А. Г. ЯХИН

Әдәбият

4

Икенче кисәк



ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

Әдәбият
А. Г. ЯХИН
4

А. Г. ЯХИН

Әдәбият

Татар телендә
башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең
4 нче сыйныфы өчен дәреслек

Ике кисәктә

ИКЕНЧЕ КИСӘК

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан рөхсәт ителгән

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 2011

УДК 373.167.1:821.512.145*04
ББК 84(2Рос=Тат) я71
Я89

Рәссамы *Рәисә Сәйфуллина*

Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Шартлы билгеләр:

?! — сораулар һәм биремнәр;

— иҗади эш.

Яхин, А. Г.

Я89 Әдәбият : татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 4 нче с-фы өчен д-лек : ике кисәктә : икенче кисәк / А. Г. Яхин.— Казан : Татар. кит. нәшр., 2011.— 159 б.: рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-02047-3

УДК 373.167.1:821.512.145*04
ББК 84(2Рос=Тат) я71

ISBN 978-5-298-02047-3

© Татарстан китап нәшрияты, 2011

Кош-кортларны сөйләштерү, предметларны җанландыру.

Искә төшерик.

Башта тема исемендәге атамаларны ачыклыйк. Хайван, кош-кортларны яхшы беләсез. Ә менә «предмет» атамасын искә төшерү зыян итмәс.

Эчтәлеккә шулхәтле бай ул «предмет» сүзе. Аның эченә кергән нәрсәләрне гомергә санап бетерә алмассың.

> Теләсә нинди җансыз әйбергә галимнәр **предмет** диләр.

Алай гына да түгел, уйлаган чакта хәтта кош-корт, хайван-җәнлекләр дә предметка әйләнәләр. Әсәрләрдә әтәчләр, этләр, сыерлар, агачлар, хәтта тыныш билгеләренә кадәр, кешеләр кебек, үзләренә йортлар салалар, эшлиләр, хәйләлиләр, укыйлар. Кеше сыйфатларын аларга әсәр иҗат итүче автор бүләк иткән.

Әдип кош-кортлар, хайваннар, җәнлекләр турында яза кебек. Ләкин без аларны барыбер кеше итеп күз алдына китерәбез. Әйберләр белән дә эш шулай. «Шәм кешеләргә яктылык бирәм дип янып бетә»,— дип яза әдип. Кешеләр турында берни дә әйтми. Ләкин барыбер, башкаларга ярдәм итү өчен, көчен

дә, сәламәтлеген дә кызганмый торган кеше турында уйлый. Ә безгә: «Шәм шәм инде ул. Мин аны кеше иттем. Ягъни мәгънәле иттем. Хәзер ул — шәм дә, шул ук вакытта кеше дә»,— ди.

Безнең бик борынгы бабайлар мәгънәнең исемен дә, аның нәрсә икәнлеген дә белмәгәннәр. Беренче чиратта тирә-юньдәге әйберләрнең килеп чыгышы белән кызыксынганнар. Аларның бөтен иҗатлары «Бу нәрсә? Бу ничек барлыкка килгән?» сорауларына җаваптан гыйбарәт булган.

Халык иҗатында да, матур әдәбиятта да персонажлары хайваннар яки предметлар булган әсәрләр күп. Андый әсәрләрнең бер ишендә хайван, кошкортлар да, җансыз әйберләр — предметлар да үз сыйфатлары белән катнашалар. Мәсәлән: *Бәрәңге әйткән: «Илтүен илтермен, кайтуыңны үзең кайгырт»,— дигән.*

Мәкальдә бәрәңге, сөйләсә дә, үзе булып кына катнаша. Аның сыйфаты берничек тә кешенеке була алмый.

?! Мәкаль эчтәлеген аңлатыгыз.

ЙӨРИ ТОРГАН АГАЧ.

Кайчандыр авыл читендә бер кечкенә малай уйнап йөргән. Кинәт ул коточкыч биек, юан агач күреп ала. Агач туп-туры авылга таба бара икән. Ул шундый зур була, малай куркуыннан кычкырып җибәрә һәм җан-фәрманга авылларына чаба.

Ирләр җыелып киңәшләшәләр. Авылга хәтле җитсә, агач барыбызны да харап итәр. Аны кисеп ауда-

рырга кирәк, диләр. Ярдәмгә күрше авыл ирләрен дә чакыралар. Таш балталарын алып, ирләр агачка каршы китәләр. Килеп җиткәч, агач тамырларын чаба башлыйлар.

Ирләр тамырларны бар көчләренә бик озак — ике көн һәм тагын бер көн чабалар. Халык җыелып эшкә тотынган арада, йөри торган агач авыл башына килеп җиткән була инде. Ниһаять, колач җитмәс кәүсә, чайкала-чайкала күк күкрәгән тавышлар чыгарып, җиргә ава.

Агач уңга-сулга чайкалганда, ботакларыннан җимешләре коела. Җимешләрнең диңгезгә төшкәннәре шунда ук балыкка әйләнеп йөзеп китәләр. Елгага төшкәннәре елга балыгы булалар.

Җимерелүдән авыл шулай котыла. Балыклар шулай барлыкка килә. Әгәр кечкенә малай авыл башына уйнарга чыкмаган булса һәм йөри торган агачны вакытында күрмәгән булса, хәзер авыл да, судагы балыклар да булмас иде. Кешеләр дә балык тота алмас иде.

Борынгы кешеләр агачка кеше сыйфатлары кушканнар. Мәгънә шулай оеша башлаган.

Бабайларның оныклары, өлкәннәр туплаган тәҗрибәгә таянып, үзләре дә яңадан-яңа ачышлар ясаганнар. Ачышларның берсе **мәгънә** булган.

БАЙ ӘТӘЧ, ЯРЛЫ ӘТӘЧ.

Авыл читендәге бер биек тауда Ярлы әтәч яшәгән. Көннәрнең берендә ул кайдадыр кычкырган әтәч тавышын ишеткән дә шунда ук җавап биргән. Ерактагы әтәчнең башы кеше башына охшаган булган. Ул үтә бай икән, чөнки акчаны йомырка урынына оясына утырып сала торган булган.

Бай әтәчнең Ярлы әтәч тавышына ачуы килгән.

— Шул оятсызның янына барып, тетмәсен тетеп кайтмасам, исемем әтәч булмасын! — дип кычкырган.

Менә ул, тәмле ашлар пешереп, ерак юлга әзерләнергә кушкан. Әзерләнеп беткәч, ерак тауга карап киткәннәр. Иң алдан, кулына озын колга тотып, әтәч киткән. Колганың бер очына ташбака кабыгы, ә икенчесенә акча тутырылган кәрзин эленгән булган. Шактый җир үткәч, ниһаять, Ярлы әтәч яши торган тауга

килеп җиткәннәр. Боларны күргәч, Ярлы әтәч кычкырып җибәргән.

— Теге тагын кычкыра,— дигән Бай әтәч. Ләкин, мескен Ярлы әтәчне күргәч, тавышын йомшарта төшкән:

— Нигә һаман кычкырасың, минем ачуымны китермәкче буласыңмы? — дип сораган.

— Андый ниятем юк. Бәлки, мине кызганырсың, дип кычкырдым. Мин — бик ярлы, авыру әтәч. Күрәсең бит: бернәрсәм дә юк, ашарыма да, эчәремә дә юк,— дигән Ярлы әтәч.

Бай әтәч як-ягына караган да ачуын да, үчен дә оныткан. Ярлы әтәчне гафу иткән. Аңа үзенә дип пешерткән ашларын да, колга башындагы акчасын да биргән. Аннары үзе яши торган тауга кайтып киткән. Шул көннән соң әтәчләр икесе дә хәсрәтсез матур гомер кичергәннәр.

Мифта әйтелгәннәргә борынгылар чын вакыйга дип ышанганнар. Мифларны балаларына сөйләгәннәр. Аннан соң: «Әтәчләр катнашкан бу вакыйга нәрсә турында?» — дип сораганнар. Балалары, бераз уйлап торгач, болай дип җавап биргәннәр...

?! Ничек дип җавап биргәннәр?

ЧИШМӘ.

Челтер-челтер чишмә ага,
Көмеш төсле сулары.
Су өстендә җем-җем итә
Көннең алтын нурлары.

Тау астында чишмәбез,—
Су алырга төшәбез.
Татлы суын без аның
Бик яратып эчәбез.
Безнең чишмә, борыла-борыла,
Зур инешкә коела.
Идел суы шундый бик күп
Чишмәләрдән җыела.
Тау астында чишмәбез,—
Су алырга төшәбез.

Әхмәт Исхак.

?! Әсәрдә чишмәнең чишмә генә булуын исбат итик. Моның өчен аның сыйфатларын барлап чыгарга кирәк. Автор башта чишмәнең матурлыгын мактый... Дәвам итегез.

Җавабыгыз дөрес булса, чишмәнең әсәрдә әйтелгән сыйфатлары бар да үзенекеләр булыр.

АК ИТЕК.

(«Урак» шигыреннән өзек.)

Сикерде яз биек түбәдән,
Җепшек карга төште тып итеп.
Шундый «яман» хәлне ишетеп,
Өйгә кереп качты ак итек.

Фәннур Сафин.

?! Әсәрдәге көлкене аңлатыгыз.

СЫЕРЧЫК.

Өй түрендә — бакчада,
Талчыбык куначада
Сыерчык канат кага —
Яз килүгә шатлана.

Җилпенә ул, талпына,
Шатлыктан сайрап куя:
Ак каенның башында
Бик матур оя тора.

Кем ясаган ояны —
Сыерчык белә аны.
Чут-чут итеп сайравы —
Аның оя сайлавы.

Гасыйм Лотфи.

?! Сыерчык яз килүгә шатлана. Автор сыерчык шатлыгын күреп соклана. Шигырьдә сыерчык — төп катнашучы. Кош матурлыгына сокланып, автор безгә нидер әйтмәкче була. Ул безгә нәрсә турында әйтергә тели?

КОШЛАР КАЙТКАЧ.

Елгада бозлар кузгалды...
Елмая, көлә кояш.
Урамнар буйлап атлады
Ямьле һәм күңелле яз.

Килгән кошларны күрергә
Гаяз ашыкты иртән:
— Сыерчык кунган түбәгә,
Кайчан ул килеп җиткән?

Сузып-сузып сайрый кошчык,
Канатын кага-кага.
— Яратам җырыңны,— диеп
Эндәште Гаяз аңа.

— Ышанмыйм,— диде сыерчык,—
Күңелем минем тоя:
Яраткан булсаң җырымны,
Син куяр идең оя.

Галимҗан Латыйп.

?! Сыерчык әсәрдә кешечә сөйләшә. Аның мәгънәсе кеше була аламы?

ЧЫЛБЫРДАГЫ ЭТ.

Бер ишегалдында ояда чылбырга бәйләнгән карт эт тора иде. Ул бала чагыннан ук, шул чылбырда йорт каравыллап, хуҗасына бик күп хезмәт иткәнгә, хуҗа да бу этне бик сөя иде.

Хуҗа, кайвакыт моның янына килеп: «Син мине яратасың, миңа тугры хезмәт итәсең бит, иншалла, мин дә сине ташламам»,— дип әйтеп, карт этнең күңелен шатландырып китә иде.

Кайчакта иректә йөри торган урам этләре, ишегалдына кереп, бу этне котырталар вә үчеклиләр иде.

— Менә син хуҗаңа хезмәт иткән буласың, бервакыт күрерсең әле: син картаеп эштән чыксаң,

хужаң сине йортыннан куар да чыгарыр әле, ашарга да таба алмассың,— диләр иде.

Ләкин чылбырдагы эт боларның сүзләрен, хуҗаның эшен ташлап, үзенә көн күрергә киңәш бирүләрен тыңламады.

Көннәрдән бер көнне бу эт хуҗасының йортыннан ут чыкты. Өй янып бетте; инде утның ялкынлы төтеннәре эт оясына да җитә башлады.

Бичара эт бик каты курыкты. Кызганыч тавышлар илә өреп, еглап, ары-бире сугылып, чылбырны өзәргә азаплана башлады. Шулай булса да аның эчендә «Шаять, хуҗам килер әле, мине коткарыр әле» дигән ышаныч һаман бар иде.

Бара торгач, төтеннән сулыш алырга да читен була башлады. Мескен эт чылбырны өзә алмый, аңа хәзер янып үләргә генә калган иде.

Шулай торганда менә берзаман әллә кайдан төтен арасыннан хуҗа йөгереп килеп чыкты. Аның чәчләре, киемнәре, йөзе тәмам көйгән, бөтен җиреннән төтен чыга иде. Үзе шундый куркынычта булса да, ул, ничек тә булса утны ерып кереп, этнең чылбырын чиште.

Эт, мескен, котылуы белән, хуҗасына ташланды. Эт бичара тик: «Рәхмәт сиңа! Мин синең мине карап торып һәлак итмәсеңә ышанган идем. Рәхмәт сиңа!» — дип әйтә генә алмады.

Габдулла Тукай.

?! Әсәрдә хуҗа эте һәм урам этләре катнаша. Үгет бирергә яратучы этләр белән чылбырдагы этне чагыштырыгыз. Аерма табыгыз. Алар нинди кешеләргә охшыйлар?

АЙ СУКМАГЫ.

(Зурлар һәм кечкенәләр өчен әкият-драма.)

КАТНАШАЛАР:

Үлемсез Акылгали.
Таңсылу — урман кызы.
Аучы Инсан.
Золымхан.
Әҗәлхан — җәллад[1].
Мәкерхан — вәзир.
Җилҗилә — урман хәбәрчесе.
Болан бозавы.
Аю-Ахун.
Этбаш-сыераяклар.
Күбәләкләр.
Боек төнбоек һәм башка төнбоеклар.

Вакыйга Гөлстан илендә бара.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ.

Беренче күренеш.

Кара урман, караңгы төн. Урман йокыга талган. Төз нарат-лар, шыбырдык усаклар, зифа каеннар — барысы да йокыда. Кыргый киекләр, сайрар кошлар, сандугачлар-былбыллар — барысы да, барысы да татлы йокыда. Тик Салкын чишмә генә төннең төн буе гөлдер-гөлдер... Үзенең серле әкиятен — мәңгелек әкиятен сөйли, изге теләкләр тели:

— Йоклагыз, йоклагыз, урман балалары! Йокыгыз тыныч, төшләрегез татлы булсын!

Бөдрә башын әнисенең иңенә салган каен кызы төшендә моңлы бәллү җыры ишетеп, таңга кадәр изрәп йоклый.

---

[1] Җәллад — үлем җәзасын башкаручы.

Урман хәбәрчесе Җилҗилә шулчак агач башларын сыйпап уза...

— Таң ата! Таң ата!

Куаклардан көмеш чыклар коела, күктә бер-бер артлы йолдызлар сүнә. Сайрар кошлар — сандугачлар, кәккүкләр телгә килә. Шаулы камышлы тымызык күлләрдә төнбоеклар керфек ача, аккош кычкыра:

— Таң ата! Таң ата!

Урман чишмәләре җырына яңа дәрт өстәлә. Кояшның беренче нурлары, яфракларны аралап, чишмә өстенә төшә. Яшел ешлыкта меңләгән кояш күбәләкләре биешә.

Тереклек — шатлык, яшәү — бәхет.

Урман ешлыгыннан, ак томандай очынып кына, урман кызы Таңсылу чыга. Ул таңны сәламли, кояшка баш ия.

Таңсылу. Сәлам сиңа, алсу таң! Сәлам сиңа, мәңгелек тереклек чыганагы кайнар кояш! *(Таңсылу төрлесе төрле җиргә кунып йоклаган күбәләкләрне уята.)*

Торыгыз, уяныгыз, күбәләкләрем! Әнә нинди таң атты, әнә нинди сихри иртә! Таң вакытын йоклап уздырганнар бәхеттән мәхрүм кала, ди.

Күбәләкләр, бер-бер артлы уянып, куаклардан чык бөртекләрен, җыеп, ап-ак туз тырыска тутыралар һәм, аларны энҗе-сәйлән итеп, Таңсылуны бизиләр.

?! Пьесаның укыган өлешен ике өлешкә бүлегез. Өлешләргә бер-ике сүз белән генә исемнәр бирегез.

Хәлдән таеп, Болан бозавы чабып керә.

Болан. Коткар мине, коткар!..

Таңсылу. Кем тиде, кем җәберләде, боланчыгым?!

Болан. Аучы егет куа килә. Кулында утлы ук ата торган корал. Ул мине атып үтерәчәк. Инде нишлим? Инде нишлим?! Тау-ташлар аша көн-төн чабып хәлдән тайдым. Ары атлар хәлем юк. *(Елый. Тәмам хәлсезләнеп, җиргә ава.)*

Таңсылу. Тор тизрәк, кузгал. Урман-ана кочагына яшерен. Тиз бул, әнә ул килеп тә җитә.

Аучы Инсан керә. Кулында мылтыкны да, борынгы сөңгене дә хәтерләткән сәер корал.

Инсан. Озак йөгерттең, Болан, әмма ычкына алмадың. Бәхилләш якты дөнья белән. *(Җәясен киерә.)*

Таңсылу. Тукта, атма!

Инсан. Кызый! Кем син? Бу кара урманда, адәм аяк басмаган караңгы ешлыкта нишләп йөрисең?

Таңсылу. Таңсылу мин. Бу Боланчык — минем туганым.

Инсан. Боланмы? Дүрт аяклы киек адәм баласына туган булырмы?

Таңсылу. Адәм баласы түгел мин. Урман кызы. Әнкәм — Карурман, туган җирем — гөлчәчәккә күмелгән шушы ил, Гөлстан иле.

Инсан. Сәер кыз икәнсең... Менә нәрсә, урман кызы Таңсылу! Бу Боланны мин кечәдән бирле эзәрлеклим. Ул — минем табышым. *(Атарга тели.)*

Таңсылу *(Боланны күкрәге белән каплый).* Атсаң, икебезне бергә ат! Үтер! Мине дә үтер.

Инсан. Шушы киек өчен үзеңне корбан итәрсеңме?



Таңсылу. Гөлстан иле — дуслык, туганлык иле. Дошман булмасаң, куй читкә утлы коралыңны.

Инсан. Матур гына түгел, батыр да икәнсең, урман кызы Таңсылу. Ярый, тыңлыйм сүзеңне.

Таңсылу. Рәхмәт, егет. Туганнарымны җәберләмәсәң, гомерең буе дустың булырмын. Исемең ничек синең?

Инсан. Аучы Инсан диләр мине. Сусадым. Салкын су бирегезче.

Таңсылу. Боланчыгым, бар әйт төнбоекларга. Кунагыбызга су китерсеннәр.

Болан. Су! Су! Кунагыбызга салкын су!

Чыгып йөгерә. Озак та үтми, сәхнәгә ак һәм сары төнбоеклар йөгерешеп керә. Иң артта Боек төнбоек. Аның берничә таҗ яфрагы көеп каралган.

Тенбоеклар. Инсан батыр! Инсан батыр! *(Инсанны уртага алып, әйлән-бәйлән уйнап җырлыйлар. Тик Боек тенбоек кына, моңаеп, башын иеп, бер читтә утыра.)*

Инсан тенбоек касәләреннән су эчә.
Рәхмәт әйтеп, баш ия.

Таңсылу. Инсан егет! Инсан батыр! Синең йөрәгең шәфкатьле, күңелең саф. Китмә син. Кал биредә, кал...

Боек тенбоек. Кал биредә, шәфкатьле егет, кал! Үтенеп сорыйбыз синнән. Безгә... безгә синдәй рәхимле, синдәй көчле яклаучы кирәк. Юкса...

Таңсылу. Тыңла син безне, Инсан батыр. Әнә биредә нинди гүзәллек. Әнә ишетәсеңме? *(Каен кәүсәсенә колагын куеп тыңлый.)* Ишетәсеңме: кәүсә буйлап каен суы ага.

Инсан. Син... Син шулай кәүсәдә каен суы акканны да ишетәсеңме?

Таңсылу. Әнә тыңла! Тыңла син, адәм улы Инсан! Тамырлардан яфракларга шифалы ширбәт килә. Әнә бөреләр эчендә яшь яфраклар шыта. Әнә урман күгәрчене гөрли, чишмәләр чылтырый, кәккүк кычкыра... Китмә!

Күбәләкләр һәм тенбоеклар *(бергәләп).*

Зәңгәр төндә көмеш күл,
Ай сукмагы тирбәлә.
Шул сукмакка утырып
Тирбәлербез, бергәләп.

Уйлашырбыз, бергәләп,
Җир язмышы турында.
Китмә, кеше, китмә син,
Язмышың үз кулыңда.

Таңсылу. Язмышың үз кулыңда!

Инсан. Синең гүзәллегеңнән күз камаша. Сүзләреңнән йөрәгем талпына. Әмма минем юлдашым — утлы ук, киңәшчем — булат кылыч.

Шулчак урман тынгысызланып шаулый башлый.

Инсан. Чү! Бу нинди шомлы аваз?

Таңсылу. Җилҗилә. Урман хәбәрчесе. Ашыгыч хәбәр китерә.

Җилҗилә очып керә. Ул гүзәл кыз кыяфәтендә. Юка ефәк бөркәнчеге, ефәк күлмәгенең киң итәкләре, җиңнәре сузылып, җилфердәп килә. Ул һич тукталып тормый. Әйтәсе сүзен узышлый гына сөйләп бирә.

Җилҗилә. Алып килдем бер хәбәр. Бу хәбәрем бик хәтәр. Ил өстенә яу килә. Яу башлыгы — Золымхан, узган юлы — кара кан. Өлкән вәзир — Мәкерхан, җәлладлары — Әҗәлхан. Бик хәтәр, бик хәтәр... *(Чыгып китә.)*

Күбәләкләр һәм төнбоеклар *(куркышып).* Золымхан килә. Золымхан явы. Этбаш-сыераяклар! Качыгыз!

Чыгып йөгерәләр. Еракта быргы, барабан тавышлары. Көчле сирена улагандай, күк күкрәгәндәй шомлы авазлар, шомлы музыка.

Инсан. Тукта, ни булды сезгә? Ник барыгыз да куркуга калдыгыз? Алар соң... адәми затлардан түгелмени?

Болан. Золымхан явы узган җирдә чәчәкләр шиңә, чишмәләр кибә.

Инсан. Ай-һай! Ай-һай!

Болан. Аның вәзире Мәкерхан мең төрле сихер белә. Җәллады Әҗәлхан бертуктаусыз кан коя. Әнә килеп җитәләр. Нишлибез?

Таңсылу. Син... Син әле һаман ышанмыйсыңмы?.. Ярый, кара, алайса, бу нәни төнбоекка. Әнә бер тагы ничек көйгән.

Инсан. Чыннан да, бөтенләй кара күмергә әйләнгән.

Боек төнбоек. Айлы төн иде. Көмеш күлдә нәни йолдызлар тирбәлә иде... Мин аларга тылсымлы әкият сөйли идем. Мавыгып киткәнмен. Золымханның күлгә агу агызганын сизми калганмын. *(Елый.)* Дусларым, башка төнбоеклар көмеш күлгә, тирәнгә чумып өлгергәннәр. Ә мин... Инде гомерем бик аз калды минем.

Инсан. Юк, син яшәргә тиеш. Бар, бар тизрәк дусларың янына. *(Боек төнбоекны озата.)* Болай булгач, мин сезне ташламыйм. Тәнемдә җаным барында мин ул явызларга юл куймам.

Таңсылу. Юк, батыр егет, син берьялгызың усал Золымханга каршы тора алмыйсың. *(Урманга карап кычкыра.)* Газиз анам Карурман! Инде нишлик, киңәш бир!

Карурманның җавабы булып, әллә ничә юнәлештән кайтаваз яңгырап ишетелә: «һә-һә-һәй... һә-һә-һәй...»

Инсан. Аңладыңмы телен? Нәрсә әйтә әнкәң урман?

Таңсылу. Золымханга каршы торырлык тик бер зат бар, ди. Акылгали. Егылганга кул, адашканга юл күрсәткән изге Акылгали.

Инсан. Сора әнкәңнән, урман кызы, кайда ул Акылгали?

Таңсылу *(кычкыра).* Газиз анам Карурман! Кайда ул?.. Кайда ул Акылгали?

Урман авазы: «һә-һә-һәй... һә-һә-һәй...»

Таңсылу. Ул исән, тик әнкәм Карурман аның кайдалыгын белми.

Инсан. Без аны табарбыз. Табарбыз үлемсез Акылгалине. Гөлстан илен коткарып калырбыз. Әйдәгез, әзли барыйк.

Болар чыгарга барганда, аларга каршы борынгы сөңгеләрне дә, хәзерге ракеталарны да хәтерләткән хисапсыз күп сәер кораллар сузыла.

Инсан. Биредә дошман. Әйдәгез.

Башка юнәлешкә йөгерәләр. Ләкин анда да шул ук хәл. Кая гына бармасыннар, каршыларына сөңге, ракета очлары сузыла. Прожектор кебек акай күзле роботлар аркылы төшә.

Таңсылу. Юллар ябык. Без һәлак булдык, һәлак булды Гөлстан иле.

Инсан. Күңелеңне төшермә, батыр бул, гүзәл Таңсылу. *(Кылычын ала.)* Әйдә, булат кылычым, бүгенгесе көннән синең белән изге көрәшкә — Җир язмышы өчен көрәшкә чыгабыз. *(Дошман явы өстенә ташлана, кылычы белән юл ярып уза.)*

Кара тәхеткә утырган Золымханны күтәреп, этбаш-сыераяклар керә. Алар ишарәләр белән һәм борын аша мыгырдап кына аңлашалар. Тәхетнең бер ягында Мәкерхан, икенче ягында Әҗәлхан.

Золымхан. Гаскәр! Үрә кат! Трам-та-там! *(Барабан сугалар.)* Җәллад!

Әҗәлхан. Асам-кисәм, кан коям, көлә-көлә җан кыям. Ха-ха-ха! *(Тәхет алдына килеп, баш ия.)*

Золымхан. Вә-вә-вәзир!

Мәкерхан. Мәкер җепләре үрәм, хәйлә белән көн күрәм. Хи-хи-хи... *(Баш ия.)*

Золымхан. Фәрма-ан!

Мәкерхан. Тыңлагыз! Тыңлагыз! Бөек ханыбыз Золымханның мең дә беренче фәрманы. Бөек ханның үпкәсен агулый торган хуш ис таратучы барлык чәчәкләрне, яфракларны көл-күмер итәргә. Гөлстан илен бүгенгесе көннән Көлстан иле дип исемләргә. Кем дә кем шушы фәрманга буйсынмый...

Болан. Мин! Мин буйсынмыйм мондый әшәке фәрманга!

Мәкерхан. Хи-хи-хи... Син буйсынмыйсыңмы?! Мәкер җепләре үрәм, хәйлә белән көн күрәм... Әфсен-төфсен фәрмалин, шухрый-мухрый дәрмалин. *(Кара таягын Боланга төзи. Сызгырган, улаган тавышлар. Таяк очыннан кукле-яшелле утлар сибелә. Болан шунда ук таш кыяга әверелә.)*

Таңсылу. Болан! Боланчыгым, сиңа ни булды? Мин дә буйсынмыйм! Гөлстанның иреккле балалары бу фәрманга баш имәс.

Әҗәлхан. Асам-кисәм, кан коям...

Золымхан. Вә-вәзир! Фәрман!

Мәкерхан. Тыңлагыз! Тыңлагыз! Бөек ханыбызның мең дә икенче фәрманы. Урман кызы Таңсылу —

бүгенгесе көннән бөек ханның күләше, аның сарай бизәге...

Таңсылу. Минем сараем — хәтфә келәмле, яшел түбәле урман аланы.

Мәкерхан. Мәкер җепләре үрәм... Әй гүзәлләрнең гүзәле Таңсылу! Бөек ханыбыз Золымхан синең юлларыңа энҗе, гәүһәр сибә.

Таңсылу. Минем хәзинәмдә бетмәс-төкәнмәс энҗеләр — таң чыклары. Урман чәчәкләре миңа барлык асыл ефәкләрдән артык. Кызарып пешкән җиләкләр, каралып пешкән карлыганнар барында, кирәкми миңа ханның балы-мае.

Мәкерхан. Шулаймы? Чәчәкләр, җиләкләр, карлыганнар, бөрлегәннәр кирәкме? Хи-хи-хи... Әфсентөфсен фәрмалин, шухрый-мухрый дәрмалин! *(Кара таягыннан ут чәчә. Бөтерелеп, сихер бию башкара. Шунда ук бөтен чәчәкләр, бөтен яфраклар юкка чыга. Урман кара күмергә әйләнеп кала. Этбашсыераяклар сикерә-сикерә бииләр, көләләр.)*

Таңсылу. Газиз анам Карурман! Туган җирем Гөлстан!

Мәкерхан. Гөлстан түгел, Көлстан. Хи-хи-хи... *(Таңсылуның кулларын богаулый.)*

Шулчак Җилҗилә очып керә.

Җилҗилә. Бирешмә, батыр бул, Таңсылукай. Изге хәбәрләр көт! Акылгали үлмәгән. Инсан китте, әйтер ул, аны табып кайтыр ул. Тетрәнегез, явызлар!

Золымхан. Фәрма-ан!

Мәкерхан. Тыңлагыз! Тыңлагыз! Бөек ханыбызның мең дә өченче фәрманы... Акылгалине тотарга... Тотарга да сытарга. Таулар-ташлар ярырмын, Инсаннан тиз барырмын. Шухрый-мухрый фәрмалин! *(Юкка чыга.)*

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ.

Икенче күренеш.

Урманлы биек таулар арасында тар гына үзәнлек. Бирeдә һәр үсемлек кара көйгән. Тау итәгендә, карт имән төбендә Аю-Ахун зур агач көрәк белән чишмә казый.

Аю. Ох-ох-ох! Кая киттең чишмәбез? Нигә киптең чишмәбез? Ох-ох-ох! Чыкмый! Өч көн, өч төн казыйм, тамчысы да... *(Тагын казый башлый. Эш белән мавыгып, җир астыннан Мәкерхан килеп чыкканын сизми.)*

Мәкерхан. Шухрый-мухрый дәрмалин!.. Сукмакта кеше эзе күренми. Килеп җитмәгән. Сорыйм әле бу сөрхәнтәйдән. Әфәндем Аю-Ахун, Акылгали узмадымы бу сукмактан?

Аю. Кем сорый? Дустымы, дошманымы?

Мәкерхан. Бичара бер дәрвиш мин. Каты авыруга юлыктым. Гомер буе азау тешем сызлый. Ай-вай-вай!.. Акылгали җитмеш төрле сырхауга дәва белә дип ишеттем. Ай-вай-вай!..

Аю. Түз, дәрвиш, түз! Бөек Акылгалинең үтәр юлы шушы сукмакта. Озакламый кайтып җитә Акылгали!

Мәкерхан. Шатланасың? Әллә синең дә авыруың бармы?

Аю. Авыруым юк, моң-зарым бар. Явыз Золымхан явы бөтен җирне агулап, кара күмер итеп, чишмәләребезне корытып китте. Җир яна, тереклек яна. Елгалар, күлләр агуланды, балыклар, бөҗәкләр, киекҗәнлекләр һәлак була.

Мәкерхан. Минем кемлекне беләсең киләме, әфәндем Аю-Ахун? Әфсен-төфсен фәрмалин, шухрый-мухрый дәрмалин. Таш арасы күл булсын, күл буена юл булсын. *(Кара таяк ярдәме белән күл ясала.)* Шухрый-мухрый дәрмалин! *(Күлгә чума, үз кыяфәтендә чыга. Күл шунда ук юк була.)*

Аю. Мәкерхан!

Мәкерхан. Ә-ә, шулаймы, таныдыңмы?

Аю. Бетерәм, сытам! *(Зур күсәк күтәреп, Мәкерханга һөҗүм итә.)*

Мәкерхан. Хи-хи-хи... Шухрый-мухрый дәрмалин! *(Кара таягы белән ут чәчә. Аю күсәк күтәргән килеш, торараташтай катып кала. Мәкерхан аның кулаякларына богау сала.)* Таш ярылсын, чишмә аксын, су түгел, агу аксын. Агуны Акылгали эчсен, җаны җәһәннәмгә очсын... *(Таш ярыла, агулы чишмә ага.)* Хи-хи. Менә синең дустыңа сый-хөрмәт. Ә без атлый торыйк. *(Аюны таягы белән кыйный-кыйный алып чыгып китә.)*

Бераздан, әлсерәп, хәлдән таеп, Инсан керә.

Инсан. Акылгали! Акылгали! Эзләп йөрим бик күптән, юлымда сулар кипкән. *(Чишмәне күрә.)* Чишмә! Салкын чишмәкәй! Эчим әле! Басыйм әле сусавымны. *(Эчә.)* Ә-әх, салкын! Ә-әх, тәмле!.. Тукта, нигә баш әйләнеп китте?.. А-ах, егылам... Үләм. *(Егыла.)*

Акылгали керә.

Акылгали. Нигә хәсрәтле монда һәр агач?
Нигә сайрамый сары сандугач?

(Карт имән төбенә килеп, аның кара янган кәүсәләрен карый.) Әйтмисеңме? Туган җиремнең бу кайгысы — минем йөрәгемә кара таш. *(Су эчәргә бара. Үлеп яткан Инсанны күреп ала.)* Тукта, ни булган бу адәм баласына? Дәвалап карыйк.

Сиңа әҗәл дәвасы —
Туган илнең һавасы.
Ач күзеңне, ач, балам,
Ач үлемнән кач, балам!

(Куенынннан ак чәчәк алып иснәтә. Инсан күзләрен ача.)

Инсан. У-ух, озак йоклаганмын.

Акылгали. Син мәңгелек йокыда идең, балам. Сине туган ил һавасы үлемнән йолып алып калды. Сәфәргә киткәндә, истәлеккә өзгән бердәнбер чәчәк. Ярый әле, саклаганмын.

Инсан. Әйе, әйе, исемә төште. Мин үлемсез Акылгалине эзләп бара идем. Очратмадыңмы аны, бабакай?

Акылгали. Акылгали? Акылгали бабаң мин үзем булам. Ни йомыш, адәм углы?

Инсан *(шатланып).* Акылгали бабай! Коткар Гөлстан илен. Коткар дусларыбызны! Урман кызы Таңсылу усал Золымхан, сихерче Мәкерхан кулында.

Акылгали. Кара эчле Мәкерхан! Менә кем эше икән бу явызлык! Йөгерик! Салкын чишмә суы эчеп, арыган тәнгә хәл алыйк та...

Инсан. Эчмә, бабакай, эчә күрмә. Мине үтергән агулы чишмә бу.

Акылгали. А-ах, менә ничек! Димәк, бусы да Мәкерхан сихере! *(Чапан эченнән тылсымлы чәчәген чыгара. Аны әкрен генә чишмә өстендә тирбәтә-тирбәтә җырлый.)*

Явыз дошман кул салган
Агу бетсен суыңда,
Гөлләр үссен юлыңда.

Кинәт кенә тылсымлы чәчәк аллы-гөлле нурлар сибә. Нурлар чишмә суында чагыла. Инсан белән Акылгали чишмәдән, учлап-учлап, су эчәләр.

Акылгали. Йөгерик, балакай! Дусларыбызны коткарыйк!

Инсан. Йөгерик, йөгерик. *(Чыгалар.)*

Пәрдә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ.

Өченче күренеш.

Беренче күренештәге алан. Золымхан явы кара чатырлар корган. Иң зур чатыр алдында, кара тәхеттә Золымхан утыра. Таңсылу, таш кыяга карап, тирән уйга талган. Аның кулында көмеш гөслә[1].

---

[1] Гөслә — бармаклар белән чиертеп уйный торган күпкырлы музыка коралы.

Таңсылу *(моңлы көй уйный, җырлый).*

Алсуланып таңнар атмый шул,
таш кыям.
Сандугачлар гөлне тапмый шул,
таш кыям.
Чишмәләр дә челтерәп акмый шул,
таш кыям.
Ташларыңа иелеп яшь коям,
таш кыям.

Әҗәлхан. Бөек ханыбыз күңел ачарга тели. Күңелле көй уйна! Шатлыклы көй!

Таңсылу. Урман анам яшел яфрак ярсын, сандугачлар-былбыллар кире кайтсын, гөлләребез янә чәчәк атсын. Шунда мин сезгә шатлык көе, бәхет көе уйнармын.

Золымхан. Җәллад!

Әҗәлхан. Асам-кисәм, кан коям, көлә-көлә, җан кыям. Ха-ха-ха! *(Кылычын күтәреп, Таңсылуга ташлана. Шулчак, Аюны җитәкләп, Мәкерхан керә.)*

Мәкерхан. Фәрманыгыз үтәлде, бөек ханым. Акылгали, агулы чишмә суы эчеп, теге дөньяга олагачак.

Золымхан. Үр-рә кат! Трам-та-там!

Этбаш-сыераяклар дөбер-шатыр барабан кагалар.

Аю. Юкка! Юкка шатланасыз, явызлар! Акылгали бөек.

Мәкерхан. Хи-хи-хи... Бөектән бөек шөһрәтле Золымхан бөек!

Аю. Кан эчүче рәхимсез Золымхан.

Золымхан. Фәрман!

Мәкерхан. Тыңлагыз! Тыңлагыз! Бөек ханыбызның мең дә дүртенче фәрманы! Шәһрәт иясе бөек Золымханга каршы сөйләгәне өчен, Аю-Ахунны теленнән мәхрүм итәргә.

Золымхан. Җәллад!

Әҗәлхан. Асам-кисәм, кан коям!.. *(Аюның башын чабарга бара.)*

Таңсылу. Туктагыз, тукта! Аю-Ахун — оста биюче. Үлем алдыннан биеп күрсәтсен, бөек ханның күңелен ачсын. *(Күңелле көй уйный.)*

Мәкерхан. Бие, Аю-Ахун. Шатлыклы көнең. Җаның җәннәткә китә. Бие.

Таңсылу. Ул богаулы килеш бии алмый. Салдырыгыз богауларын.

Мәкерхан аның богауларын салдыра. Таңсылу гөслә уйный. Аю биеп китә.

Таңсылу. Аю-Ахун — зур агам,
Сикереп-сикереп биедең,
Соңгы тапкыр бас, әйдә...
Кул-аягың богаусыз,
Йөгереп-йөгереп кач, әйдә.

Аю. Ох-ох-ох! *(Золымханның тәхетен тибеп аудара да чыгып кача.)*

Золымхан. Мәкерхан! Бөек тәхетне аударган, хан әмерен бозган куркыныч җинаятьче Таңсылуны җәзага тартырга. Ак болыт итеп, күккә очырырга.

Мәкерхан. Әфсен-төфсен фәрмалин, шухрый-мухрый дәрмалин. Кара болыт, ак болыт... Йөзеп йөр, болыт булып!

Таңсылу. Хуш, сау бул, таш кыям. Хуш, бәхил бул, туган илем Гөлстан! *(Ак болытка әверелеп очып китә.)*

Золымхан. Трам-та-та-там!

Җилҗилә очып керә.

Җилҗилә. Әй сез, явызлар! Иртә шатланасыз. Акылгали үлмәгән, аңа берни булмаган. Аю китте, әйтер ул, аны табып кайтыр ул. Куркыгыз, тетрәнегез!

Золымхан. Җәллад!

Мәкерхан. Кичерегез, бөек ханым Золымхан. Өлкән вәзирегездә сихер көче бетмәгән. Агулы чишмәдән котылса, мәкерле алмагачым бар. Дошманыбыз Акылгалине юк итмәсәм, Мәкерхан исеме харам булсын! Шухрый-мухрый дәрмалин! *(Юкка чыга.)*

Пәрдә.

Дүртенче күренеш.

Шәп-шәрә таш кыялар буеннан тар сукмак уза. Бердәнбер юл, хәвефле юл. Мәкерхан керә. Иелеп, сукмакны карый.

Мәкерхан. Монда Инсан эзе юк. Акылгали дә узмаган... Әфсен-төфсен фәрмалин, шухрый-мухрый дәрмалин. Кызыл агач, ал агач, үс, мәкерле алмагач! *(Шунда ук алмагач үсеп чыга.)* Алсу-алсу алмасын башка беркем алмасын. Акылгали ашасын. Бал тәме бар эчендә, зәһәр агу төшендә... *(Юкка чыга.)*

Бераздан **Инсан** белән **Акылгали** керәләр. Бик арыганнар, тәмам хәлдән тайганнар.

Акылгали. Авыр юл, газаплы юл. Тәмам җегәрне алды.

Инсан *(алмагачны күреп).* Акылгали бабай, күр әле, нинди матур алмагач, нинди эре алмалар!

Акылгали. Бик тәмле, бик сусыл күренә. Өзеп ашыйк. *(Ике алма өзә, берсен Инсанга бирә.)*

Инсан ашарга гына торганда, **Аю** чабып керә.

Аю. Ох-ох-ох... Ух-ух-ух... *(Төрле ишарәләр белән алманың агулы икәнен аңлатырга тырыша. Берничек тә аңлата алмагач, агулы алманы үзе ашый да шунда ук егылып үлә.)*

Акылгали *(аның йөрәген тыңлый).* Үлде. Каһәр! Каһәр! Тагын шул Мәкерхан мәкере. Өмет өзмик, тырышып карыйк. Туган илнең һавасы — әҗәлнең дәвасы. Ач үлемнән кач, Аю. Күзләреңне ач, Аю! *(Чәчәк иснәтә.)*

Инсан. Бабай! Бабакай! Кузгала. Җан керә!

Аю *(терелеп аягына баса).* Ох-ох-ох! Нинди матур төш. Нинди матур җыр уятты мине?!

Акылгали. Дуслык җыры уятты сине. Дуслык җыры телле итте.

Аю. Ох-ох-ох! Хәтерлим! Мәкерхан алмасы. Йөгерик! Чабыйк!

Акылгали. Юк, балалар, сезгә анда барырга ярамый. Золымханның һәр сулышы — сезнең өчен һәлакәт. Ул явызга каршы мин үзем көрәш ачам. Әгәр

һәлак булсам, Гөлстан иле өчен корбан булды, диярсез. Хушыгыз, балалар. *(Китә.)*

Аю. Китте! Берьялгызы китте!

Инсан. Әйдә, Аю-Ахун, барлык урман балаларына хәбәр итик. Ярдәмгә барыйк.

Аю. Йөгерик, йөгерик! *(Чыгып йөгерәләр.)*

Пәрдә.

Бишенче күренеш.

Урман аланы. Золымхан кара тәхеттә утыра. Мәкерхан керә.

Мәкерхан. Мәкер җепләре үрәм... Хи-хи-хи... Фәрманыгыз үтәлде, бөек ханым. Акылгали, агулы алма ашап, теге дөньяга олагачак.

Золымхан. Там-та-ра-рам!

Җилҗилә очып керә.

Җилҗилә. Акылгали үлмәгән, аңа берни булмаган. Белегез: сезнең соңгы көнегез.

Ерактан Акылгали җыры ишетелә.

Золымхан. Җәллад!

Әҗәлхан. Асам-кисәм, кан коям!.. *(Мәкерханның башын кисәргә тели.)*

Мәкерхан. Бөек ханым Золымхан! Өлкән вәзирегездә мәкер көче бетмәс-төкәнмәс. Дошманыбыз Акылгали агулы алмадан, агулы чишмәдән котылса да, мәкер җәтмәсеннән ычкына алмас. Әфсен-төфсен фәрмалин, шухрый-мухрый дәрмалин. *(Таягы белән*

җиргә суга. Җирдән кара җәтмә күтәрелеп, агач башларына эленә.) Хи-хи-хи... Килсен, килсен. Башын, кисеп, алдыгызга куярбыз.

Акылгали керә.

Акылгали *(тирә-якка каранып).* Тереклек дошманы явыз Золымхан! Ни хәлгә калдырдың Гөлстан илен?! Гөлстан иле дошман аягы астында көл булмас. Гөлстан чәчәгенең исе — сезнең барыгызга да үлем.

Акылгали, куеныннан туган җир чәчәге алып, аны баш очына күтәрә. Аның таҗында кинәт аллы-гөлле нурлар уйный башлый. Дөнья яктырып китә. Ләкин шулчак бөтен роботлар, бөтен сиреналар улый, үкерә башлый. Этбаш-сыераяклар өчен бу — куркыныч тревога.

Золымхан. Вә-вә-вәзир!

Мәкерхан. Шухрый-мухрый дәрмалин! *(Кара җәтмә төшеп, чәчәге-ние белән Акылгалине чорнап ала.)*

Мәкерхан. Менә инде синең дә соңгы сәгатең сукты. Безнең урамда бәйрәм!

Золымхан. Фәрма-ан!

Мәкерхан. Тыңлагыз! Тыңлагыз! Бөек ханыбыз Золымханга каршы чыккан өчен, Акылгалинең башын кисәргә.

Әҗәлхан. Асам-кисәм! Кан коям, көлә-көлә, җан кыям! *(Акылгалигә кылыч белән суга, ләкин кылыч аның башын кисә алмый.)*

Мәкерхан. Шухрый-мухрый... *(Кара таягыннан ут бөрки. Акылгалигә берни дә булмый.)*

З о л ы м х а н. Сабыр итегез, ханым! Мин моның бер серен аңладым. Әҗәлханның кылычы бары тик иелгән башларны гына кисә ала.

А к ы л г а л и. Сез күп җан кыйдыгыз, күп илләрне вәйран иттегез. Әмма Акылгалине беркайчан да баш идерә алмадыгыз һәм идерә алмассыз да!

З о л ы м х а н. Фәрма-ан!

М ә к е р х а н. Тыңлагыз, тыңлагыз! Бөек Золымхан алдында баш имәгән өчен, Акылгалине тереләтә күмәргә. Җитмеш колачлы чокыр казып, җитмеш потлы таш белән бастырырга.

Тау-ташларны актарып, чокыр казыйлар. Акылгалине чәчә-ге-ние белән шунда ташлап, өстенә таш бастыралар. Бәйрәм башлыйлар. Барысы да бии. Ләкин шулчак, әче сирена тавышларын басып, көмеш гөслә авазы яңгырап китә. Акылгалинең кабере өстендәге ташны тишеп, гүзәл чәчәк үсеп чыга.

З о л ы м х а н. Фу-фу-фу!

М ә к е р х а н. Чәчәк исе. Бөек ханыбызның үпкәсен агулый. Кисәргә! Тураклап ташларга.

Ә җ ә л х а н. Ха-ха-ха! *(Чәчәкне кисә, турый, төрле җиргә сибеп ташлый. Ләкин, бии башлауга, чәчәкнең һәр кисәге, һәр яфрагы яңа чәчәк булып үсә.)*

М ә к е р х а н. Буыла! Бөек ханыбыз һәлак була!

Шулчак бер яктан т ө н б о е к л а р, икенче яктан у р м а н ч ә ч ә к л ә р е йөгерешеп киләләр.

Б о е к т ө н б о е к. Уяна илебез! Уяна Гөлстан иле!

М ә к е р х а н. Шухрый-мухрый дәрмалин! *(Чәчәкләргә һөҗүм итәләр. Шулчак, таш кыя ярылып, аннан Болан чыга.)*

Б о л а н. Чәчәк исе, гөл исе — туган илнең һавасы, туган җирнең һавасы — безгә әҗәл дәвасы.

М ә к е р х а н. Шухрый-мухрый... Ханым-солтаным, инде нишлик?! Чәчәк исеннән сихер таягының көче бетте.

И н с а н һәм А ю йөгереп керәләр.

И н с а н. Шулаймы? Шулаймы, явызлар! Инде сихердән башка көрәшеп карагыз. *(Золымханга ташлана.)*

Әҗәлхан җитәкчелегендә этбаш-сыераяклар явы Инсанга һөҗүм итә, Инсан аларга каршы тора. Аю белән Болан Инсанга ярдәм итәләр. Каты көрәштән соң Мәкерхан, Әҗәлхан һәм барлык этбаш-сыераяклар куркышып чыгып качалар.

И н с а н. Йә кансыз хан, явыз Золымхан. Инде синең чират! Күрсәт кодрәтеңне!

А ю. Упкынга явызны!

И н с а н. Җәһәннәмгә!

Тәхете-ние белән упкынга ыргыталар.

А ю. Бетте явыз дошман.

Б о е к т ө н б о е к. Котылдык. Котылдык! Тик ни сәбәпле Инсан батырның йөзе сагышлы?!

И н с а н. Күзләрем урман кызы гүзәл Таңсылуны күрми. Әй Җилҗилә! Урман хәбәрчесе Җилҗилә! Күрмәдеңме урман кызы Таңсылуны?

Еракта Җ и л җ и л ә тавышы ишетелә.

Җ и л җ и л ә. Беләм, һәр таң саен күрәм мин: Таңсылукай — ак болыт, ил гизә болыт булып.

Болан. Әнә ул, әнә ак болыт! Безнең турыга тукталды.

Инсан. Җилҗилә! Җитез канат Җилҗилә... Туктат син ак болытны, коткар син Таңсылуны.

Җилҗилә. Гөлдән аркан үрегез, очын миңа бирегез.

Инсан. Үрмәле гөл билбавым! *(Билбавын чишә, Җилҗиләгә бирә.)*

Җилҗилә, билбауның бер очын тотып, күккә оча.

А ю. Куып җитте ак болытны.

Боек төнбоек. Бәйләде гөл бавына, тартыйк, әйдә, тартыйк! *(Җырлый-җырлый тарталар. Берберсен билләреннән кочып, Таңсылу белән Җилҗилә очып төшәләр.)*

Таңсылу. Дусларым! Туганнарым! *(Кочаклашып күрешәләр. Күмәк бию, бәхет бәйрәме башлана.)*

Таңсылу. Илдә бөек бәйрәм, бәхет бәйрәме. Бу бәхетне безгә бүләк иткән Акылгали кайда?

Барысы бергә. Акылгали, син кайда?.. Син кайда, Акылгали?

Инсан. Җавап бирми. Бәлки... Бәлки, ул һәлак булгандыр. Безнең өчен, Гөлстан иле өчен.

Таңсылу. Юк, мөмкин түгел. Акылгали үлемсез.

Боек төнбоек. Мин хәзер... Гөлләр-чәчәкләр белән үз телебездә — чәчәкләр телендә сөйләшеп карыйм. Бәлки, алар беләдер.

Таш өстендә үскән бер чәчәк янына килеп, сүзсез генә бик матур бер көй көйли. Икенче, өченче чәчәккә бара. Ниһаять, Акылгали кабере өстендәге чәчәк аңа җыр белән җавап бирә.

Боек төнбоек. Акылгали исән. Тик ул... Җитмеш потлы таш астында. Инде нишлибез? Ул харап булыр.

Барысы, бергәләп, кабер өстенә бастырылган ташны этәләр.

А ю. Бер, ике, өч...

Болан. Кузгала, кузгала! Тагын бераз гына... Бераз гына көч җитми.

Боек төнбоек. Тик бераз гына кузгатыгыз! Мин таш астына керәм.

Инсан. Якын килә күрмә. Харап булырсың, сытылырсың.

Боек төнбоек. Курыкма, Инсан батыр. Без болай гына зәгыйфь күренәбез. Бездә яшәү көче, тереклек көче. Без мәрмәр ташларны да тишә алабыз. Әйдәгез, туганнарым!

Барлык чәчәкләр, төнбоеклар таш астына керәләр һәм, күмәк көч белән, ташны кубарып ыргыталар. Таш астыннан Акылгали чыга.

Акылгали. Сәлам сезгә, Карурман балалары! Сәлам сиңа, Инсан батыр!

Барысы бергә. Ил агасы, Җир баласы Акылгалигә сәлам!

Инсан. Инде... Илегез имин, табыныгыз түгәрәк. Миңа китсәм дә ярыйдыр. Фатихаңны бир, ил агасы!

Акылгали. Тукта, адәм улы Инсан. Сиңа сүзем бар. Син гыйбрәтле хәлгә шаһит булдың. Елгалардан агу акканын, чишмәләр кипкәнне күрдең. Бу җиһанда әле дә этбаш-сыераяклар бетмәгән. Гөлстанга тагын да зуррак афәтләр килүе мөмкин. Бу кырлар, бу

урманнар, бу гөлчәчәкләр барысы да синең яклауга мохтаҗлар. Аларның һәлакәте — синең һәлакәтең. Аерылма син алардан, ташлама аларны.

Боек төнбоек. Китмә, Инсан, китмә син,
Без — нәни төнбоеклар.
Без — урман чәчәкләре —
Җирнең киләчәкләре.

Барысы бергә. Уйлашыйк без, бергәләп,
Ил язмышы турында.
Китмә, кеше, китмә син,
Язмышың үз кулыңда.

Акылгали *(залга карап)*. Язмышың үз кулыңда!

Пәрдә.

Габделхәй Сабитов.

Автор Гөлстан исемле бик матур ил турында яза. Андый ил юк. Шулай булгач, автор уйлап тапкан гөлләр илендә яшәүчеләр дә безгә таныш персонажлар түгел. Анда аю да, болан баласы да, төнбоеклар да, чәчәкләр дә, җил дә кешечә сөйлиләр, бар да игелекле, шәфкатьле, бар да үзләренең туган илләрен яраталар.

?! **1.** Гөлстан иленең автор күз алдында тоткан мәгънәсен табыгыз. Аны бер генә сүз белән әйтегез.

2. Таңсылу: «Мин кеше түгел»,— ди. Кем ул? Таңсылу турында сөйләгез.

Таңсылу аша автор безгә нидер әйтә. Нәрсә әйтә?

3. Әсәрдә төп геройларның берсе — Инсан. Инсан — Җир шарындагы барлык кешеләрне гәүдәләндерүче кеше дигән сүз. Табигать вәкилләре аның Гөлстан илендә калуын телиләр. Бу үтенечтә авторның безгә әйтәсе нинди теләге бар?

4. Әсәрдә Гөлстан иленә ярдәмгә килүче Акылгалинең кем булуын исеме әйтеп тора. Гали — барысыннан да өстен дигән сүз. Акылгали ни өчен җиңелми?

5. Гөлстан илен харап итүчеләр — кешеләр, ләкин алар кешеләргә бик аз охшаганнар. Алар ни өчен исемнәре белән дә, кылган эшләре белән дә кешеләргә охшамаганнар?

6. Гөлстан иленең киләчәге нинди булырга тиеш? Җавап әсәрнең исемендә. Ай сукмагы турындагы җырны, табып, кабат укысагыз, әсәр исеменең мәгънәсен белә аласыз. Белегез.

КӨМЕШ ТОЯК.

Безнең заводта Кокованя кушаматлы бер карт бар иде. Бу карт, гаиләсендә үзе генә калгач, тәрбиягә бер ятим бала алмакчы була. Сез шундый бала белмисезме дип, күршеләреннән сораштыра.

Күршеләре аңа:

— Күрше авылда Григорий кызы ятим калды. Шуны алып кайт,— дип, киңәш бирәләр.

— Мин Григорийны да, хатынын да белә идем. Икесе дә шат күңелле, җитез генә кешеләр иде. Кызлары да ата-анасына тарткан булса, аның белән яшәү күңелсез булмас. Килергә ризалашса, кызны алып кайтыр идем, — дип шатлана карт.

Күршеләре:

— Тормышы бик авыр, ничек килмәсен, килер. Бар да үзе белән сөйләш! — диләр.

Бәйрәм көн иде. Кокованя әлеге ятимә янына китте. Килеп керсә, өй эче бала-чага һәм олылар белән шыгрым тулы. Кызчык мич янында, ә аның алдында бер көрән песи утыра. Кызчык кечкенә генә, песи дә бик кечкенә: шундый ябык, шундый йолкыш, рәтле кеше андый песине өенә дә кертмәс иде. Кокованя кызчыкка карады да:

— Шушымы инде Григорийның бәләкәй кызы? Йә Бүләккыз, минем белән яшәргә телисеңме? — дип сорады.

Кызчык гаҗәпкә калды:

— Син, бабай, минем исемем Бүләккыз икәнен каян белдең соң?

— Шулай инде, үзеннән-үзе беленде. Сорашмадым, белешмәдем, кыек атып туры тидердем.

— Ә син үзең кем соң, бабай? — дип сорады бала.

— Мин аучы,— диде карт,— җәен, ком юып, алтын җыям, кышын урманнарда кәҗә тәкәсе эзләп йөрим, тик әле һаман да очрата алмыйм.

— Очратсаң атар идеңме?

— Юк,— диде Кокованя,— гади кәҗәләрне генә аулыйм мин. Арада бик чибәре бар, анысын күрәсем генә килә. Алгы уң аягы белән кай төшкә типкәнен күрәсем килә.

— Нигә кирәк ул сиңа?

— Ә менә миңа кучсәң, барын да сөйләрмен,— диде Кокованя.

Кызчыкның кәҗә тәкәсе турында күбрәк беләсе килде. Аннары ул кунакны яратып та өлгерде: ягымлы кеше иде бабай.

— Кучәм. Ләкин песиемне дә алыйк. Кара нинди матур песи,— диде Бүләккыз.

— Шундый шәп мырлый торган песине ничек монда калдырасың! Алып китик, балалайка урынына тотарбыз,— диде Кокованя.

Песи үзе турында сөйләшкәнне аңлап тора диярсең, аякка сырпаланып мыр-мыр итә.

— Дөр-рес әйтәсең, дөр-рес,— дип сөйләнә.

Кокованя үзе зур, үзе сакаллы, ә кыз кеп-кечкенә, борыны төймә хәтле генә. Менә алар урам буйлап бара, артларыннан йолкыш песи ияргән.

Шулай итеп, бергә-бергә гомер итә башладылар болар. Әллә ни бай яшәмәделәр, ләкин шулай да зарланмадылар. Барысы да эшләделәр.

Кокованя иртән хезмәткә китә, Бүләккыз өй җыештыра, аш-су әзерли, Мырмырау ауга йөри, тычкан тота. Кичләрен бергә җыелалар, өчесенә дә күңелле була.

Карт әкиятләр сөйләргә оста. Бүләккыз әкиятләр тыңларга ярата, ә Мырмырау алар янында мырылдаудан туймый:

— Дөр-рес әйтә, дөр-рес,— ди. Ләкин, әкият сөйләгән саен, Бүләккыз карттан:

— Бабай, теге кәҗә тәкәсе турында сөйлә инде, нинди соң ул? — дип сорый торган булды.

Баштарак Кокованя сөйләмәскә төрле сылтау табып килде, соңыннан сөйләп бирде:

— Гаҗәп тәкә ул. Аның алгы уң аягында көмеш тояк. Шул тояк белән кай төшкә типсә, шуннан кыйммәтле таш килеп чыга. Бер типсә — бер таш, ике

типсә — ике таш, ә инде тыпыр-тыпыр итеп торса, кыйммәтле ташлар өем-өем килеп чыга.

Карт ник сөйләгәненә үкенде. Чөнки, шул көннән башлап, кәҗә тәкәсе Бүләккызның теленнән төшмәде.

— Бабай, зурмы ул?

— Юк, буйга өстәлдән биек түгел, аяклары нечкә, башы җип-җиңел.

— Бабай, аның мөгезләре бармы?

— Аның мөгезләре бик гайрәтле. Гади кәҗә тәкәләренең мөгезе ике генә япьле була, ә моның мөгезләре биш япьле.

— Бабай, ә аның йоны ни төсле?

— Җәй көне көрән, безнең Мырмыраунныкы төсле, ә кышын соры була.

Кыш җитте. Кокованя ауга җыена башлады.

— Бу салкында урманда ничек кунарсың, бабай?

— Бер аланлыкта кышкы өем бар. Бик яхшы өй, мичле, тәрәзәле...

— Көмеш тояк та шул якта йөриме?

— Кем белсен аны. Бәлкем, шул яктадыр.

— Бабай, ал мине дә үзең белән. Анда өйдә генә утырырмын. Көмеш тоякны күрәсем килә. Бәлки, килеп чыгар...

Башта карт бик нык каршы торды:

— Юк! Юк! Кыш көне кечкенә кызга урманда йөрү ярый торган эш түгел! Чаңгыда барырга кирәк анда, ә син йөри белмисең, карга батарсың. Туңарсың.

Бик ялынып сорагач, алай да Бүләккызны алып китәргә риза булды.

Кокованя бәләкәй чанага ике капчык сохари һәм башка кирәк-яраклар төяде. Бүләккыз, курчагына күлмәк тегәр өчен, чүпрәк-чапрак, бер йомгак җеп, энә, бер кисәк бау алды.

«Шушы бау белән Көмеш тоякны тотып булмасмы?» — дип уйлады.

Песиен калдыру бик кызганыч булды, ләкин нихәл итәсең? Кыз, киткәндә, песиенең аркасыннан сыйпап сөйләнде:

— Мырмырау, без бабай белән урманга барабыз, ә син өйдә кал, тычкан тот. Көмеш тоякны күргәч, без кайтырбыз. Кайткач, мин сиңа барын да сөйләрмен.

Песи хәйләкәр генә карап мыр-мыр итте:

— Дөр-рес әйтәсең, дөр-рес.

Кокованя белән Бүләккыз юлга чыктылар. Бөтен күрше-күлән шаккатты:

— Акылдан язган бу карт! Шундый кеп-кечкенә кызны кыш көне урманга ияртеп китте бит! — диделәр.

Бүләккыз белән Кокованя авылдан чыкканда, никтер этләр өрә башлады. Шундый өрәләр, шундый чиныйлар, әйтерсең урамда берәр ерткыч күргәннәр. Бүләккыз белән карт артларына әйләнеп караганнар иде, исләре китте: урам уртасыннан Мырмырау чаба. Этләр шуңа өрәләр икән. Өрәләр, ә якын килергә куркалар. Шундый зур, шундый таза ул хәзер.

Бүләккыз песине, тотып, өйләренә кайтарып куймакчы булган иде дә, кая ул тоту!

Алар урманда өчәү тора башладылар. Бүләккыз мактанып куйды:

— Болай күңеллерәк,— диде ул. Кокованя аның сүзен җөпләде:

— Билгеле, күңеллерәк.

Ә Мырмырау мич кырыена йомарланып яткан җиреннән:

— Дөр-рес әйтәсең, дөр-рес,— дип мырлый бирде.

Бу кышны урманда кәҗә тәкәләре күп иде. Ләкин гади тәкәләр иде алар. Кокованя көн саен бер-икене алып кайтып торды. Тәкә тиресе һәм тозлаган ит шулхәтле күп җыелды, бәләкәй чана белән генә тартып кайтырлык булмады. Бүләккыз:

— Бабай, авылдан ат алып килер идең. Тозлаган итне өйгә кайтарып куярга кирәк бит,— диде.

Кокованяның исе китте:

— Нинди акыллы бала син! Олы кешеләр кебек уйлыйсың. Үзең генә калырга курыкмассыңмы соң?

— Курыкмыйм. Безнең өебез нык ич: бүреләр җимереп керерлек түгел. Минем янда Мырмырау да кала.

Кокованя кайтып китте. Бүләккыз Мырмырау белән калды. Көндезләрен, бабай кәҗә аулап йөргән чакта, ялгыз утырырга күнеккән иде инде ул. Караңгы төшкәч, бераз шикләнә башлады. Ә Мырмырау тып-тыныч ятты. Бүләккыз моны күреп тынычланып китте. Тәрәзә каршына барып утырды. Болын ягына караган иде — урман эчләтеп кәҗә тәкәсе чаба. Аяклары неп-нечкә, башы җип-җиңел, мөгезе биш япьле... Бүләккыз, тәкәне карарга дип, тиз генә йөгереп чыкты, ләкин берни дә күрә алмады.

— Ахры, йокымсырап киткән булганмын да төшемдә күргәнмен,— дип уйлады. Мырмырау мыр-мыр итеп куйды:

— Дөр-рес әйтәсең, дөр-рес.

Бүләккыз песи янына сузылып ятты да таң атканчы йоклады.

Икенче көн үтте. Кокованя килмәде. Ямансу булып китте Бүләккызга, ләкин еламады. Мырмыраунының аркасыннан сыйпый-сыйпый сөйләнде:

— Моңайма, песи! Иртәгә бабай килеп җитәр.

Ә Мырмырау җырлады да җырлады:

— Дөр-рес әйтәсең, дөр-рес.

Бүләккыз тагын тәрәзә каршына килеп утырды, йолдызларга сокланып карап торды. Ятарга җыенганда, кинәт стенада тыпыр-тыпыр иткән тавыш ишетелде. Тыпырдау икенче як стенада, аннары тәрәзәле стенада, аннары ишекле стенада, аннары түбәдә ишетелә башлады. Бик каты да тыпырдамый: җиңел генә, тиз генә берәү йөридер кебек. «Кичәге кәҗә тәкәсе килде микән әллә?» — дип уйлап алды Бүләккыз.

Шулхәтле күрәсе килде аның кәҗә тәкәсен, хәтта куркуын да басты. Ишекне ачып караса, каршында кәҗә тәкәсе басып тора! Алгы уң аягын күтәргән — менә хәзер тибеп куяр кебек, аягындагы көмеш тоягы елтыр-елтыр итә. Мөгезе дә биш япьле. Бүләккыз нишләргә белмичә аптырап торды да өй кәҗәсен чакырган шикелле:

— Кәҗ-кәҗ! — дип эндәште. Кәҗә тәкәсе көлеп җибәрде. Аннары борылды да урманга чапты. Өйгә

кергәч, Бүләккыз күргәннәрен Мырмырауга сөйләде.

— Дөр-рес сөйлисең, дөр-рес,— диде Мырмырау.

Өч көн үтте. Кокованя юк та юк. Кыз курка башлады. Күзләренә яшь тулды. Песи белән сөйләшмәкче булды, ләкин Мырмырау өйдә юк иде. Бүләккыз песине эзләргә чыгып китте.

Урман эченә керү белән, песиен күрде. Әнә ул Мырмырау! Әнә! Үзе генә булса бер хәл иде әле, янында Көмеш тояк та басып тора!

Мырмырау башын чайкый, тәкә дә чайкый. Аннары алар алан буйлап чабып уйный башладылар. Тәкә чаба-чаба да, туктап, тоягы белән җиргә тибә; песи аның янына йөгереп килгәч, тәкә икенче урынга

чабып китә, бераз чапкач, тагын, туктап, тоягы белән тибенә башлый. Песи белән тәкә шактый озак чабышып уйнадылар. Аннары күздән югалдылар. Бераздан өй янына килделәр.

Менә бервакыт кәҗә тәкәсе түбәгә сикереп менде дә тоягы белән түбә тактасына тибәргә тотынды. Тып итеп китереп бәрә — аяк астыннан очкын кебек кыйммәтле ташлар сибелә. Тагын бәрә — тагын сибелә! Ташлар кызыл, яшел, зәңгәр, сары, тагын әллә нинди, әллә нинди матур төсләргә кереп җемелди.

Кайткач, Кокованя үз күзенә үзе ышанмады: өе кояштай балкып тора! Уңда да асылташлар, сулда да асылташлар! Ә Көмеш тояк түбәгә тибүен туктатырга уйлап та карамый.

Ул арада Мырмырау да түбәгә сикереп менде. Менә ул тәкә янына килде дә мыраулап җибәрде. Мырмырау белән Көмеш тояк кинәт юкка чыктылар.

Кокованя бүрегенә кыйммәтле ташлар тутырды.

— Бүген җыймыйк, бабай! Иртәгә дә карарбыз, бик матур бит,— дип ялынды Бүләккыз.

Кокованя каршы килмәде.

Төн буе кар яуды. Таң алдыннан Бүләккыз белән карт урамга чыгып өйләренә карасалар — өйләре морҗаларына кадәр ап-ак карга күмелгән! Карны көрәп түбә тактасына хәтле җиттеләр, ләкин кичәге асылташларның берсен дә таба алмадылар. Хәер, аларга кичә Кокованя бүрегенә җыйганы да бик җиткән иде.

Бүләккыз белән картның шатлыклары эчләренә сыймады. Мырмырау гына кызганыч. Шул китүдән

әйләнеп кайтмады. Көмеш тояк та кабат күренмәде. Ләкин тәкә чабып йөргән аланда кешеләр кыйммәтле ташлар таба башладылар. Аларның күбесе, яшел төстә булып, хризолит дип атала иде.

Сезнең шундый таш күргәнегез бармы?

Павел Бажов.

Таулар да туалар, үсәләр, картаялар. Урал тавы — дөньядагы башка тауларга бабай. Иң өлкән яшьтәге тау. Шуңа күрә аның эче тулы байлык. Ни генә юк анда! Тимер белән бакыр бар да бар инде. Көмеш, алтын дисеңме, алмазмы... Әйтәм бит, булмаган нәрсә юк анда. Урал тавының тагын бер зур байлыгы — кыйммәтле ташлар. Ул ташларның төсләрен күрсәгез иде!.. Бик сирәк тауда гына була Уралдагы кебек затлы асылташлар... Менә шундый матур, бай як ул Урал.

«Көмеш тояк» хикәятенең авторы Павел Бажов әнә шунда туган. Эшчеләр белән аралашып үскән. Эшчеләр, ял иткән арада, әкият сөйләргә яратканнар. Ә әкиятләре аларның Урал кешеләре, Уралның табигате турында булган.

Кечкенә Павел әкиятләрне бик яратып тыңлаган. Барысын да хәтерендә калдырырга тырышкан. Әкият яраткан кеше табигатьне дә ярата. Павел гомере буена Урал ягының табигатен дә, кешеләрен дә ныклап өйрәнгән. Шул күзәтүләренә миф вакыйгаларын да, әкият геройларын да, үз хисен, теләген, акылын да кушып, әсәрләр язган. Бик матур әсәрләр. Әсәрләрен **хикәятләр** дип атаган.

«Көмеш тояк» хикәятендә миф вакыйгасы да бар. Типкән саен кыйммәтле ташлар коя торган Көмеш тояк, яхшылыкка яхшылык белән җавап бирә торган песи кебек әкият геройлары да катнаша. Ә иң әһәмиятлесе: алар барысы да автор мәхәббәтенә төрелгәннәр. Көмеш тояк белән песинең яхшылыгына автор зур бәя бирә.

?!

1. Картка бәя бирегез.
2. Бүләккызга бәя бирегез.
3. Песигә бәя бирегез.
4. Хикәятнең мифлар белән охшашлыгын күрсәтегез.
5. Автор теләген табыгыз.

КЫШКЫ ТӨН.

Кышкы төндә ай җыр суза,
Айда — йолдызлар дәрте,
Челтәрле чыршылар моңы,
Шәрә таллар хәсрәте.

Салкын айның яктысында
Ак каеннар моңлана,
Өзелми калган яфраклар
Туңудан калтырана.

Кышкы төн — гаҗәп күренеш,
Табигатьнең бер сере,
Урман, айның, йолдызларның
Җырга әйләнгән төре.

Флёра Тарханова.

?! 1. Автор ай җыры турында язган. Исбат итү өчен, сүзләрнең урыннарын алыштырып, шигырьне үз сүзләрегез белән сөйләргә кирәк.

2. Шигырьне дәвам итегез. Болай башлагыз: *Кышкы таңда кояш җыр суза:*

Кояш җырласа, аның җырында ниләр ишетергә теләр идегез?

ИПЕКӘЙ.

Бала, теле ачылганда, иң башлап кайсы сүзне әйтә: «әннә» диме, әллә «мәм-мәм» дип әйтәме?.. Ачык кына хәтерләмим, әмма кайсын гына башлап әйтмәсен, «әннә» белән «мәм-мәм» — адәм баласының иң беренче сүзләре, шушы сүзләр белән аның теле ачыла. Ана һәм ризык. Ризык — адәм баласы өчен ана шикелле үк иң зарури[1], иң кадерле нәрсә.

Ана — җан бирүче, ә ризык — яшәтүче. Ана белән ризыктан башка Җир йөзендә тереклек булмас иде. Күрәсез, бу ике төшенчәнең мәгънәсе һәм әһәмияте никадәр тирән, никадәр зур!

Ризык дигәнебез ул,— барыннан да элек, икмәк. Икмәк барлык ризыклардан өстен тора, бик күп ризыклар икмәктән башлана, икмәккә кайтып кала. Без иртәнге чәйдә май белән йомырка ашыйбыз икән, болар да — шул ук икмәк аркасында алдыбызга килгән ризыклар.

Тагын шуны да әйтергә кирәк: моннан күп мең еллар элек... кыргый икмәкне табигатьтән иң элек

---

[1] Зарури — кирәкле.

хатын-кызлар табып алалар һәм әкренләп үстерә башлыйлар. Чөнки ирләр ауга йөргәннәр, кыргый хайваннар тотканнар, үстергәннәр, ә хатын-кызлар ашарга яраклы төрле үләннәр, тамырлар җыйганнар. Шулай итеп, бодай, арпа, кукуруз кебек икмәк азыкларын алар тапкан, алар шуларны, игәргә ярарлык культура хәленә китереп, тормышка кертеп җибәргән. Бу да бик гыйбрәтле факт: безне тудырган ана безгә икмәкне табып бирүче дә икән әле!

?! **1.** Укып чыккан өлеш нәрсә турында? Язып куегыз.

Минем үземә икмәкнең нәрсә икәнен кече яшьтән үк белергә туры килде. Мин 1921 нче елның коточкыч ачлыгын күреп уздырдым. Ләкин ул ачлык елда күргәннәрне мин язып тормыйм инде — алар җан тетрәткеч дәрәҗәдә авыр һәм фаҗигале[1] булды. Нәкъ менә шул чакта инде борынгы мәкальнең дөреслеге бөтен тирәнлеге белән ачылды: «Алтынкөмеш — таш, имеш, алабута — аш, имеш!..» Әйе, шулай икән шул. Икмәк бөтен байлыклардан да кирәгрәк, кыйммәтлерәк нәрсә икән. Икмәк булмаса, бөтен нәрсәнең — иң затлы[2], иң бәяле әйберләрнең дә — кыйммәте бетә, алар чүпкә әйләнә.

Безнең татар халкында исә икмәккә хөрмәт аеруча зур иде. «Ипекәй» дип кадерләп кенә йөртә иде ул аны... Әгәр урамда ипи сыныгы ятканын күрсә, ул аны, иренмичә иелеп алып, читәнгә яки бүрәнә

---

[1] Фаҗигале — кайгылы, үкенечле.

[2] Иң затлы — яхшы.

ярыгына кыстырып китә. Балаларга да, сыныгыңны калдырма, валчыгыңны җый, бәрәкәт[1] очмасын, дип әйтеп кенә торалар. Һәм без ипи валчыгын таптаудан чынлап та курка идек, икмәк безгә рәнҗер, бездән китәр, килмәс дип шомлана идек... Хәзер андый шомланулар бетте, әмма хөрмәт калырга, хөрмәт сакланырга тиеш.

...Икмәкне кешеләр тир түгеп табалар. Икмәк үстерү — авыр эш, бик күп хезмәт, тәҗрибә, тырышлык сорый ул...

Әмирхан Еники.

?! 2. Әсәрнең соңгы өлеше нәрсә турында?

БОРЫН.

Бер малайның борыны башта нәни генә, матур гына була. Дуслар, шундый борынлы малайны мактап:

— Бик әйбәт малай ул,— диләр, — борыны аның күтәрелми дә, төшми дә.

Малай борынын тотып карый, басып карый, тартып карый да, үз борынына үзе сокланып:

Мондый борын барлыгын
Белмәгән идем бер дә!
Миндә икән ул борын,
Кирәк кадерен белергә! —

дип җырлап җибәрүенә... борын күтәрелә дә китә!

---

[1] Бәрәкәт — бетмәс-төкәнмәс муллык, барлык.

— Абау, моның борыны бигрәк күтәрелгән! — диләр дуслары. Малай борынын тотып карый, басып карый, тартып карый, ләкин борынының күтәрелүен сизми. Шуннан соң ул:

— Дусларым мине юри мыскыл итәләр,— дип, зур кайгыга бирелүе белән... борыны төшә дә башлый! Дуслары бу юлы:

— Карагыз әле, малайның борыны төшкән ич! — дип гаҗәпсенәләр.

Малай борынын тотып карый, басып карый, тартып карый, төшкәнен сизми, ләкин:

— Борыным сәламәт түгел, ахры,— дип, табибка йөгерә.

Табиб аның борынын тотып карый, басып карый, тартып карый һәм, борынының бер күтәрелеп, бер төшеп торуын сизеп, малайга ике төрле дару бирә.

Идрис Туктар.

?!

1. Малайның борыны нигә күтәрелә? Нигә төшә?
2. Табиб малайга нинди дару бирә?

АРТТЫРУ АЛЫМЫН ӨЙРӘНИК.

Арттыру алымы — язучыларның иң яраткан алымнарыннан берсе. Ләкин арттыруның да төрлесе була. Алар арасындагы аерма җир белән күк арасы кебек. Аерманы безнең борынгы бабайлар да бик яхшы белгәннәр. Борынгы кешеләр кабилә-кабилә яшәгәннәр. Алар үзләренә башлык сайлый торган булганнар. Кайчакта сайлау уңышсыз булып чыккан. Ялгышып бик надан кешене сайлап куялар икән. Ләкин борынгы бабайлар башлыкларыннан куркып тормаганнар. Тотканнар да аның турында миф уйлап чыгарганнар.

Мәсәлән, менә мондый мифны.

НАДАН ЮЛБАШЧЫ.

Нау-Сами исемле борынгы бер кешене башлык итәләр. Ләкин ул надан булып чыга. Берзаман юлбашчыга йорт салалар икән. Төзүчеләр юлбашчыдан:

— Йортыңны биек итикме, тәбәнәк итикме? — дип сораганнар.

— Югарырак күтәрегез дә түбәнрәк төшерегез,— дигән башлык.

Беркөнне башлык бакчасыннан шалкан алып керергә кушкан.

— Аскы бүлбесен алмагыз, яфракларының тышын әрчеп кертегез,— дигән.

Башлык мифта әйткәнчә үк ахмак булмаган, билгеле. Миф авторларының аны адәм көлкесенә калдырасылары килгән. Алар начарның дәрәҗәсен тагын да начаррак итеп күтәргәннәр. Оялыр да акылга утырыр дип ышанганнар. «Күрдегезме, наданлык дәрәҗәсен адәм ышанмаслык итеп арттырдык»,— дигәннәр.

Нәтиҗә ясыйк.

Арттыру алымы борынгы мифларда ук көлү алымы хезмәтен үтәгән. Борынгы бабайларның оныклары

уйларга искиткеч сәләтле булып үскәннәр. Әйтемнәр, мәкаль, җыр, әкиятләр иҗат итә башлаганнар.

Борынгыларның оныкларына арттырып көлү алымы бик ошаган. Алар, бу алымнан файдаланып, әллә никадәр әйтемнәр уйлап чыгарганнар.

Алдына китергәнне ашамыйча киреләнеп утыручы нәзберек балага, *аша, майласаң, иске чабата да үтә,* дигәннәр. Куркак балалардан, *үз күләгәсеннән дә курка,* дип көлгәннәр. Мактанчыкны, *үз бүрегем астында үземнән шәп кеше юк,* дип үртәгәннәр.

Ә кеше ни әйтсә, шуны үтәп йөрүче баланы, *кешенең кечесе булганчы, этнең көчеге бул,* дип мыскыл иткәннәр.

Ләкин шул ук вакытта, уңган, тырыш балаларны мактар өчен дә, матур-матур арттырулар уйлап чыгарганнар. *Тырышканның тукмагы да ташка чөй кага. Уңган кыз кар өстендә аш пешерә,* дигәннәр.

Мактауны бөтен кеше ишетсен өчен:

Агыйделнең аръягында
Бар кылган далалары;
Диңгез айкый, тау күчерә
Замана балалары,—

дип җырлап җибәрә торган булганнар.

Ә бераздан арттыру алымының матурлык һәм хәсрәт дәрәҗәсен күрсәтү өчен дә менә дигән алым булуы ачыклана:

Агыйделдән агып килә
Ак чыршы бүрәнәсе;
Йөзләрендә нурлар уйный,
Янында күләгәсе.

Агыйделләрдә пароход
Китәргә дип хут алган;
Эчләремне генә түгел,
Тышларымны ут алган.

?! Әйтем һәм җырларда арттыру алымын табыгыз.

Арттыру алымы тора-бара мифлардан әйтем һәм җырларга, әкиятләргә күчкән.

СОҢГЫ ПИЛМӘН.

Безнең авылда шактый саран бер малай яшәгән. Яшь булуына карамастан, әллә никадәр баланы алдарга өлгергән. Алдап, хәйләләп, аларның әйберләрен үзләштергән.

Берзаман авырып киткән бу. Уң якка әйләнеп яткан, сулга әйләнгән, авыз эченнән генә нидер мыгырдаган. Энесе, якын килеп:

— Абый, нәрсә әйтмәкче буласың? — дип сораган.

— Сүзем юк. Тыныч кына үлә алмыйм, борчуым бар,— дигән абыйсы.

— Борчуыңны әйт,— дигән энесе.

— Әбиләргә барган идем. Әби пилмән пешергән иде. Соңгы пилмән тәлинкә төбендә калды.

— Нигә соң пилмәнеңне кашыкка алмадың? — дип сораган энесе.

— Кашыкта бер пилмән бар иде шул. Соңгысы сыймады.

— Кашыктагысын авызыңа кабарга иде.

— Авызда да бер пилмән бар иде инде.

— Анысын йотып җибәрәсең калган.

— Йота алмадым. Тамак төбендә тагын бер пилмән бар иде,— дигән саран малай.

?! 1. Әкиятне бик җитди итеп сөйләгез. Тыңлаучыларга кызык булсын өчен, пилмәнен йота алмаган малайны кызганган булыгыз.

2. Әкият авторы, кешенең бер сыйфатын арттыра-арттыра, безне кисәтә. Ничек кисәтә?

БЕР АГАЙ.

Борын-борын заманда булган, ди, бер агай. Аның булган, ди, бер хатыны, ике кызы, бер танасы, бер көчеге. Агай җәй көннәрен иген үстереп, ашлыгын суктырып, тегермәндә арыш, бодай тарттырып гомерен уздыра икән, ди. Ә кыш көне кырыктартмачы булып, сату итеп, өяздә йөри икән. Агай сатасы әйберен сатып баеп кайтканда, аны танасы мөгрәп, көчеге өреп каршы ала икән, ди.

Әтиләрен озаткач, әниләре олы кызын инешкә суга җибәргән, ди. Кыз, чиләген тутырып су алганда, миләш агачының кып-кызыл булып пешкән ботагы инешкә таба кәкрәеп үсеп утырганын күреп уйга калган, ди: «Мин кияүгә барсам, малаем белән әтиләргә кунакка килсәм, минем малаем да, шушы миләшкә кызыгып, агачка менәр дә, ботагы сынып, инешкә батып үләр»,— дип елап утыра икән бу.

Бик озак кызы кайтмагач, әнисе: «Бар әле, кызым, апаең нишләп озак тора икән?» — дип, кече кызын инеш буена җибәргән, ди. Барып җитсә, апасы елап утыра моның.

— Нишләп елап утырасың? — дип сорауга, апасы үзенең нигә елавын сөйләп биргән.

— И апай, синең артыңнан мин дә кияүгә китәрмен, миңа да килер бит бу хәлләр,— дип, икәүләшеп елый башлаганнар болар.

Ике кызы да кайтмагач, әниләре үзе киткән болар артыннан. Барса, ни күрсен, ике кызы да елап утыра икән. Кызлар үз хәлләрен сөйләп биргәннәр икән, өчәүләп елый башлаганнар болар. Бераз шулай утыргач, әниләре әйткән: «И кызларым, болай елап утырып булмый, әйдә, кайтыйк та ул балаларның өчесен, җидесен, кырыгын укытып куйыйк»,— дип өйгә кайткач, балаларның өчесен, җидесен, кырыгын укытырга дип, тананы суеп, аш әзерләп, мәҗлес уздырганнар, ди. Шул тананың сөяген кимергәндә, тамагына сөяк кадалып, көчек тә үлеп киткән, ди.

Агай, сәүдәләрен уңышлы үткәреп, баеп, капкасын ачып керсә, ни гаҗәп: тана да мөгрәмәгән, көчек тә өреп чыкмаган моның каршысына. Хатынынннан сорашкан, хатыны булган хәлне сөйләп биргән, ди. Агай бик ачуланып, сезнең шикелле җиде тиле тапсам, өйгә әйләнеп кайтырмын дип чыгып киткән, ди.

Бара агай, бара, ди. Бара торгач, бер авылга җитте, ди. Шул авылда бер кешенең бер өйгә, бер келәткә йөгерә-йөгерә йөргәнен карап тора да, янына килеп: «Ни эшләр бетереп йөрисең?» — дип сорый бу.

Теге кеше әйткән:

— Менә солы кисәле пешергән идем, кисәлем өйдә казанда, тозы keləттә. Мин шул кисәлне ашыйм,— дигән.

— Синең болай йөреп ашап тамагың туймас, мин сиңа ансат ашау юлын өйрәтим, күпме бирәсең?— дигән.

Теге кеше:

— Күпме сорасаң, шуны бирермен,— дигән.

Агай кисәлне казаннан табакка бушатып, келәттәге тозны, чүлмәге белән өйгә кертеп, боткага салган да, менә хәзер аша инде, дигән. Теге кеше шуның өчен моңа йөз тәңкә акча биргән, ди.

Бу тагын юлга чыгып киткән, ди, акчасын кесәсенә салып.

Бара торгач, бер авылга барып керсә, бер йорт янында халык җыелган. Болар бер үгезне өстериләр икән, шау-шу килеп. Агай карап торган да сораган болардан:

— Бу үгезне кая алып барасыз, нигә болай шаулыйсыз? — дип. Теге кешеләр әйткәннәр, ди:

— Өй түбәсенә печән үскән, шуны ашатырга дип, үгезне шунда менгерәсе идек, үгез киреләнә, менми,— дигәннәр.

— Мин сезгә шул эшне ничек эшләргә кирәген өйрәтсәм, күпме бирәсез? — дигән.

— Күпме сорасаң да бирер идек, булыш кына,— дигәннәр тегеләр.

Агай бер урак алган да, ди, түбәгә менеп, печәнне урып алып, үгезнең алдына китереп салган, ди.

Агай болардан да йөз сум акча алып чыгып киткән, ди, үз юлы белән.

Шулай барганда, бер өй эчендә дөбердәгән, елаган тавышлар ишетелгән моңа. Бу өйгә барып керсә, бер хатын яңа теккән ыштанны бөрмәсеннән тотып, балакларын ачып тотып тора, ди, ире мич башыннан сикереп төшеп, ыштан балагына туры китереп кимәкче була, кия алмый икән. Ире: «Син аякларын тегә белмәгән»,—дип, хатынын кыйный икән, хатыны елый икән, ди. Агай, бу хәлне күреп:

— Бу ни эшләвегез, икегезгә бер акыл юкмыни, күпме бирәсез, үзем өйрәтәм,— дигән.

— Күпме сорасаң да бирер идек,— дигәннәр болар. Агай бу кешене эскәмиягә утырта да, ыштанын киертеп, йөз сум акчаны алып, тагын үз юлы белән китә, ди.

Бара торгач, бер кешенең кулына иләк тотып бер өйгә кереп, бер тышка чыгып йөргәнен күргән дә, аның янына барып: «Бу ни эшләр бетереп йөрүең?» — дип сораган икән, бу кеше:

— Менә өй салган идем дә, өем караңгы булды, яктыны ташый идем, яктыны тотып ала торган әмәл юк, гаҗиз булдым инде,— дип зарланган, ди.

— Күпме бирәсең, үзем өйрәтәм,— дигән агай.

— Сораганыңны бирер идем, өйрәтсәң,— дигән теге. Агай балта белән пычкы алган да өйгә тәрәзәләр тишеп биргән. Аннан йөз сум акчаны алып тагын чыгып киткән бу.

Шулай юл белән бара торгач, бер авылда бер йорттан хатын-кызлар чыелдашкан тавышлар ишет-

кән бу. Шул өйгә килеп керсә, анда аулак өйгә җыелган хатын-кызлар икән, ди. Бу кызлар аякларына чәмчәле[1] читекләр кигәннәр дә, аякларын сәкегә сузып утырып, чигү чигәләр икән, ди. Йокларга вакыт җиткәч, торып китим дисәләр, аякларын таный алмыйча, «бу минеке» дә, «бу минеке» дип чыелдашалар икән болар.

— Бу ни эшегез, чибәр кызлар? — дигән агай.

Кызлар хәлне сөйләп бирәләр моңа, аякларын таныткан өчен, акча да бирергә риза булалар.

Агай ишегалдына чыга да, бер күсәк алып кереп, һәммәсенең дә аякларына суккан икән, кызлар шыпырт кына барысы да үз аякларын тартып алганнар, ди.

Агай бу йөз сумны да кесәсенә салып, йөри-йөри арып, өенә кайтып киткән, ди. Өенә кайткач, хатынына әйткән, ди: «Бу дөньяда сезнең төсле җүләрләр күп икән, барысына да йөреп бетерә алмассың, янчыгым тулды да өйгә әйләнеп кайттым»,— дигән.

Алып кайткан акчаларын санап, бер тана сатып алган, бер кәчек алган да калган акчасы белән гадәтенчә тагын кырыктартмачы булып, сату-алу эшләре белән йөри башлаган, ди. Сатудан баеп кайткан саен, яңадан танасы мөгрәп, кәчеге өреп каршы ала башлаганнар, ди, моны.

Әле дә булса рәхәтләнеп яшиләр, ди, болар.

---

[1] Чәмчә — кунгә чигеп төшерелгән бизәк.

?! **1.** Әкият авторы уйлап эшләмәүчеләрдән көлә. Аларның ахмаклык дәрәҗәсен бик нык арттыра. Шул урыннарны елмаймыйча, сәхнәдән сөйләгән кебек сөйләгез.

Истә тотыйк: көлке әсәр сөйләүче үзен бик җитди тотарга тиеш.

2. Уйлап табуы шактый кыен булган арттыруларны әйтегез.

КАРАКОШ ҺӘМ ЧҮЛ.

Еракта, Кытайның көнбатыш ягында, иге-чиге күренмәгән моңсу чүлдә ялгыз бер Каракош яшәгән. Тирә-якта җансыз ком сахрасы җәелеп ята, анда бер генә куак әсәре дә, чишмә заты да юк икән.

Бервакыт Каракош биеккә-биеккә күтәрелгән дә, куәтле канатларында талпынып, тирә-ягына горур караш ташлаган.

Шулчак көнчыгышта дулкынланып яткан очсыз-кырыйсыз зәңгәр диңгез, ә төньякта тынып калган карт кара урман күргән. Көнбатышта салават күперендәй нурланып кичке шәфәкъ уйный икән, көньякта хәтфә кебек яшел болыннар җәелгән, ди.

«Минем туган ягым нинди ярлы, нинди күңелсез! Монда да тулы сулы елгалар аксын, бакчалар күкрәп үссен иде»,— дип уйлаган Каракош.

Әмма көнчыгыштагы зәңгәр диңгез бик ерак икән.

«Көнбатышка очсам да, көньякка очсам да, барыбер берничә көн очарга туры киләчәк»,— дигән Каракош.

Шулай да китәргә карар кылган. Көн очкан, төн очкан, берзаман, арып-талып, Диңгезгә килеп җиткән. Диңгез әйткән моңар:

— Нигә шулай ашыгасың? Өстемдә озаграк очып әйлән. Байлыкларымны кара. Патшалыгымның зурлыгын күр. Нинди генә утраулар, нинди генә балыклар юк анда! Син, бәлкем, күк күкрәвен, давыл кубуын яратасыңдыр? Бераз гына көт, аларын да күрерсең. Төн җиткәч, рәхим ит, берәр тау куышына бар да йокла, хәл җый.

— Сау бул, Диңгез, мин иртәгә килермен,— дигән Каракош. Авызына су капкан да күккә күтәрелеп кайтырга чыккан.

Төньяктагы Кара урман да дәшми калмаган:

— Дускай, беразга гына булса да кал монда. Тиздән караңгы төшә. Кунып кит. Әллә сиңа бу тирәләр ошамыймы? Минем халкым гади, киң күңелле. Җырларга, биергә ярата. Аю белән, мәче башлы ябалак белән таныштырырмын үзеңне. Берничә көн кунак бул. Яфраклар ышыгында төн үткәрү нинди рәхәт булуын белсәң иде син! Күзләреңне йомарга да өлгермисең, әйтеп бетергесез татлы төшләр күрәсең,— дигән.

Тик Каракош шул ук җавапны биргән:

— Сау бул, Урман! Иртәгә килермен,— дигән. Томшыгы белән ботак сындырып алган да урман өстен бер урагач кайтырга юнәлгән.

Шулчакны Шәфәкъ, Каракошка нәфис кулларын сузып, шыпырт кына:

— Кил яныма, без синең белән бии-бии күккә күтәрелербез, аннан беркайчан да җиргә төшмәбез. Бергә яшәве шундый күңелле булыр! — дигән.

— Сау бул, Шәфәкъ! Син, чыннан да, бик гүзәл! — дигән Каракош һәм, Шәфәкъне калдырып, өенә ашыккан.

Язның үзе кебек матур көньяк болыннары, Каракошны каршы алып:

— Нишләп күренеп кенә китәсең, безнең янга төш,— дигәннәр. Каракош аларга да:

— Тиздән күрешербез, сау булыгыз,— диюдән узмаган.

Үзенең ком оясына кайткач, Каракош йоклый алмаган. Көндезге эшләре турында уйланган да уйланган. Мондый минутларда үзенә үзе сөйли икән бу:

— Әйе, бик авыр эшкә тотындым мин! Эшлисең, эшлисең, ә ахыры күренми. Сүз дә юк, көнбатыш та, көнчыгыш та, төньяк та, көньяк та бик матурлар. Тик мин үземнең буш сахрамнан — аның салкынча кичләреннән, дәрт уята, хәл кертә торган иртәләреннән ничек аерылыйм, ди! Юк, карарым бер генә: мин бу чүлгә диңгезнең суын, урманның яшеллеген, шәфәкъ алсулыгын, яз гүзәллеген күчерәм. Бәлкем, миннән көләрләр, шулай да үз теләгемә ирешми калмам. Минем туган чүлемдә дә чишмәләр челтерәп агар, урманнар шаулар. Хәзергә бу хыял гына әле; тик шул хыялны тормышка ашыруда, дәртле хезмәттә күрәм мин бәхетемне!

Каракош һәр таңны эш белән каршы алган.

?! Әкиятне дәвам итегез.

Каракош турында язу өчен, без аңа автор салган мәгънәне белергә тиеш.

Автор Каракошка кеше сыйфатлары биргән. Ләкин шул ук вакытта кошның үз сыйфатларын да саклап калган. Эшебезне шул сыйфатларны барлаудан баш-

лыйк. Мондый нәтиҗә ясыйбыз: әкиятнең без язасы дәвамында да төп герой кош һәм шул ук вакытта кеше дә булырга тиеш. Димәк, ул оча да, уйлый да, ярата да ала.

Әкияттә тагын чит җирләрдә яшәүчеләр һәм Каракошның үз илендә яшәүчеләр катнаша. Алар барысы да Каракошка бәя бирәләр. Катнашучылар бәясен искә төшерәм. Араларында сокланучылар да, Каракошны кызганучылар да, аңардан көлүчеләр дә бар. Димәк, минем язмада алар да катнаша ала.

Әкият ахырында Каракош нишли? Эшен дәвам иттерәме? Арып туктыймы?

Эшен дәвам иттерсә, башкалар аңа нинди бәя бирә? Туктаса, нинди бәя бирә?

Менә хәзер нәрсә язасын беләбез. Хәтта мондый план да төзеп куябыз:

План.

1. Каракошның эше.
2. Катнашучыларның баштагы бәясе.
3. Катнашучыларның соңгы бәяләре.

ТӨЗ АТЫЛГАН ЯДРӘ.

Италиядә алтын-көмешкә күмелеп, рәхәт чигеп яши башладым. Әмма мин мондый тыныч, ваемсыз тормыш өчен яратылган кеше түгел шул. Озакламый тагын төрле маҗараларны сагындым. Шуңа күрә, Италиядән ерак та түгел инглизләр белән испаннар арасында сугыш чыкканын ишеткәч, бик куандым.

Минутны да әрәм итмичә, атка сикереп атландым да сугыш кырына җилдердем.

Испаннар Гибралтар дигән инглиз крепостен камап алганнар икән. Мин камалыштагы инглизләр янына үтеп кердем.

Крепостьтагы гаскәрләр белән командалык итүче генерал күптәнге дустым иде. Ул мине кочак җәеп каршы алды һәм үзе төзеткән ныгытмаларны күрсәтергә алып китте. Чөнки минем бик файдалы киңәшләр бирүемә ышана иде.

Гибралтар стенасына басып, күзәтү торбасы аша каршы якны тикшерергә керештем. Күрәм: испаннар тупларын нәкъ без басып торган урынга төзәп маташалар.

Шунда ук бирегә зур туп китереп урнаштырырга куштым.

— Нигә кирәк ул? — дип сорый генерал.

— Хәзер күрерсез! — дим.

Тупны дошман тубының көпшәсенә каратып төзәдем дә, испан тупчысы утлы факелын алга сузуга, бар тавышыма команда бирдем.

Ике туп бер үк вакытта атып җибәрделәр.

Нәкъ мин уйлаганча килеп чыкты: ике ядрә һавада коточкыч көч белән бер-берсенә килеп бәрелделәр. Дошман ядрәсе кирегә очты.

Төшенәсезме: испаннарга таба очты.

Испан тупчысының һәм тагын уналты солдатның башын кыеп төшерде.

Аннары яр буенда торган өч корабның мачтасын бәреп аударды да туп-туры Африка ягына очып китте.

Шуннан соң, тагын өч йөз-дүрт йөз чакрым узып, иске генә бер крестьян йортының түбәсенә барып төште.

Ул йортта бер карчык яши икән. Чалкан ятып, авызын ачып йоклаган чагы булган. Минем ядрә түбәне тишеп төшкән дә карчыкның нәкъ авызына барып кергән, мескенкәйнең соңгы тешен бәреп сындырган. Аннары тамагына ук кереп утырган.

Шунда бу карчыкның карты кайтып кергән. Ул кулын карчыгының авызына тыгып, ядрәне алырга тырышып караган, әмма урыныннан да кузгата алмаган.

Карт бик башлы һәм тапкыр кеше икән. Минутын да әрәм итмәстән, бер чеметем вак тәмәке алган да карчыгының борын төбенә китергән, карчык шундый хәтәр төчкереп җибәргән, хәтта ядрә тәрәзәне ватып, урамга ук чыгып очкан.

Менә нинди афәтләр китерде испаннарга үзләре аткан ядрә.

Безнең ядрә шулай ук бушка китмәде. Ул испаннарның хәрби корабына барып тиде һәм аны, ике йөз матросы белән бергә, су астына олактырды.

Шулай итеп, минем тапкырлык аркасында инглизләр бу сугышта җиңеп чыктылар.

— Рәхмәт сиңа, дустым Мюнхгаузен! — диде генерал, кулымны кысып.— Әгәр син булмасаң, без беткән идек! Бу гүзәл җиңүебез өчен сиңа бурычлыбыз.

— Монда искитәрлек нәрсә юк! — дидем мин аңа.— Дусларыма ярдәм итәргә мин һәрвакыт әзер.

Бу хезмәтләрем өчен генерал миңа полковник дәрәҗәсе бирмәкче иде дә үтә тыйнак кеше буларак баш тарттым.

Эрих Распе.

1. Әсәрне бер кат уку белән үк, вакыйгаларны хәтерләргә өйрәник: укып чыккач, китабыгызны ябыгыз. Дәфтәрләрегезгә Мюнхгаузен арттырып сөйләгән урыннарны языгыз. Күпме табуыгыздан чыгып, үзегезгә билге куегыз.

2. Хикәяне икенче кат укымагыз. Бер минут эчендә андагы вакыйгаларга күз йөртеп кенә чыгыгыз. Җавабыгызда төшеп калган арттыру алымнарын өстәп языгыз. Үзегезгә тагын бер тапкыр билге куегыз.

КУРЧАК БАТЫР.

Борын-борын заманда
Шушы безнең Казанда
«Әби» атлы карчык белән
«Бабай» атлы карт булган.
Ләкин менә боларның
Булмаган, ди, уллары,
Булмаганга уллары
Йөргәннәр, ди, хурланып.
Карт әйткән: «Әйдә, карчык,
Камырдан курчак ясыйк,
Шуны бала итеп сөеп,
Хәсрәтебезне басыйк».
Беркөн әби камырдан
Курчак ясап калдырган,
— Карт,— дигән,— син буярсың,
Күзләр ясап куярсың,

Ә мин кәзәкиләрен,
Күлмәкләрен тегәрмен.
Бабай курчакны, буяп,
Мичкә кибәргә куя.
Әби кипкәнен көтә,
Киемнәрен киертә.
Сөрмә тартып кашына,
Куялар мич башына.
Болар йокларга ята,
Курчак килеп уята.
Бу курчакка җан кергән,
Ир малайга әверелгән.
— Карыным ачты, әни, ди,
Ашатыгыз мәми,— ди,
«Ләхәүлә!» — дип тәкеренеп,
Әби уяна элек.
Сикереп торып, бабай да
Карап тора малайга.
Бәби һаман: «Мәми, ди,
Тизрәк ашат, әни!» — ди.
Әби, торгач аптырап,
Бер кабартма каптыра.
— Ашатасыз бик аз, ди,
Миңа кирәк бер каз, ди,
Сарык булса да ярый,
Ул да азрак миңа,— ди.
Әби дә һәм бабай да
Шаккаталар малайга.
Тотынган ул үсәргә,
Башы тигән түшәмгә.

Өч яшь тулды дигәндә
Сыймый башлый өйгә дә.
Тиңсез була көчкә дә,
Батыр була эшкә дә.
«Утын кирәк»,— дисәләр,
Бер имәнне кисә дә,
Җилкәгә салган көйгә,
Күтәреп кайта өйгә.
Типсә, җирне яра, ди,
Елга булып кала, ди.
Әби дә һәм бабай да
Шаккаталар малайга.
«Курчак батыр» дип аңар
Алар исем куйганнар.
Әйбәт булган бу батыр.
Үзе булган бик матур.

Кеше хәтерен саклаган,
Сәлам биргән картларга,
Начар сүзләр әйтмәгән,
Һичкемне рәнҗетмәгән.
Ил халкы бик яраткан,
Макталган ул һәр яктан.
Менә нәкъ шул заманда
Бер хәл була Казанда:
Тик торганда югала
Көн саен дүрт-биш бала.
Кабан күле төбеннән
Чыгып һәр көнне төнлә,
Йотып тора икән, ди,
Аларны бер крокодил...

Бари Рәхмәт.

?! **1.** Крокодил һәр көнне дүрт-биш бала йота. Ул аларны ни өчен йота? Крокодилга балаларның нинди сыйфатлары ошамаска мөмкин?

2. Безнең батыр, әлбәттә, аларны коткара. Ничек коткара ала?

3. Әсәрдә арттырылган урыннарны эзләп табыгыз.

МИШКА ПЕШЕРГӘН БОТКА.

Җәй көне без әни белән дачада ял иттек. Безгә кунакка Мишка килде. Мишканы бик тә сагынган идем. Әни дә шатланды.

— Килеп бик яхшы иткәнсең,— диде әни.— Бергә-бергә күңеллерәк булыр. Иртәгә шәһәргә дә барасым бар иде. Үзегез генә ике көн тора алырсызмы?

— Әлбәттә, торырбыз,— дидем мин.

— Үзегез аш пешерә алырсызмы?

— Пешерербез,— ди Мишка.— Аны да булдырмагач!

— Ярар, алайса, аш белән ботка пешерерсез. Ботканы пешерү дә ансатрак.

— Боткасын да пешерербез. Ашын да. Ботка да пешермәгәч... — диде Мишка.

— Синең пешергәнең юк ич,— дидем.

— Борчылма! Әнинең ничек пешергәнен күргәнем бар минем. Ачтан үлмәссең әле, туйдырырмын. Телеңне йотарлык итеп пешерермен...

Николай Носов.

?! Дуслар ботканы ничек пешергәннәр? Хикәяне дәвам итегез. Мөмкин кадәр кызыграк итеп арттыра-арттыра языгыз.

ДЖЕЛЬСОМИНО ЯЛГАНЧЫЛАР ИЛЕНДӘ.

Бу тарихны Джельсомино миңа үзе сөйләде. Аның белән сөйләшә башлаганчы ук, колакларыма ярты килолап мамык тутырган идем. Ярдәме тимәде диярлек. Тыңлап бетергәнче барыбер чак кына чукракланмый калдым. Эш шунда: Джельсоминоның тавышы бик көчле. Хәтта шыпырт кына сөйләшкән чакта да аны диңгез өсте тигезлегеннән ун мең метр биеклектә очкан реактив самолёт пассажирлары ишетә.

Джельсомино хәзер — танылган җырчы. Аны бар җирдә — Төньяктан алып Көньяк полюска кадәр беләләр! Ул үзенә яңгыравыклы һәм купшы исем дә уйлап тапкан. Әмма бу кадәресен әйтеп торуның хаҗәте юк, чөнки сез аны газеталарда йөз тапкыр очраттыгыз инде.

Менә шул. Гап-гади бер малай иде Джельсомино. Хәтта буйга кайбер малайлардан кечерәк тә булгандыр әле. Әмма дөньяга килгән минуттан ук аның табигать тарафыннан табигый булмаган тавыш белән бүләкләнүен белделәр.

Джельсомино төнлә туды, һәм тирә-юньдәге халык, завод гудоклары эшкә дәшә дип белеп, урыннарыннан сикерешеп торды. Әмма бу нибарысы Джельсомино тавышы гына иде. Дөньяга килгән балаларның һәркайсы үз тавышын шулай сынап карый бит! Бәхеткә, газета хәбәрчеләре белән төнге каравылчылардан кала барлык кешелекле кешеләр кебек үк, Джельсомино тиз арада кичтән таңга кадәр тәмләп йокларга өйрәнде. Аның тавышы төп-төгәл

иртәнге җидедә, нәкъ менә кешеләр эшкә барыр өчен йокыларыннан уяныр вакытта чыга иде. Хәзер инде, кирәге калмаганлыктан, гудокларны чүплеккә чыгарып ташладылар.

?! **1.** Әсәрнең укыган кадәресен үз сүзләрегез белән сөйләргә план төзегез. Мәсәлән, башта автор укучыларын герое белән таныштыра. Шуңа күрә планны болай башлыйбыз:

1. Танышу.
2. (Дәвам итегез.)

Алты яшен тутыруга, Джельсомино мәктәпкә китте. Дәресне укытучы исемлек тикшерүдән башлады. Тиздән «Д» хәрефенә килеп җитте.

— Джельсомино! — диде. Малай, шатланып:

— Мин монда! — дип җавап кайтарды, һәм көтмәгәндә дөбердәгән тавыш ишетелде — сыйныф тактасы, яргаланып, кыйпылчык өеменә әверелде.

Чырае кырысланган укытучы кулына күрсәткеч таяк алды. Кырыс тавыш белән:

— Тактаны кайсыгыз ватты? — дип сорады.

Җавап кайтаручы булмады.

— Ярар, исемлекне тагын бер кабатларбыз, алайса,— диде укытучы. Ул яңадан «А» хәрефеннән башлады. Һәр укучыга да сорау бир иде:

— Ташны син ыргыттыңмы?

— Ю-ук, м-мин түгел...— диештеләр куркынган малайлар.

Укытучы «Д» хәрефенә яңадан килеп җиткәч, Джельсомино да урыныннан торды:

— Мин түгел, синьор...

Әмма ул «укытучы» сүзен өстәргә өлгерми калды — такта үрнәгендә тәрәзә пыялалары да коелышып төште. Укытучы бу юлы сыйныфны игътибар белән күзәтте: кырык баланың берсендә дә рогатка юклыгына иманы камил иде.

«Урамдагы берәрсенең этлегедер бу, мөгаен,— дип уйлады ул.— Дәрестә утырасы урында, берәр ташбаш рогатка белән кош ояларын туздырадыр. Чыгып тотыйм гына, колагыннан сөйрәп полициягә илтәм әле мин аны».

Ул иртәдәге маҗаралар шуның белән төгәлләнде. Әмма укытучы икенче көнне дә исемлек тикшерә башлады һәм тагын Джельсомино исеменә килеп җитте.

Яңадан мәктәпкә килүенә куанган малай, горур гына як-ягына каранып:

— Мин монда! — дип кычкырып җибәрде. «Чалтырррр-чолтыррр-зың-зың-зың!»— дип җавап кайтарды тәрәзә пыялалары. Әле ярты сәгать элек кенә мәктәп караучы куеп чыккан пыялалар зыңгылдап-чылтырап урамга коелды.

— Гаҗәп эш,— диде укытучы,— синең исемгә җитүгә, сәер хәлләр башлана. Ә-ә, аңлашылды, егеткәем! Тавышың чамасыз көчле синең! Син кычкыра башлауга, давыл сымаграк нәрсә куба. Әгәр дә мәктәп белән авылыбызны бөлдерергә теләмәсәң, бүгеннән сиңа пышылдап кына сөйләшергә туры килер. Килештекме?

Джельсоминоның битеннән кайнар күз яшьләре акканын күреп, укытучы малай янына килде һәм ягымлы итеп аның башыннан сыйпады:

— Сүзләремне яхшылап тыңла, улым. Бу тавышың сиңа йә бихисап бәла-каза, йә искиткеч олы бәхет китерер. Ә хәзергә мөмкин кадәр азрак файдалан син аннан. Дәшми торган өчен моңарчы берәүне дә әрләгәннәре юк әле. Сүзең көмеш булса, дәшмәвең алтын икәнлеге бар кешеләргә дә билгеле.

Шушы көннән Джельсомино тәмуг газаплары кичерә башлады. Яңа казалар тудырмас өчен, ул мәктәптә авызын кулъяулык белән томалап утыра торган булды. Укытучы аңардан дәресләрен мөмкин кадәр сирәгрәк сорарга тырышты. Джельсомино гаҗәеп укучы булганлыктан, аның дәресләрне яхшы белүенә тамчы да шикләнми иде ул.

Өйгә кайткач, Джельсоминоның мәктәптә алган тәэсирләре белән уртаклашасы килде. Әмма, берьюлы дистәләгән савыт-сабаның көлен күккә очыргач, өйдә шулай ук аңа катгый рәвештә авыз ачмаска боердылар.

Күңелен бушатыр өчен, Джельсомино авылдан кая да булса читкәрәк — урман-болыннарга, басукырларга яисә күл буена чыга торган булды. Ирекккә чыга да, тирә-юньдә пыяла тәрәзәләр юклыгына ышангач, чалкан ятып, рәхәтләнеп җырлап җибәрә. Берничә минуттан табигать җанлангандай була: сукыр тычканнар, кырмыска, күбәләк курчаклары — кыскасы, туфракта һәм җир өстендә яши торган барлык кош-кортлар белән киек җанварлар, җир тетри дип белеп, кайсы кая чабыша, кача башлыйлар.

Шулай үсте малай, тиздән үсмер егет булып җитеште... Үсеп ныгый төшкәч, мәктәбен ташлап,

крестьян хезмәте белән көн күрә башлады. Әгәр дә күңелсез бер хәлгә тарымаган булса, мөгаен, ул бөтен гомерен авыл җирендә уздырган булыр иде. Миңа да әллә ни язып торырлык нәрсә калмас иде, шәт. Нинди вакыйгага соң ул, дисезме? Анысын хәзер белерсез.

?! **2.** Өзекне үз сүзләрегез белән сөйләгез.
3. Аңа исем уйлап табыгыз.

Беркөнне Джельсомино, бакчаларына чыккач, грушаларның тәмам өлгергәнен күрде. Шундый нәрсә инде ул груша дигәннәре: ым да, шым да юк алардан, ә үзләре шыпырт кына өлгерә, пешә бирәләр. Гаҗәеп матур таңнарның берсендә бакчагызга чыгып карасагыз — шаккатасыз: грушаларыгыз тәмам өлгергән! Джельсомино белән дә шул хәл. «Кызганыч, баштан ук баскыч алып киләсе калган икән,— дип уйлады ул.— Менә хәзер өйгә кайтырга туры килә инде. Кайткач-кайткач, озынрак колга да алып килми ярамас — анысы иң өстәге грушаларны бәреп төшерергә кирәк булыр».

Нәкъ шул минутта аның башына шаян бер фикер килде: «Тавышны сынап карасам ни булыр?» — дип уйлады ул.

Уйлавы булды, әллә уйнап, әллә чынлап, груша төбендә кычкырып та җибәрде:

— Әй сез, грушакачкайларым, коелыгыз! — Шәпшәп! Шап-шоп! — дип җавап бирделәр аңа өлгергән җимешләр һәм, яңгыр сыман шыбырдашып, җиргә коелдылар.

Джельсомино, икенче агач янына килеп, тагын шуны ук кабатлады. «Коелыгыз!» — дигән саен грушалар, шуны гына көткән кебек, ботакларыннан үзеләə һәм шыбырдашып җиргә коела тордылар. Джельсомино куанды.

«Моңа мин тамчы да көч түкмәдем,— дип уйлады.— Кирәк бит, тавышның колганы да, баскычны да алыштыра алуын моңа кадәр белми йөргәнмен!»

?! 4. Бу өзекне дә үз сүзләрегез белән сөйләгез. Кыскартып сөйләгез. Аңа исем уйлап табыгыз.

Джельсомино грушаларын җыеп йөргән арада, аны янәшә бакчадагы күршесе күреп алды. Күзләрен уды, борын очын чеметте, тагын бер мәртәбә яхшылап карады да, күргәннәре төш булмавына ышангач, җан-фәрманга өйләренә чапты.

— Минемчә, безнең күрше — явыз сихерче! — диде ул хатынына, куркуыннан калтырана-калтырана.

Хатыны Джельсоминога карады да:

— Син нәрсә, атасы? Игелекле тылсымчы ич бу! — диде.

— Ә мин әйтәм, явыз сихерче, дим!

— Ә мин әйтәм, игелекле тылсымчы!

— Әйдә, күршеләрне чакырабыз. Алар да күрсен. Аннан соң тыңлап карарбыз. Ни әйтерләр бит әле... — диде ире.

Бу фикер хатынының күңеленә хуш килде.

Кич җиткәнче әлеге хәлләрне бөтен авыл халкы белеп өлгергән иде инде. Фикер икегә бүленде: берәүләре Джельсоминоны игелекле тылсымчы дип

куәтләсә, икенчеләре явыз сихерче дип бәхәсләштеләр. Бәхәс, җилле көнне күтәрелгән диңгез дулкыннарыдай, көчәйгәннән-көчәя генә барды. Бәхәсләшә торгач, ызгыш чыкты, кайберәүләргә хәтта имгәнергә дә туры килде. Әйтик, крестьяннарның берсе үз төрепкәсенә пеште, чөнки, бәхәс белән мавыгып, ул аны авызына ялгыш утлы башы белән капкан иде. Полицейскийлар исә, кемнең хаклы, кемнең хаксыз икәнлеген аерып әйтә алмаганлыктан, берәүне дә кулга алмадылар. Бары тик, бер төркемнән икенчесенә йөреп, аларны таралышырга өндәделәр.

Иң хәтәр бәхәсчеләр Джельсомино бакчасына юнәлде.

— Менә ул изге тылсымчы! Менә!

— Нинди тылсымчы булсын, ди! Явыз сихерче бу! Күрмисезмени! Сихерле чиләк ич аның кулында!

— Юк дигәч, юк инде! Изге ул, изге!

— Без, Джельсомино, барысын да күреп тордык. Грушаларга син өлгерергә боердың — алар өлгерде, коелырга куштың — алар коелды.

— Акылдан яздыгызмы әллә? — диде Джельсомино.— Минем тавышым сәбәпче ич моңа! Мин кычкырган чакта, һава давылдагы сыман котырына, бары тик шул гына...

— Әйе, әйе, без беләбез,— дип кычкырды бер хатын. — Тылсымлы тавышың белән могҗизалар тудырасың син!

— Бернинди дә могҗиза түгел. Сихер бу!

Джельсомино кулындагы чиләген җан ачуы белән җиргә күтәреп бәрде дә, өенә кереп, ишеген бикләде.

?! **5. Өзекне үз сүзләрегез белән сөйләгез. Аңа исем уйлап табыгыз.**

«Менә тыныч тормыш дигәнең шулай бетеп тә куйды,— дип уйлады ул.— Алардан башка адым да ясап булмас хәзер, койрык сыман тагылып йөрерләр. Кичләрен сүз бары тик минем хакта гына булыр. Тыңлаусыз балаларны минем белән куркыта башлаячаклар. Юк, булмый болай. Моннан китүең хәерлерәктер, мөгаен. Аннан килеп, бу авылда миңа ни калган? Әтием белән әнием вафат булдылар. Дусларым сугышта шәһит киттеләр. Дөнья буйлап сәфәр чыксам, бәлки, тавышым ярдәмендә бәхетемне табармын. Җырлаган өчен, кайбер кешеләргә хәтта акча да түлиләр икән дип сөйлиләр бит».

Шундый карарга килеп, ул барлы-юклы мөлкәтен биштәренә тутырды да урамга чыкты. Төркемдәгеләр шаулашып алдылар да егеткә юл бирделәр. Джельсомино берәүгә дә күтәрелеп карамады.

«Саубуллашу хөрмәтенә бер шаяртыйм әле»,— дип уйлады да, тирәнрәк сулап, бар көченә кычкырып җибәрде:

— Са-ау бу-улы-ыгы-ыз! Ху-ушы-ыгы-ыз! Ху-ушы-ыгы-ыз!

Үз гомерендә беренче тапкыр эшләгән шушындый наянлыгыннан ул рәхәтләнеп көлә иде.

Баш киемнәре белән париклар[1], очып барган кошлар төркемедәй бөтерелә-бөтерелә, болытларга

---

[1] Париклар — ясалма чәчләр.

кадәр күтәрелделәр дә тора-бара бөтенләй күздән югалдылар.

Соңрак аларның әллә ничә чакрымнар очып баруы, кайберләренең хәтта ил чигенең аргы ягына барып чыгуы мәгълүм булды.

Берничә көннән Джельсомино шулай ук чик сызыгын узды һәм... дөньядагы иң сәер илләрнең берсенә барып чыкты.

Джанни Родари.

?! **6.** Соңгы өзекне дә үз сүзләрегез белән сөйләгез. Аңа исем бирегез.

7. Авторның арттырып сөйләгән вакыйгаларын табыгыз.

ХӘРӘКӘТ ОХШАШЛЫГЫ.

Кузгалу, көчү, гамәл, вакыйга.

Әдәби әсәрдәге хәрәкәт белән сез беренче сыйныфта ук танышкан идегез. Искә төшерик. Без сезнең белән теләсә нәрсәне өлешләргә бүләргә остарып беттек. Хәрәкәтне дә бүлик.

Менә сез дәрестә укытучыгыз сөйләгәнне тыңлап утырасыз, ди. Сез, билгеле инде, тәртипле балалар. Тыныч кына тыңлап утырасыз. Ә хәзер, бик кыен булса да, үзегезне кыбырсык бала итеп күз алдына китерегез әле. Юкны бар итү бик кыен ул, алай да бер генә минутка башка бер бала булып алыгыз.

Менә сез артка борылып карадыгыз. Балалар нигә дәрестә артка борылып карыйлар? «Менә мин, күрдегезме мине?» — дип, бераз гайрәтләнү өчен шулай итәләр. Сезнең теләк тә шундый.

Сез хәрәкәт иттегез. **Кузгалдыгыз. Сезнең торыш үзгәрде.**

Кыбырсык бала үзенә үзе хуҗа була беләме? Аны мактану теләге гел ашкындырып тора. Шуңа күрә сез икенче якка яисә артка борылып карыйсыз. «Бу якта утыручылар да мине күрәләр микән?» — дип борчыласыз. Сез тагын кузгалдыгыз. Тагын бер тапкыр борылып карадыгыз. Кузгалулар бер-берсенә охша-

ды. Сезгә балаларның күз ташлаулары ошады. Ләкин укытучыга сезнең матур теләгегез ошамады. Менә ул сезне бастырды да: «Мин нәрсә турында сөйлим?» — дип сорады. Үзегез булсагыз, сез, әлбәттә: «Хәрәкәт темасын искә төшерәбез»,— дип шартлатып җавап биргән булыр идегез... Ләкин сез әлегә үзегез түгел — мактанчык малай дип сөйләштек бит. Шуңа күрә укытучы сезне иң арткы партага күчереп утыртты.

— **Бер урыннан икенче урынга күчү дә — хәрәкәт,**— диде... Монысы сезгә бик авыр хәрәкәт булды. Гадәт буенча, артка борылып карыйсыз, ә анда стенадан башка берни юк. Сезнең батырлыкны берәү дә күрми. Сул якка борылып карыйсыз — анда да стена гына. Шулай ике-өч тапкыр борылганнан соң, йә елап җибәрәсез, йә тыңларга мәҗбүр буласыз. Укытучының сүзләрен ишетәсез, ул **үзгәрү дә хәрәкәт** булуын аңлата. Ләкин сез дәрес башында сөйләгәнне ишетмәдегез, шуңа күрә үзегездәге үзгәрешнең хәрәкәт булуын аңламый калдыгыз. Нәрсә үзгәрде соң? Сез кыбырсык бала булып уйнаудан баш тартасыз. Минем кабат үзем булып үзгәрәсем килә, дисез. Дөрестән дә, кемнең үз ирке белән берәү дә яратмый торган кыбырсык буласы килсен!

Хәзер, кабат үзебез булып, укуны дәвам итик. Әлеге кыбырсык баланың күчеп утырулары, артка караулары кузгалу гына түгел, катлаулырак хәрәкәт булды. Шундый **тәмамланмаган хәрәкәткә эпизод** диярга гадәтләнгән идек. Аны, татарчалатып, **гамәл** диярга дә була.

Искә төшерик.

Тәмамланган хәрәкәткә **вакыйга** диләр. Ә әсәрдәге вакыйга **сюжет** була. Ләкин сюжет, гадәттә, берничә вакыйгадан төзелә.

?! 1. Керештә кемнәр катнаша?

2. Керешне кузгалу, күчү, гамәл, вакыйга атамалары хәтердә калырлык итеп укыгыз. Китабыгызны ябыгыз да эчтән генә үзегезгә үзегез сөйләгез.

3. Кыбырсык укучы эпизодын, тәмамлап, вакыйга итегез.

ТУГАННАР МӘХӘББӘТЕ.

Закирга укытучы шундый сорау биргән:

— Синең абыең бакчадан ун алма алып чыкты, ди. Шуларның өчесен үзенә алды да калганнарын сиңа бирде, ди. Әйт әле, абыең сиңа ничә алма биргән була?

Закир кашларын җимереп утырды да башын селкеде, ди:

— Бирде, ди! Кетәрсең ул саранннан шулчаклы алма!

Укытучы елмаеп куйды да башкача итеп сорады, ди:

— Алайса, абыең түгел, син алып чыктың, ди, ун алма. Үзеңә өчне калдырдың. Абыеңа ничә алма биргән буласың?

Закир янә башын селкеде, ди: ...

?! Закир җавабы — мәзәкнең икенче өлеше. Ул укытучыга нинди җавап биргән?

ИКЕ БӘТИ.

Безнең кәҗә күптән түгел
Китерде ике бәти.
«Бәтиләрне сөзешергә
Өйрәтмә!» — диде әти.

Аны гына мин дә беләм,
Тик ярамас өйрәтми —
Миңа елап кайта торган
Җебек бәти кирәкми!

Сөзгәч-сөзгәч сөзсен инде,
Җиргә егарлык итеп,
Мөгезләре бәрелгәндә,
Очкын чыгарлык итеп...

...Хәзер шундый сөзешәләр,
Ничек түзә башлары?
Хәтта берсе үземне дә
«Тәгәрәтә» башлады.

Беркөн әллә сүз берләшеп
Куйганнар инде шунда,
Икәүләшеп аунаттылар
Үземне тузан-комда!

Авыз җәеп елап кердем:
— Бүген дә сөзде бәти-и-и...
— Миңа елак ул кирәкми!
Дип көлде миннән әти...

Җәүдәт Дәрзаман.

?! Охшаш вакыйгаларны табыгыз. Аларның әсәрдә каршылык тудыруын аңлатыгыз.

ТУКРАНСАКАЛ.

Бер корольнең бердәнбер кызы булган, ди. Аның бер дә килмәгән җире юк, шундый чибәр, шундый сөйкемле җан, ди. Тик ул бик тәкәббер, бик масаючан булган, бер генә егетне дә үзенә тиң күрмәгән, ди. Кодалап килгәннәрне кире борып җибәргән, өстәвенә әле мыскыл итеп калган.

Шулай берзаман король бик зур мәҗлес җыйдырган. Кызын яучылаган егетләрнең якын-тирәдәгеләрен дә, ерактагыларын да — барысын-барысын да чакырткан, ди.

Үзенә ошаганын сайлап алсын өчен, король кызын шул саф алдыннан уздырган, ди. Ләкин кыз егетләрнең һәркайсыннан нинди дә булса җитешсезлек тапкан, ди. Гәүдәгә тулырак булганыннан: «Сыра мичкәсе!» — дип көлгән, буйга озынрагын: «Урманда үскәнмени, шөкәтсез колга!» — дип гаеп иткән. Тәбәнәгенә: «Үзе карсак, үзе юан, каян килгән пәһлеван!» — дигән. Аксыл чырайлысын: «Гүрдән чыккан өрәк!» — дип мәсхәрәләгән. Алсу йөзлесен: «Горур күркә»,— дип мыскыллаган, бераз бөкрәебрәк утырганын: «Мич башында киптерелгән утын агачы»,— дип кимсеткән, ди. Шулай итеп, егетләрнең барысыннан да бер җитешсез як тапкан, ди. Бүтәннәргә караганда күреклерәк, әмма сакалы очлаеп торган яшь корольдән дә: «Карагыз әле моның сакалына, тукран томшыгымыни!» — дип рәхәтләнеп көлгән. Шуннан

соң әлеге корольгә «Тукрансакал» дигән кушамат тагылып калган, ди.

Кызының шулай барысын да үчекләп, мәҗлеснең ямен җибәрүенә, егетләрне үзеннән биздерүенә корольнең яман да ачуы чыккан. «Мин ул тәкәбберне ишектән кергән беренче хәерчегә кияүгә бирәчәкмен!» — дип ант иткән, ди.

Шушы хәлләрдән соң берничә көн үткәч, сарай тәрәзәсе каршына бер хәерче килеп баскан да, бераз хәер-сәдака бирмәсләрме икән, дип җырлый башлаган. Урам җырчысының тавышын ишеткәч, король хезмәтчеләренә:

— Шул хәерче монда керсен әле,— дигән, ди.

Бүлмәгә кием-салымы теткәләнеп, пычранып беткән әлеге җырчы килеп кергән. Ул корольгә, аның кызына атап, бер җыр җырлаган. Аннары:

— Мәрхәмәтле галиҗәнаплар, рәхим-шәфкать күрсәтсәгез лә! — дип үтенгән, ди.

Король:

— Җырың бик тә ошады, шуңа күрә сиңа сәдака урынына кызымны бирәм, киявем булырсың,— дигән, ди.

Кыз өнсез калган, карышып та караган. Ләкин атасы:

— Король сүзе бер булыр, антымны боза алмыйм! — дип кырт кискән.

Тиз генә урам җырчысы белән кызына никах укыткан.

— Менә хәзер хәерче хатыны булдың. Хәерче хатыны король сараенда яши алмавын үзең дә

аңлыйсыңдыр. Ирең куышында гомер ит, хәерле юл! — дип озатып калган, ди.

Хәерче, никахлы хатынын җитәкләп, сарайдан чыгып киткән.

Бер карурманга якынлашкач, король кызы:

— Бу урманга кем хуҗа? — дип сораган.

— Бу урман Тукрансакалныкы,—дигән, ди, хәерче.

— Ах, мин бит ул Тукрансакалны мыскыл итеп куып чыгардым,— дип үкенгән король кызы.

Ямьле болын аша узганда, кыз тагын:

— Кем болыны аша узабыз? — дип сораган, ди.

— Болын да Тукрансакалныкы,— дип җавап биргән хәерче.

— Ах, мыскыл итеп куып чыгардым бит мин аны! Ничек ялгыштым! Ничек ялгыштым! — дип уфтанган кыз.

Бара торгач, бер бик матур шәһәргә килеп кергәннәр, ди, болар. Кыз тагын:

— Бу шәһәргә дә Тукрансакал хуҗамы? — дип сораган, ди.

— Шәһәргә дә ул хуҗа,— дигән хәерче.

— Ах, ничек ялгыштым! Ничекләр ялгыштым! — дип өзгәләнгән кыз.

Кыйшаеп беткән кечкенә генә алачык янына килеп туктагач, кыз тагын:

— Бусы кем өе? Бигрәк начар. Үзе тәбәнәк, үзе кысан. Монда яшәүче кеше бик бәхетсездер? — дип сораган, ди.

— Без яшисе куыш бу. Юрганыңа карап аягыңны суз, дигәннәр. Шушында матур итеп яшик,— дигән ире.

Ишеге тәбәнәк булганлыктан, моңа кадәр берәүгә дә баш ияргә теләмәгән тәкәббер кыз, өйгә кергәндә, яхшы ук бөгелергә мәҗбүр булган.

Өйгә кергәч, яшь килен:

— Хезмәтчеләрең кая соң? — дип сораган, ди.

— Нинди хезмәтчеләр? — дип гаҗәпсенгән ире.— Хәерченең хезмәтчесе була димени? Бөтен эшне үзең эшләрсең. Башлап учак кабызып җибәр. Ашарга пешер, юкса тәмам хәлдән тайдым, карыным ачты.

Ләкин иркәләнеп-назланып кына үскән король кызы учак та кабыза белмәгән, ашарга да пешерә алмаган. Хатыны бер эш тә булдыра алмагач, ирнең үзенә җиң сызганырга туры килгән. Ниһаять, туяр-туймас ашаганнар да йокларга ятканнар, ди, болар.

Иртәгесен ире, хатынын бик иртә уятып, өй эшләрен эшләргә кушкан. Шул рәвешле, берничә көн узып та киткән, ди. Тиздән ашарга ризыклары беткән, ди.

— Ачтан үлмәс өчен, кәсеп итәргә кирәк. Кәрзин үрә башласак, ничек булыр икән? — дигән ире.

Бераздан бер кочак тал чыбыгы күтәреп кайткан. Ләкин хатыны, кәрзин үрергә тотыну белән, бармакларын кабартып бетергән, ди. Ире, пошынып:

— Бу эшне булдыра алмадың, җеп эрләп кара,— дигән.

Хатыны бер төргәк җитен алган да җеп эрләргә тотынган, ләкин, җаен белмәгәнлектән, бармакларын җәрәхәтләп бетергән, хәтта җәрәхәтләреннән кан саркый башлаган, ди.

— Бер эш тә белмисең. Синең белән ничек яшәрмен! Чүлмәк-чынаяк, савыт-саба сатып кара әле.



Бәлки, анысын булдырырсың. Мин ясармын, син базарда сатарсың.

Ире чыгып киткәч, король кызы:

— Бар икән күрәселәрем,— дип уфтанган, ди.— Базарга туган илем кешеләре килеп чыкса, хәерче хатыны кебек чүлмәк сатып утырганымны күрсәләр?! Рәхәтләнеп көләчәк бит алар миннән, туйганчы мыскыл итәчәк! Тик нишлисең, язмыштан узмыш юк, ачтан үлеп булмый бит инде!

Башта сәүдәләре ярыйсы гына барган. Кешеләр, хатынның чибәрлегенә сокланып, нинди бәя сораса, сатулашып-нитеп тормый, шуны биргәннәр, ди. Кайберләре хәтта, акчасын түләсә дә, чүлмәкләрен калдырып киткән, ди. Савыт-саба сатудан килгән акчага хәтсез генә яшәгәннәр, ди, болар. Бер әзерлә-

гәне сатылып беткәч, тагын бик күп савыт-саба юнәткән, ди, ире.

Беркөнне хатын базарда уртагарак утырган, ди. Кеше күп йөри торган мәйданга савытларын саф-саф тезеп куйган да сәүдә итә башлаган, ди. Шулчак көтмәгәндә әллә кайдан бер җайдак килеп чыккан да аты белән чүлмәкләрне таптатып узган, бөтен савыт-сабаларын чәлпәрәмә китергән, ди.

Хатын куркуыннан нишләргә дә белмәгән, гарьлегеннән елый башлаган.

Өенә кайткач, иренә, елый-елый, нинди бәлагә юлыгуын сөйләп биргән. Ире ачуланган:

— Мәйдан уртасына савыт-саба тезеп куйгач, ни буласы билгеле инде. Шул дәрәҗәдә булдыксыз булырсың икән! Йә ярый. Король сараена савыт-саба юучы кирәк икән. Булмаса, шунда эшләп кара. Тамак ялыннан булыр дип килештек,— дигән.

Назлы король кызы савыт-саба юып көн күрә башлаган. Иртә таңнан кухняда эшләгән. Хәтта беркадәр хәйләләргә дә өйрәнгән. Калдык-постык ашларны тутырып өенә алып кайта башлаган. Байтак вакыт ирле-хатынлы тамакларын әнә шулай туйдырганнар, ди, болар.

Көннәрдән бер көнне король улы туй мәҗлесе җыйган, ди. Мәҗлескә берсеннән-берсе баерак, берсеннән-берсе купшырак киенгән кунаклар җыела башлаган. Ялчы хатын, йөрәге әрнеп, үзенең авыр язмышы турында уйланган, ди. Шушындый мескенлеккә төшергән, шушындый түбәнлеккә тәгәрәткән тәкәбберлеген каһәрләгән, ди.

Өстәлләргә берсеннән-берсе тәмлерәк ашлар китерелгән. Аш өләшүчеләр ара-тирә хезмәтче хатынга да калдык-постык сыныклар биргәләгән, ди. Хатын аларны чүлмәкләренә сала барган, өенә алып кайтырга җыенган, ди.

Мәҗлес кызып барганда, залга король улы килеп кергән. Өстендәге киемнәре бәрхеттән дә ефәктән, ди, түшендә зиннәтле алтын чылбыр, ди. Король улы ишек артында басып торган чибәр хатынны күргән дә аны кулларыннан әләктереп алып биергә теләгән. Ләкин ялчы хатын, өнсез калып, биюдән баш тарткан, чөнки кайчандыр үзенә өйләнергә теләгән Тукрансакалны таныган. Теге чакта егетне мыскыл итүен, аңа кияүгә чыгудан баш тартуын исенә төшергән.

Ләкин король улы, карышуына да карамастан, ялчы хатынны бию залына алып кергән, ди. Шулчак хатынның алъяпкыч астындагы баулары өзелеп киткән дә чүлмәкләре идәнгә тәгәрәгән. Чүлмәктәге аш, ит кисәкләре, ипи телемнәре идәнгә чәчелгән, ди. Моны күргән кунаклар эчләре катып көлә башлаганнар. Король кызы бу хурлыктан шулхәтле гарьләнгән, ди, качып котылмакчы булган. Ләкин баскычтан йөгереп төшеп барганда, кемдер куып тоткан да яңадан залга җитәкләп алып кергән. Күтәрелеп караса, Тукрансакал икән, ди.

— Курыкма, синең белән җимерек алачыкта яшәүче урам җырчысы мин булам,— дигән.— Сине яратканга, юри хәерче булып кыландым. Әтиеңнең: «Беренче кергән хәерчегә кияүгә бирәм»,— дигәнен ишетеп калган идем. Базарда чүлмәкләреңне чәлпә-

рәмә китергән җайдак та мин идем. Боларны масаюыңны җуяр өчен эшләдем, тәкәбберлегең өчен үртәдем,— дигән король улы.

Кыз үксеп елый башлаган.

— Гаебем зур. Мин синең хатының булырга лаек түгел,— дигән.

— Тынычлан, авыр көннәребез узды инде. Дөнья шаулатып, туй итик. Үз туебызны,—дип, хатынын юаткан, ди, яшь король.

Шул минутта король кызы янына Тукрансакалның хезмәтчеләре йөгерешеп килгәннәр, аңа матур-матур киемнәр кидергәннәр, ди. Ул да түгел, ата-анасы, туганнары, дус-ишләре дә килеп җиткән, ди. Барысы да Тукрансакал белән король кызын котлаганнар, аларга куанычлы, бәхетле гомер теләгәннәр, ди.

Кызның чын бәхете, ямьле тормышы нәкъ менә шул минутлардан башланган, ди.

Мондый туйларга эләгеп күңел ачу сиңа да, миңа да насыйп булсын!

Бертуган Якоб һәм Вильгельм Гриммнар.

?! Әкият озын. Ләкин аны ике генә өлешкә бүлеп була. Өлешләрнең берсен тапсагыз, икенчесе шуңа охшарга тиеш.

ШАКИР БЕЛӘН ГАЛИ.

Шакир белән Гали кырдан
Кайтып киләләр иде.
Шакир, эчтән бер уй уйлап,
Ашыгып, алга йөгерде.

Ул чыкты да басмадан,
Такталарны тарттырып:
— Гали баскач егылсын,— дип,
Куйды чак-чак эләктереп...

Муса Җәлил.

?! Шигырь тәмамланмаган. Ахырын уйлап языгыз.

Әйдәгез, бергәләп, мондый нәтиҗә ясыйк: әсәр сюжеты тәмамланган вакыйга булырга тиеш. Тәмамлау өчен, вакыйга ничек башланса, ахырында автор шуңа әйләнеп кайта. Тәмамлауның бер алымы шундый. Бу очракта автор иптәшен суга чумдырырга ниятли. Вакыйга шуның капма-каршысы белән тәмамланды. Шакир иптәше чумасы урынга үзе суга чумды. Хәзер бүлек исемендәге «охшашлык» сүзен ачыклыйк.

ТИМЕРКЕНДЕК.

Бар икән бер патша, аның бар икән, ди, өч улы. Бер улын мал көтәргә чыгарган. Улы малларын көтә алмыйча йоклап калган, ди. Ул йоклаганда, күп маллары югалган. Өйгә кайтып, атасына әйтте, ди:

— И эти, мал көткәндә йоклап калганмын, белмәдем: нәрсәдер безнең малларыбызны алып киткән.

Атасы малларын көтәргә икенче улын җибәрде, ди. Уртанчы улы тагын йоклап калды, тагын да күп кенә маллары югалды. Уртанчы улы да, этисе янына килеп:

— И әти, мин дә йоклап калганмын, күп малыбыз югалды, кайда киткәннәрен белмим,— диде. Өченче көндә малларын көтәргә атасы үзе китте, ди. Кече улы әйтте:

— Мин дә барамын,— диде. Атасы:

— Син монда кал, син әле кечкенәсең,— диде. Шулай дисә дә, кече улы калмады, бергә барды. Төнлә атасы да йоклап китте. Кече улы йокламыйча карап ятты. Төн уртасында, караңгыда күрә бу: өч башлы Дию пәрие килә. Дию пәриенең авызларыннан ялкыннары чыгып тора. Бу Дию пәрие боларның малларын куып алып китә.

Иртә белән аталары йокысыннан торып караса, маллары юк. Атасы әйтте:

— Мин дә йоклап калганмын икән, малларның кайда киткәнен белмим,— ди.

?! **1.** Бер-берсенә нык охшаган өч вакыйга белән таныштыгыз. Өчесенә дә уртак исем бирегез.

Улы әйтте:

— Ә мин беләм: аларны төн уртасында өч Дию пәрие килеп алып китте,— ди.

Өйгә кайттылар. Атасы улларын янына чакырып алып әйтте:

— Әй улларым, безнең югалган малларны эзләргә кирәк,— диде.

Өч улы да малларын эзләргә киттеләр. Бер җиргә килеп кундылар. Ул җирдә бер җиз күпер бар икән. Абыйлары ике үрдәк атып алдылар. Кече малай әйтте:

— Сез ятып йоклагыз, мин бу үрдәкләрне йолкып пешерермен,— диде. Болар йоклап киттеләр, ә кече улы үрдәкләрне йолыкты. Аш пешерергә дип, су алырга төште. Күпер астына төшүе булды, өстән бик күп мал үтеп китте, ди. Маллар үтеп китү белән, алар артыннан өч башлы бер Дию күпергә килеп җитте. Дию пәриенең аты күпергә кермәде. Дию пәрие, атыннан төшеп, атын кыйный башлады:

— Атым, син ник бармыйсың?
Тимеркендек тумаган,
Туса да, монда килмәгән.

Егет күпер астыннан чыгып әйтте моңа:

Ничек атың курыкмасын?!
Тимеркендек туган да,
Каршыңа килеп торган да.
Ук атышмак кирәкме,
Сиңа көрәш кирәкме?

Дию пәрие әйтте:

— Өч мәртәбә көрәшергә кирәк,— диде. Тотынышып алыштылар, ди, көрәшергә. Көрәштеләр-көрәштеләр дә, ди, болар, теге егет Дию пәриен күтәреп бәрде, ди. Өч башын кисеп, күпер янына салып куйды, ди, бу. Шуннан соң, абыйлары янына кайтып, аш пешерде, ди.

Абыйларын уятты:

— Торыгыз, аш пеште,— диде. Абыйлары торып, юынып ашадылар-эчтеләр, ди. Энеләре атларын алып килеп, иярләп менеп киттеләр. Әлеге күпергә



аркылы чыгып, Дию пəриенең башлары янына килеп җиттелəр. Абыйлары:

— Бу нəрсəнең башлары? — дип сорыйлар тегеннəн. Энелəре бер сүз дə дəшмəде.

Яңадан киттелəр болар юл белəн. Барып-барып, бер көмеш күпер янына барып җиттелəр. Шунда кунаргa туктадылар.

?! **2.** Əкиятлəрдə вакыйгалар өч тапкыр кабатлана. Шуны истə тотып, егетнең тагын бер җиңүе турындагы вакыйганы үзегез сөйлəгез.

3. Хəзер бөтенлəй башка эчтəлектəге вакыйгалар өч тапкыр кабатлана. Беренчесе мондый:

Киттелəр, ди, болар юл белəн. Бара-бара торгач, барып җиттелəр, ди, болар бер җиз сарайга. Энелəре əйтте:

— Абыйларым, сез шушында торып торыгыз, мин бу сарайга кереп карыйм,— ди. Атыннан төшеп, сарайның ишеген эзли, ди, бу. Сарай ишеген таба алмады, тик стенада өч кыл күрде, ди. Шул өч кылны тартып җибəрүе булды, ди, өч ишек ачылып та китте, ди. Сарай эченə керде. Сарай эчендə Дию пəриенең хатыны бишектəге өч башлы Дию малаен тирбəтеп утыра икəн, ди. Тимеркендек Дию баласын, аягыннан тотып, стенага сукты, ди. Шуннан соң олы абыйсын чакырды:

— Бу синең хатының булыр, син монда кал,— диде.

Кече абыйсы белəн Тимеркендек китте. Бара-бара, болар бер көмеш сарайга барып җиттелəр.

Тимеркендек, атыннан төшеп, теге сарай янына барып, сарайның ишеген эзләде, таба алмады...

?! **4.** Өйләнү вакыйгасы аз гына үзгәреш белән тагын ике тапкыр кабатлана. Дәвам итегез.

5. Өченче вакыйга да алдагы икесе кебек кабатлана. Аны да үзегез сөйләгез.

6. Өч охшаш вакыйгага уртак исем бирегез. Әкиятнең дәвамында да кабатланган вакыйгаларга игътибар итегез.

Үзе янә юл белән китте.

Бу хатынны атка атландырып, икәүләп мал эзләргә киттеләр, ди, болар. Малларын таптылар. Куалап алып кайтып киттеләр. Уртанчы агалары янына кайтып җиттеләр.

— Абый, чык әле, малларны алып кайттык бит без,— дип, Тимеркендек абыйсын чакырып чыгарды. Абыйсы хатынын алып чыгып, атка атландылар да дүртәүләшеп малларны куып алып кайтып киттеләр. Күпмедер вакыттан соң олы агалары янына кайтып җиттеләр.

— Малларыбызны алып кайттык,— дип, олы абыйларын да чакырып чыгардылар. Алтау булып, малларын куып алып кайтып киттеләр.

?! **7.** Хәзер әкиятне кыскартып, ягъни охшаш вакыйгаларны бергә генә калдырып сөйләгез. Мал саклау вакыйгалары өчәү, бергә генә калдырыйк. Мәсәлән, болай: «Ике ага һәм аталары бер-бер артлы малларын сакларга чыгалар. Өчесе дә бару белән йоклап китәләр. Йоклап, күп малларын югалталар. Төпчек энеләре каракларны күреп кала...» Дәвам итегез.

ЧУК ҺӘМ ГЕК.

Берәү бик еракта, Зәңгәр тау янындагы урманда яши. Күп эшли. Ләкин, аңа карап, эше аз гына да кимеми. Шуңа күрә ялга берничек тә китә алмый. Кыш җиткәч, гаиләсен сагынуы чиктән ашты. Хуҗадан хатынын һәм балаларын үз янына чакырырга рөхсәт сорады. Рөхсәт булгач, кунакка килегез дип, хатынына хат язып җибәрде.

Ике улы бар — Чук һәм Гек. Алар әниләре белән Мәскәү дигән зур калада яшиләр.

Хат ташучы, әтиләре язган хатны тотып, баскычтан менгәндә, Чук белән Гек пыр тузып сугышалар иде. Дөресен әйткәндә, колак тондырырлык итеп улыйлар һәм бер-берсен дөмбәслиләр иде.

Ни бүлешә алмауларын, ни өчен сугышуларын оныттым инде. Гекның буш шырпы тартмасын Чук чәлдергәнме, әллә, киресенчә, Чукның буш вакса савытын Гек шудырганмы — шунысы гына хәтердә калган.

Ике туган сугу өчен йодрыкларын күтәргәндә генә, ишек шакыдылар. Малайлар әниләре кайтты дип шүрләделәр. Бик сәер иде әниләренең холкы. Ул улларының сугышуларын күрсә ачуланмый, тиргәми, тота да икесен ике бүлмәгә ябып куя. Менә хәзер уйнап карагыз, янәсе.

Малайлар, күз яшьләрен сөртә-сөртә, ишек ачарга чаптылар.

Ләкин ишек кагучы кеше хат ташучы булып чыкты. Әтиләреннән хат китергән икән.

— Әтидән хат! Әтидән хат килде! Мөгаен, кайтам дип язгандыр! — дип, сикерә-чаба кычкырды малайлар. Шатлыкларыннан әниләренең кайтуын сизми дә калдылар. Улларының, диванга ятып, үкчәләре белән стенаны дөмбәсләүләрен, анда элеңгән картиналарның әрле-бирле чайкалуын күреп гаҗәпләнсә дә, ни өчен шатлануларын белгәч, сүз әйтмәде. Икесен дә диваннан куып төшерү белән чикләнде.

Хат укыганда, әниләре башта күңелсезләнде, аннары, елмаеп:

— Әтиегез тиз генә кайтмый әле. Эше күплектән ял бирми торалар,— диде. Улларының борыннары төшүен көтеп торды да, елмаеп:

— Кайтмый. Ул безне үз янына чакыра,— дип өстәде.

— Бик әйбәт! Чакыргач, нигә бармаска, утырабыз да китәбез! — диде әнисенең сүзе беткәнне дә көтмичә Чук.

— Ахмак син. Анда бару өчен мең, аннан соң тагын бер мең чакрымны поездда үтәргә кирәк. Аннан соң, ат чанасына утырып, тайга аша чыгасы бар. Ә тайгада йә бүрегә, йә аюга очравыңны көт тә тор. Гаҗәп хат,— диде әниләре.

— Барабыз, барабыз. Мең булмагае йөз мең чакрым булсын, без бернәрсәдән дә курыкмыйбыз. Кичә ишегалдына кергән этне таш атып кудык бит әле, курыкмадык,— диделәр Чук белән Гек.

Әниләре тыңлап торды да көлеп җибәрде. Икесен дә кочагына алып, диванга ауды.

Бу хатны ул күптән көткән булган. Балаларын котыртып, юри генә борчылган икән.

Юлга әзерләнә-әзерләнә, атна үтте. Ул арада уллары да тик утырмадылар.

Чук пычактан кинжал ясады, ә Гек каяндыр шома таяк табып, очына кадак кагып куйды. Бик тә нык сөңге килеп чыкты. Аю очраса, тунын тишү генә түгел, йөрәгенә үк үтеп керерлек очлы сөңге иде ул.

Ниһаять, әниләре иртәгә китәсе кичке поездга билет алырга китте.

Өйдә икесе генә калгач, Чук белән Гек тагын тыныша алмадылар.

Бу талашуның ни белән тәмамлануын беләләрме?.. Белсәләр, гомергә дә талашмаган булырлар иде.

Чук запас җыярга ярата. Тимер тартмасында чәйдән калган көмеш кәгазьләр, конфет кәгазьләре, ук ясар өчен карга канатлары, кытай фокусы өчен ат койрыгыннан төшкән кыл һәм күп-күп башка шундый бик кирәкле әйберләр саклый. Гекта андый тартма юк. Аның каравы ул җырларга ярата.

Чук яшергән җиреннән кыйммәтле тимер тартмасын алып маташканда, Гек җырлап җибәрде. Ул арада хат ташучы, кереп, Чукка телеграмма тоттырды.

Чук телеграмманы тартмасына яшереп маташканда, Гек, җырлаудан туктап, такмак әйтергә кереште:

— Р-ра! Р-ра! Ура!

— Әй, бәр Турумбәр!

Нишләп җырламый башлады әле бу дип, Чук Гек бүлмәсенә керде. Керде дә шаккатты: сөңгесе

белән төртә-төртә, Гек ботинка тартмасын тишкәләп бетергән! Аюга каршы сугыша, имеш. Ә ул тартмада Чукның сыбызгысы, төсле өч значогы һәм ерак юлга дип саклаган кырык алты тиен акчасы бар иде.

Чук энесенең кулыннан сөңгесен тартып алды да, сындырып, читкә атты.

Гек Чукка карчыгадай ташланды. Кулындагы тимер тартмасын йолкып алды, тәрәзә төбенә сикереп менде. Тартманы яшен тизлеге белән ачык форточкадан урамга ыргытты.

— Телеграмма! Анда телеграмма! Анда телеграмма! — дип кычкыра-кычкыра, Чук җилкәсенә пальтосын гына элеп, урамга чыгып чапты. Аңа Гек иярде.

Ләкин, күпме генә эзләсәләр дә, телеграмманы таба алмадылар. Әллә карга күмелеп калды, әллә җил очырды.

Өйләренә кергәч, малайлар шактый вакыт сүзсез утырдылар. Әниләре бу эшләрен сизсә, ни буласын яхшы белделәр. Чук Гектан бер яшькә өлкәнрәк. Әнисенең ачуы күбрәк аңа төшәчәк иде. Уйлый торгач, котылу юлын уйлап тапты.

— Әллә телеграмма турында әнигә әйтмикме? Безгә телеграмма булмаса да күңелле бит,— диде.

— Алдарга ярамый. Алдасак, әнинең ачуы артыр гына,— диде Гек.

— Алдамыйк! Телеграмма кайда дип сораса — әйтербез. Ә сорамаса — дәшмик. Без синең белән тел бистәләре түгел бит! — диде Чук.

— Алай алдашмагач, ярый, син әйткәнчә булыр,— диде Гек.

Ул арада әниләре дә кайтып керде. Аның күңеле күтәренке иде, чөнки поездга билет ала алды, урыннары да яхшы иде. Ләкин улларының йөзендә хәсрәт, күзләрендә яшь күреп:

— Йә, әйтегез, бу юлы нигә сугыштыгыз? — дип сорады.

— Сугыш булмады,— диде Чук.

— Юк, булмады, сугышмакчы булган идек, аннан соң бу уебыздан кире кайттык,— дип, абыйсының сүзен раслады Гек.

Әниләре улларын мактады. Башыгызга матур уй килгән, диде. Телеграмма турында сорамады.

Икенче көнне алар юлда иде инде. Төнлә Гек уянды. Түшәмдәге ут янмый иде. Карлы тәрәзә аша карап, айны күрде. Галәмәт тә зур иде ай. Әһә, поезд биек тау өстеннән чаба икән, ай безгә якыннан күренгәнгә шулай зурдыр, дип уйлады Гек.

Әнисен уятып су сорады. Әнисе су бирмәде, сәбәбе бар иде. Апельсин ашарга кушты. Гек үпкәләде. Шуңа күрә йокысы качты. Чукны төрткәләп уятмакчы булды, ләкин уята алмады. Абыйсы ачу белән нидер мыгырданды да икенче якка борылып ятты.

Гек, аягына итекләрен киеп, коридорга чыкты. Коридор тар. Аңа тагын ун ишек чыга. Барысы да кыпкызыл, шомалар.

Гек, стенадагы урындыкларның әле берсенә, әле икенчесенә утыра-утыра, коридорның аргы башына ук барып җитте. Каяндыр проводник килеп чыкты. «Кешеләр йоклый, ә син аларны уятып шакылдыйсың»,— дип ачуланды.

Проводник китү белән, Гек, кайтып, купе ишеген ачты. Әнисен уятмаска тырышып, үз урынына менеп ятмакчы булды. Ләкин юан Чук шундый таралып яткан, аңа утырырлык та урын калдырмаган. Гек ачу белән Чукның аркасына кундырды. Шуннан соң ни булганын төшеңдә күрсәң дә куркып уянырсың! Түгәрәк башлы Чук урынына аңа ниндидер абзый кешенең мыеклы усал йөзе карап тора иде.

— Кем төртешә монда? — дип, ачу белән сорады абзый кеше.

Гек куркудан бар көченә кычкырды. Пассажирлар куркып уяндылар. Түшәмдәге ут янды. Ә Гек, чит купега керүен күргәч, тагын да яманрак итеп кычкырды.

Пассажирлар тавыш сәбәбен белгәч көлделәр, ә мыеклы абзый Гекны үз купесына озатып куйды.

Көн-төн бара торгач, ниһаять, поезд кечкенә генә станциягә килеп туктады.

Ана, Чук белән Гекны төшереп, мыеклы кеше кулыннан әйберләрен алу белән, поезд китеп тә барды. Ләкин аларны каршы алырга әтиләре килмәгән иде. Әниләренең ачуы чыкты. Улларына әйберләрен сакларга кушып, ямщиклар[1] янына китте. Аларга тайгадан тагын йөз чакрымлап юл үтәргә кирәк иде әле.

Әниләре хәсрәткә батып кайтты. Әтиегез юлга чыгабыз дип салган телеграммабызны алмаган, күрәсең. Шуңа күрә каршы алырга ат җибәрмәгән, диде.

---

[1] Ямщиклар — почта яки кешеләр ташый торган атларны йөртүчеләр.

Ямщик, карда аунап яткан әйберләрне күтәреп, буфетка керде.

Чук белән Гек чәй эчкән арада, әниләре әлеге ямщик белән сатулашты. Ямщик, илткән өчен, йөз сум акча сорады. Бәхәсләшә торгач килештеләр. Бу кадәр арага йөз сум кызганыч түгел иде.

— Әтиегез безнең монда икәнлегебезне белми, күргәч шаккатыр, шатланыр,— диде әниләре.

Бераздан ямщик кузгалырга әзер иде. Киң чанага әйберләрне урнаштырдылар. Өсләренә одеяллар, толыплар бөркәнделәр.

Зур шәһәрләр, заводлар, станцияләр, авыллар, хушыгыз! Хәзер алда урман, таулар, тагын куе кара урман гына булачак.

Кичкә кадәр куе урманга сокланып карый-карый баргангадыр, юл кыен сыман булмады.

Чук алдагы юлны күрә алмады, ул ямщик артында утыра иде. Тора-бара аңа күңелсез була башлады. Шуңа күрә әнисеннән ашарга сорады. Әнисе бирмәде. Чук ачудан Гекны чана кырыена кысрыкларга кереште. Баштарак Гек түзде, түземе беткәч, Чукның битенә төкерде. Чук ачудан энесенә ташланды. Икесенең дә куллары толып астында булганга, алар башлары белән бәрешергә мәҗбүр булдылар.

Әниләре сугыш чукмарларына карап көлде. Шунда ямщик атларына чыбыркы белән селтәнде, атлар чабуларын тизләттеләр.

Битләргә саф һава исә. Теләмәсәләр дә, Чук белән Гек, бер-берсенә сыена төшеп, тайгага һәм

зәңгәр тау артыннан ипләп кенә чыгып килүче айга карап, таудан түбәнгә таба җилдерделәр.

Атлар карга күмелгән кечкенә өйчек каршына килеп туктадылар. Ямщик карга сикереп төште дә:

— Станциябез шушы булыр. Монда кунабыз,— диде. Ямщик тиз арада чәй кайнатып өлгерде. Чанадан ашамлыклар сумкасын алып керде. Колбаса чүкеч урынына кадак кагарлык иде. Аны кайнар суга салдылар, ә ипине кызган плитә өстенә куйдылар.

Чук мич артыннан күгәргән, кәкрәеп беткән пружина тапты. Төрле җанварлар каптыра торган капкын пружинасы дип аңлатты ямщик.

Чәй эчкәч йокларга яттылар. Матрац урынына аска коры яфрак җәелгән иде.

Икенче көнне кичкә кадәр урман эченнән һәм таулардан үттеләр. Югары менгәндә, ямщик, чанадан төшеп, җәяү барды. Ә төшкәндә, чана шундый зур тизлек белән шуды, Чук белән Гекка алар атлары, чаналары белән бергә күктән җиргә очып төшкәндәй булды.

Ниһаять, караңгы төшәр алдыннан, атлар да, кешеләр дә хәлдән тайгач, ямщик:

— Менә килеп тә җиттек. Каршыдагы калкулык артында ялан, ә яланда аларның базалары,— диде.

Калкулыкны әйләнеп үттеләр. Чана өч йорт янына шуып туктады.

Гаҗәп! Этләр өрми, кешеләр күренми, мичләрдән төтен чыкмый, өйләрне кар күмгән.

— Безне кайда алып килдең? — дип, ана калтыранган тавыш белән ямщиктан сорады.— Без шушында килергә тиеш идекмени?

— Кайда кирәк булса, шунда килдек. Менә шушы өч йорт — җир асты байлыклары эзләүче геологларның базасы,— дип җавап бирде ямщик.

— Шушысын шушыдыр. Ләкин нигә соң ишекләр йозаклы? Баскычта кар, кешеләре кайда соң бу йортларның? — дип сорады ана.

— Чыннан да, кая киттеләр икән болар? — дип борчылды ямщик.— Үткән атнада без монда он, суган, бәрәңге ише азык-төлек алып килдек. Сигез кеше, хуҗалары белән тугыз, каравылчыларын да санасаң, унау — бар да өйдә иде. Бәла аяк астында шул. Бүреләр ашамады бит инде аларны. Көтегез, каравылчы өен карап киләм,— диде дә, толыбын салып, көрт ера-ера, иң читтәге йортка таба китте.

Әйләнеп кайткач:

— Йортта кеше юк, ләкин миче җылы. Димәк, каравылчы урманга кош-корт атарга гына киткән булырга тиеш. Төнгә кайтып җитәр дә ирегезнең кая китүен әйтер,— диде.

Төялеп, каравылчы йортына киттеләр. Чолан аша көрәкләр, себеркеләр, балталар, таяклар, салкынга каткан аю тиресе арасыннан үтеп, өйгә керделәр. Алар артыннан, йөкне сөйрәп, ямщик керде.

Өй җылы иде. Ямщик атларын ашатырга чыкты. Ана куркудан телләрен йоткан балаларын чишендерде.

— Әтиегез янына килдек, килдек...— менә килеп җиттек,— диде.

Ана сәкегә утырып уйга калды. Ни булды? Ни өчен базада бер кеше дә юк? Хәзер безгә нишләргә? Кайтып китәргәме? Кайтыр идек, акча ямщикка би-

рерлек кенә калды. Каравылчыны көтүдән башка чара юк. Тагын өч сәгатьтән ямщик кайтып китәчәк. Каравылчы озак торса нишләрбез? Моннан иң якын станциягә йөз чакрым бит!

Ямщик керде. Тирә-ягына күз йөртеп чыккач иснәнде дә:

— Каравылчы караңгы төшкәндә кайтачак. Мичтәге чүлмәктә кәбестә ашы бар. Озак торырга киткән булса, ашын салкынга чыгарган булыр иде,— диде.— Хәер, ихтыярыгызда. Кайтабыз дисәгез, станциягә бушлай илтәм.

— Рәхмәт. Монда калабыз,— диде ана.

Тагын чәй кайнаттылар. Каткан колбасаны җылы суга салып эреттеләр. Бар булганы белән тамакларын ялгадылар.

Әниләре, төргәкләрен сүтеп, андагы кирәк-яракны урнаштырганда, Чук белән Гек мич башында йоклыйлар иде инде. Алар ямщикның моннан китүен дә, әниләренең үзләре янына менеп ятуын да белми калдылар. Ә төн уртасында аларны баскычта нидер дөбердәве уятты. Ишек ачылды. Өйгә, кулына фонарь тотып, йөнтәс этен ияртергән каравылчы керде.

Менә ул җилкәсенә аскан мылтыгын салды, атып алган куянын сәкегә ыргытты. Аннан соң фонарен мич башына күтәргәч:

— Нинди кунаклар килгән безгә? — дип сорады. Ана, мич башыннан төшә-төшә:

— Мин геологлар партиясенең хуҗасы Серёгин хатыны. Ә болар — аның балалары. Карыйм дисәгез, документ күрсәтә алам,— диде.

— Әнә алар документлар: мич башында утыралар,— дип мыгырданды каравылчы, Чук белән Гекны яктыртып. Аннары бармагы белән Чукка төртеп: — Аеруча менә монысы, юаны нык охшаган,— диде.

Малайлар икесе дә үпкәләделәр. Чук — юан дигәне өчен, ә Гек әтисенә охшаган улы үзе булмавын белгән өчен үпкәләде.

— Нигә монда килдегез? Сезгә килмәскә әйтелде бит,— диде каравылчы.

— Ничек килмәскә әйтелде? Кем әйтте?

— Менә шулай, килмәскә дип әйтелде. Серёгин телеграммасын почтага үзем илтеп салдым. Анда: «Ике атна арасында килмәгез. Безнең партия ике атнага ашыгыч эш белән тайгага китә»,— диелгән иде. Серёгин ашыкмагыз дигән икән, димәк, ашыкмаска кирәк иде.

— Нинди телеграмма? Безнең бернинди телеграмма да алганыбыз юк,— диде ана һәм, сүзләрен раслату өчен, Чук белән Гекка күз ташлады.

Әниләренең күз карашы тәэсирендә малайлар, куркышып, бер-берсенә карап алдылар һәм мич башының почмагына шуыштылар.

— Балалар, сез мин юкта телеграмма алмадыгызмы? — дип шикләнеп сорады әниләре.

Мич башында коры йомычка, себерке шыгырдады, ләкин сорауга җавап ишетелмәде.

— Җәфалар! Ник җавап бирмисез? Телеграмманы мин юкта алдыгызмы? Миңа бирмәдегезме?

Берничә секунд тынлыктан соң, парлап елау тавышы яңгырады. Чук — калынрак тавыш белән

сузып, ә Гек нечкәрәк тавышын үзгәртә-үзгәртә елады.

— Менә кайда минем үлемем! Менә кемнәр өзәчәк гомеремне! Җитте, уламагыз, ничек булганын хәзер үк әйтегез,— диде ана.

Ләкин әниләренең үләргә җыенуын ишеткәч, малайлар тагын да катырак елый башладылар. Аннан соң, гаепләрен бер-берсенә яга-яга, сагышлы хикәяләрен сөйләп бирү өчен, шактый вакыт кирәк булды.

Бу халыкны нишләтергә? Таяк белән тәпәләргәме? Төрмәгә утыртыргамы? Аяк-кулларын богаулап, каторгага озатыргамы?

Юк. Әниләре боларның берсен дә эшләмәде. Авыр итеп сулады да улларына мич башыннан төшәргә, борыннарын сөртергә, битләрен юарга кушты. Үзе каравылчыдан: «Хәзер нишлик инде?» — дип сорады.

— Разведка партиясе ашыгыч фәрман белән Алкараш тарлавыгына китте. Ун көнсез кайтмаячаклар,— диде каравылчы карт.

— Ул арада без ничек яшик? Бар запасыбыз бетте бит,— диде ана.

— Моңа кадәр ничек яшәсәгез, шулай яши бирегез. Ипи калдырам, куянны тунап пешерерсез. Ә мин тайгага капкыннарны карарга китәм. Ике көннән кайтырмын,— диде каравылчы.

— Үзебез генә калабызмы? Без монда берни белмибез бит. Тирә-якта урман, җәнлекләр...

— Икенче мылтыгымны сезгә калдырам. Утын чоланда, су чишмәдә, чишмә әнә теге таулыкта, ярма

капчыкта. Ә мин сезгә бала караучы түгел. Вакытым юк,— диде каравылчы.

— Нинди усал абзый. Әллә аңа ни дә булса әйтикме? — дип пышылдады Гек.

— Әйтеп кара, тотар да өеннән куып чыгарыр. Әти кайтсын әле. Аңа барын да сөйләрбез,— диде Чук.

Гек әнисенең итәгенә менеп утырды да каравылчыга кашларын җимереп, усал итеп карады. Гек шунда гына каравылчы тунының җилкәсеннән биленә кадәр бер тотамы умырылып төшкәнлеген күрде.

— Мичтән кәбестә ашын чыгар, әнә тәлинкәләр, кашыклар, утырып ашагыз. Ә мин тунымны ямыйм,— диде каравылчы.

— Монда син хуҗа. Чуеныңны мичтән үзең чыгар, безне сыйла, ә туныңны үзем ямыйм,— диде ана.

Каравылчы анага күтәрелеп карады, Гекның кырыс карашын күргәч:

— Күрәм: үзсүзле кешеләр икәнсез,—дип мыгырданды һәм, анага тунын сузып, савыт-сабасын өстәлгә тезеп куйды.

— Кайда ерттың моны? — дип сорады Чук, тундагы ертыкка күрсәтеп.

— Аю белән уртак тел таба алмадык. Бераз тырнап алды,— дип, теләр-теләмәс кенә җавап бирде каравылчы.

— Кара әле, Гек,— диде Чук, каравылчы чоланга чыккач.— Ул аю белән сугышкан, шуңа күрә бүген шулай усалдыр.

Таң атканда каравылчы, капчык, мылтык алып, этен ияртеп, чаңгысын такты да урманга кереп китте. Хәзер өй эшләре үзләренә калды.

Алар суга өчәүләп йөрделәр. Су таучык артындагы кыя таштан ага, аннан чәйнектән чыккан кебек пар бөркелә. Чук агымга бармагын тидергән иде, су тыштагы салкыннан да салкынрак булып чыкты.

Аннары, бергәләп, утын ташыдылар. Мич янып киткәч, өй бик тиз җылынды. Хәтта каршы як стенадагы тәрәзәнең бозы да эреде. Хәзер пыяла аша урман, агач башларыннан саесканнарның сикерә-оча үтүләре ап-ачык күренде.

Төшке аштан соң, бергәләп, йөрергә чыктылар.

Чук әнисен мылтык һәм берничә патрон алырга күндермәкче булды. Ләкин әнисе мылтыкны иң югары элмәккә элде. Патроннарны иң өске киштәгә куйды. Ә Чукны бик каты кисәтте: «Бер генә патронны алсаң да, күрмәгәнеңне күрсәтермен»,— диде.

Чукның бит очы кып-кызыл булды. Ул моннан тизрәк китәргә ашыкты, чөнки кесәсендә патроннарның берсе ята иде инде.

Тирә-якны күзәтеп йөрү искиткеч күңелле булды! Алар чишмәгә тар сукмактан аллы-артлы тезелешеп бардылар. Баш очларында салкын зәңгәр күк балкый; зәңгәр тауларның очлы кыялары әкияттәге патша сарайлары манараларыдай күккә күтәреләләр.

Салкын тынлыкта саесканнар чыркылдый. Эрбет агачлары арасыннан соры җитез тиеннәр сикерәләр. Агач астындагы йомшак карда нинди генә җәнлекнең, кошның эзе юк!

Мәскәүдә яшәгәндә, Гек җирне Мәскәү, андагы урамнар, йортлар, трамвайлар, автобуслар итеп күз алдына китерә иде. Хәзер бөтен җир биек куе урман булып тоелды.

Гомумән, әгәр башы очында кояш яктыртса, бөтен җир өсте якты булуына аз гына да шикләнми иде Гек. Әгәр аңа күңелле булса, җирдәге барлык кешеләргә дә күңелле дип уйлый иде.

Ике көн үтеп китте, өч көн үтте, каравылчы урманнан кайтмады. Кар күмгән кечкенә өй эченә шомкурку керде.

Аеруча кич җиткәч һәм төнлә куркыныч иде. Алар чолан һәм өй ишекләрен ныклап биклиләр. Тәрәзә пәрдәләрен төшерәләр, утка җанварлар килмәсен дип, утларын сүндерәләр. Ә бит шуларның киресен эшләргә кирәк иде. Чөнки җанвар кеше түгел — уттан курка.

Мич торбасы өстендә җил гадәттәгечә улаганда, ә өермә тәрәзәләргә очлы кар бозчыкларын чәпәгәндә, әйтерсең лә тышта кемдер керергә теләп, этәртә тырнаша.

Дүртенче көн башланганда, утынны ана ярды. Куян күптән ашалды. Төшке ашлары ботка белән суган гына булды. Ипиләре бик аз гына калган иде, ана он эзләп тапты һәм көлчә пешерде.

Шундый азыкны ашагач, Гекның кәефе кырылды. Температураң күтәрелгән дип, әнисе аңа өйдә генә утырырга кушты. Үзе, чиләкләрен алып, Чукны ияртеп, чишмәгә китте. Бер уңайдан чыбык-чабык та җыеп кайтырга ниятләде. Ләкин алар тиз генә кайта алмадылар.

Гек аларның кайтуларын көтте-көтте дә, көтеп туйгач, нидер эшләмәк булып уйлый башлады.

Ана белән Чукның тиз кайта алмауларына сәбәпләр күп иде. Су алып кайтканда, чаналары ауды. Сулы чиләкләр тәгәрәп китте. Чишмәгә кабат барырга туры килде. Чук җылы бияләен чишмә янында онытып калдырды. Ярты юлдан борылып, кабат чишмәгә киттеләр. Шулай йөри торгач, кич җитте.

Өйгә кайтсалар — Гек юк. Башта ул мич башында аю тиреләре астына яшеренгән дип уйладылар. Гек анда юк иде. Мич астында да табылмады.

Ана, шомланып, ишек янындагы кадакка карады. Анда Гекның туны эленмәгәнен күрде. Урамга чыгып, өйне әйләнде, чоланга кереп, фонарь яндырды. Утын артларыннан карады. Гекны ачуланды, чык дип ялынды, ләкин җавап бирүче булмады. Караңгы төште.

Шуннан соң ана өйгә чабып керде дә мылтык белән патроннар, фонарь алып чыкты. Ә Чукка урыныннан кузгалмаска кушты.

Дүрт көн эчендә кар нык тапталды. Эзләр күренми.

Гекны кайдан эзләргә? Берүзе урманга керергә куркыр дип, ана юлдан чапты. Юл да буш булып чыкты.

Менә ул мылтыгын корды да, улы ишетсен дип, һавага атты. Бераз тыңлап торгач, тагын атты.

Көтмәгәндә, якыннан гына кемдер анага атып җавап бирде. Кемдер аңа ярдәмгә ашыга иде. Ана тавышка таба чаба алмады, ике-өч адым атлау белән,

итекләре көрткә батты. Карга бәрелеп, фонареның пыяласы ватылды, уты сүнде.

Шулчак Чук ачы тавыш белән кычкыра башлады. Мылтык аткан тавышны ишеткәч, Гекны ашаган бүреләр әнисенә һөҗүм иткәннәр дип уйлады.

Ана фонарен атып бәрде дә, сулышына кысыла-кысыла, өйгә таба чапты. Яланөс чыккан Чукны өйгә төртеп кертте, мылтыгын почмакка томырды, чүмеч белән алып, салкын су эчте.

Баскычта бәрелгән-сугылган тавыш ишетелде. Ишек ачылып китте, өйгә эт, аның артыннан каравылчы килеп керде. Керү белән исәнләшмәде-нитмәде:

— Ни булды? Нигә мылтыктан аттың? — дип сорады.

— Малай югалды,— диде дә кычкырып елап җибәрде ана. Башка бер сүз дә әйтә алмады.

— Тукта, елама,—дип кычкырды каравылчы. — Кайчан югалды? Күптәнме? Әйтәсезме, юкмы? Югыйсә чыгам да китәм!

— Бер сәгать чамасы вакыт үтте. Суга барган идек, кайтсак, Гек юк. Киенгән дә кайдадыр киткән,— диде ана.

— Бер сәгать арасында әллә кая китә алмас. Ә тунын, итеген кигәч, тиз генә туңмас. Смелый, ко мне. Мә, иснә,— диде карт.

Каравылчы кадактан Гек башлыгын алды да этенең борынына сузды.

Эт койрыгын болгап алды, ләкин урыныннан кузгалмады.

— Вперёд! Эзлә! — дип кабатлады каравылчы. Хәзер аның тавышы шактый кырыс иде. Эт, иснәнеп,

урынында калды. Әле бер аягын, әле икенчесен күтәреп, таптануын белде.

— Биеп күрсәтәсеңме? — дип ачуланды каравылчы. Гекның башлыгы белән аяк киемен тагын борынына сузды. Муен каешыннан тотып, этен ишеккә таба сөйрәде. Ләкин эт иясенә иярмәде. Түргә таба китте.

Түр почмагындагы зур агач сандык янында туктады. Йонлы аягы белән сандык капкачын тырмап алды да хуҗасына таба борылып, иренеп кенә өрде.

Каравылчы мылтыгын аптырап калган анага сузды, барып, сандык капкачын күтәрде.

Сандыкта, тунын ябынып, бүреген баш астына салып, Гек йоклап ята иде.

Уятып, сандыктан алгач, ул йокы аралаш берни аңламады. Тавышлананалар, бар да шатлананалар. Әнисе елый-елый үбә. Чук кулын, аягын тарткалый, сикерә-сикерә «әллә-лә, әллә-лә» дип кычкыра.

Эш болай булган. Әнисе белән абыйсы судан кайтмыйча озак торгач, Гек эче пошып йөргән-йөргән дә үзенә шөгыль уйлап тапкан. Туны белән бүреген кыстырып, сандыкка кереп яткан. Әнисе белән Чук кайткач эзли башларлар, шулвакыт сандык эченнән куркыныч тавыш белән улармын дип уйлаган. Ләкин кайтуларын көткән-көткән дә йоклап киткән.

Каравылчы кинәт аягына басты, өстәлгә авыр ачкыч һәм таушалган зәңгәр конверт ташлады да:

— Менә сезгә ирегез яши торган бүлмә һәм келәт ачкычлары. Монысы хуҗа Серёгиннан хат. Үзе

кешеләре белән монда дүрт көннән, нәкъ Яңа ел алдыннан кайтачак,— диде.

Менә кайда югалып торган икән бу караңгы чырайлы карт! Куян атарга барып кайтам, диде, ә үзе чаңгыда ерак Алкараш тарлавыгына кадәр барып кайткан икән!

Ана урыныннан торды да кулын каравылчының җилкәсенә салды. Чиксез рәхмәтен ул шулай әйтте.

Карт җавап бирмәде. Гекны сандыктагы әйберләрне чәчкәнсең дип, ә ананы фонарь пыяласын ваткансың дип битәрләде. Шактый озак мыгырданды, ләкин хәзер бу шәфкатьле әкәмәт карттан берәү дә курыкмады.

Ана кич буе Гек яныннан китмәде. Бөтен игътибар бер Гекка гына булуын күреп, Чук үпкәләде. Их, нигә мин дә сандыкка кереп качмадым, дип үкенде.

Хәзер барысына да күңелле иде. Каравылчы этиләре яши торган бүлмәне ачты. Мич якты. Әйберләрне күчерде.

Ана көне буе бүлмәне юды, кырды, чистартты. Кич белән утын күтәреп кергән каравылчы мондагы чисталыкны күргәч аптырап калды. Ишек янында бер адым да атламады. Ә эте яңа юылган идәннән түргә кадәр үтте. Гек янына килеп, аңа салкын борынын төртте. Син тилене мин коткардым бит, шуңа күрә миңа тамак ялгарлык ни дә булса бирергә тиешсең, диюе иде.

Ана күңеле тулып, аңа колбаса ташлады. Каравылчы бу юлы да ананы ачуланып мыгырданды. Тайгада эткә колбаса ашатсаң, саесканнар көләр, диде.

Икенче көнне Яңа елга әзерлек башланды.

Чыршыга уенчыклар ясау өчен, әлләниләр таптылар. Иске журналлардагы төсле рәсемнәрне ертып алдылар, чүпрәк-чапрактан, мамыктан курчаклар тектеләр. Әтиләренең тартмадагы папирос кәгазеннән әллә никадәр чәчәкләр бөтерделәр.

Караңгы чырайлы картыбызга кадәр, утын керткән саен, чыкмыйча, боларның эшенә сокланып карап тора башлады. Ниһаять, түзмәде. Чәй төрелгән көмеш кәгазь, итек ямау өчен саклап тоткан балавыз кисәге алып килде.

И рәхмәт укыдылар аңа. Уенчыклар фабрикасы хәзер шәм заводына әйләнде. Бар да балавыздан шәм ясадылар. Шәмнәр, әллә ни матур булмасалар да, чын шәмнәр кебек яктырттылар.

Чыршыны каравылчы алып кайтты.

Ярый, уенчыклары да күз явын алырлык чибәр түгел, чүпрәктән тегелгән куяннар песигә охшыйлар, курчакларыбыз да бертөсле — борыннары озын, күзләре акайган, аның каравы мондый матур чыршы Мәскәүдә дә юк. Безнең чыршы чып-чын тайга чыршысы иде бит: үзе биек, куе, үзе туп-туры.

Дүрт көн эш белән сизелми дә үтеп китте. Яңа ел килеп җитте диярлек. Төшке ашка дип өстәл янына утырганнар гына иде, каравылчы тәрәзә какты.

— Чыгыгыз. Менә хәзер алар әнә теге тау итәгендә күренәчәкләр. Аннары тайгада югалып торырлар да ярты сәгатьтән монда булырлар,— диде.

Шулай булды да. Башта этләр җигелгән чана, аннары чаңгычылар күренде. Биек таулар итәгендә алар кеп-кечкенә булып күренделәр.

Күп тә үтмәде, урман эченнән йөкле чана тарткан этләр чабып чыкты, алардан калышмыйча, тугыз чаңгычы шуа. Баскычтагы Чук белән Гекны күргәч, бар да, чаңгы таякларын күтәреп, «ура» кычкырдылар.

Гек түзмәде, баскычтан сикереп төште дә, итегенә кар тутыра-тутыра, сакаллы биек кешегә таба чапты.

Көндез юындылар, кырындылар, мунча керделәр. Ә кичен барысы да чыршы янына җыелды. Өстәл әзер булгач, ут сүндереп, шәмнәрне яндырдылар.

Берсенең баяны бар икән, бию көе уйнап җибәрде. Барысы да биеделәр. Әти кеше бии белми иде. Тезенә Чук белән Гекны утыртып, башкалар биегәнне күзәтте. Өчесе дә биючеләргә өзлексез кул чаптылар.

Биюләр тукталгач, Гекны җырларга чакырдылар. Әйбәт җырлавын ул үзе дә белә иде. Ялындырып тормады. Баянист уйнаган көйгә җырлап җибәрде. Әле дә хәтеремдә: бик матур җыр җырлады ул. Аны тын да алмыйча тыңладылар. Ә җыр тәмамлангач, шау-гөр килеп, Гекны күтәреп чөйделәр дә чөйделәр. Әти кеше сәгатенә карап алды да:

— Инде өстәл янына утырыгыз. Хәзер эшнең иң мөһиме башлана,— диде. Аннан соң, барып, радиоалгычын кабызды. Бар да утырдылар. Башта нидер шыгырдады, чыжылдады, аннары чаң җырлыйҗырлый суга башлады.

Чук белән Гек бер-берсенә карап алдылар. Алар бу чаңның Мәскәүдәге Кремль чаңы булуын таныдылар. Бар да аякка басты, бер-берсен тагын бер тапкыр котладылар, барысына да бәхет теләделәр.

Бәхетне һәркем үзенчә аңлый. Ләкин бөтен кеше намус белән яшәргә, күп эшләргә һәм туган җирне яратырга, сакларга кирәклеген белә һәм аңлый иде.

Аркадий Гайдар.

Хикәянең авторы белән танышыйк.

Авторның тормыш юлын түкми-чәчми язсаң, үзе бер мавыктыргыч әсәр булыр иде.

1904 нче елда укытучы гаиләсендә туган. Бала чагы Татарстанга шактый якын Арзамас шәһәрендә үткән.

Шуннан соңгы тормыш юлы әкияткә охшый. Унөч яшьтә большевиклар ягында сугыша. Батырлыгы өчен аңа исеме язылган хәрби мылтык бүләк итәләр. Ундүрттә, чын яшен яшереп, Кызыл Армиягә языла. Яшьтәшләренә караганда буйга озынрак, тазарак булганга, аңа ышаналар. Ә инде сигезенче сыйныф укучысы яшендә, хәрби курслар тәмамлап, дүрт йөзләп солдаты булган полк белән җитәкчелек итә. Шул дәрәҗәдә ул төрле фронтларда сугыша. Күп тапкыр яралана. Иң авыр ярасы — башындагы яра — аны хәрби хезмәттән китәргә мәҗбүр итә.

Әкияткә охшаган тормыш юлы әле шуннан соң да дәвам итә.

Аркадий Гайдар ул чактагы иң зур хәрби башлык булган М. В. Фрунзега хат яза. Хатында хәрби хезмәткә кайтырга теләвен белдерә. Ул хатның эче тулы хис булгандыр, югыйсә Фрунзе, егетне чакырып:

— Хатыңны укыдым да, иптәш полк командиры, мин сиңа язучы булырга приказ бирәм, мондый хатны язучы кеше генә иҗат итә ала,— ди. Үзе мыек астыннан елмая.

Безнең илдә Аркадий Гайдарны белмәгән бала юктыр. Ул, үзе исән чакта ук, илдә иң талантлы балалар язучысы булып таныла.

Бөек Ватан сугышы башлангач, үзе теләп, фронтка китә. Үзе теләп, дошман ягында кала һәм партизан отрядында пулемётчы булып сугыша. Сугышларның берсендә партизаннарны дошман чолгап ала. Аркадий Гайдар, пулемётыннан дошманга ата-ата, иптәшләрен коткара. Ләкин үзе шунда һәлак була.

Аркадий Гайдар күбрәк балалар турында яза. Балалар холкын аның кебек белеп язучы юктыр да әле. Менә бу әсәрендә дә малайлар берсен берсе күрмичә тора алмыйлар. Шул ук вакытта сугышмыйча да түзә алмыйлар.

?! **1.** Хикәянең бер өлеше малайларның бертуктаусыз сугышулары турында. Алар сугышалар да дуслашалар, сугышалар да дуслашалар.

Чук белән Гекның сугышулары турында автор берничә урында язган. Дөрес, сугышу сәбәпләре төрле, ләкин алар бар да — холыксызлык нәтиҗәсе бит. Шуңа күрә бу вакыйгаларны охшаш вакыйгалар дип кушабыз. «Малайлар сугышы», «Холыксызлык», ә үзегез уйлап тапсагыз, башка исемнәр дә бирергә була.

Хикәянең беренче өлеше табылды. Икенче өлешен табарга кирәк. Анысын да охшаш вакыйгаларга уртак исем биреп табыгыз.

2. Каравылчы карт — әсәрдә аеруча уңышлы язылган персонаж. Ана да, малайлар да аны башта өнәп бетермиләр. Ә холкын белгәч яраталар. Каравылчының холкы турында сөйләгез (холык кешенең даими сыйфаты булуын истә тотыгыз).

3. Әдип Себернең шактый кырыс, яшәү өчен уңайсыз, куркыныч урыны турында яза. Кешеләр анда да эшлиләр. Зарланмыйлар, мактанмыйлар. Эшлиләр дә эшлиләр. Мондагы эш кешеләренә авырлыкны җиңәргә нинди сыйфатлары ярдәм итә?

4. Хикәядәге төп вакыйганың (сюжетның) үсешен күз алдына китерик. Әсәр ананың һәм балаларның шатлыгы белән башлана. Юлда кыенлыклар арта бара, кыенлыклар арткан саен, ананың борчылуы да арта. Шатлыкны хәсрәт алыштыра. Ана борчылуының иң югары ноктасы кайчан була? Хәсрәт кайчан шатлыкка әйләнә?

5. Сугыш чукмарлары Чук белән Гек сәяхәттән үзгәреп кайталар. Алар кырыс табигатьнең дә матурлыгын күрергә өйрәнәләр. Малайларга тәэсир итүче башка сәбәпләрне әйтегез.

КӨЗГЕ КИЧТӘ.

Чү!
Тирәкнең яфраклары
Дәррәү очып китте, дисәм...
Кошлар икән.
Чү!..

Зиннур Мансуров.

?! Шигырьнең беренче өлешен тагын бер кат укыгыз. Икенче өлеше — беренчесенең капма-каршысы. Шигырьнең икенче өлешен, табып, дәфтәрләрегезгә языгыз.

НИЧЕК БЕЛЕП АЛЫРГА?

Һәр юлчының
Җыры бар.
Алар юлда
Җырлыйлар.
Шул җырларның барын да
Ничек белеп алырга?!

Җилләрнең дә,
Суларның да
Җыры бар...
Алар нәрсә җырлыйлар —
Ничек белеп алырга?!

Болытлар да
Юлчылар,
Аларның да
Җыры бар.
Шул җырларның барын да
Ничек белеп алырга?!

Болытларның җырлары
Күкләр турында микән?
Дөньяны дерелдәткән
Күкрәү турында микән?

Еракларга күренгән
Яшен турында микән?
Яшәү турында микән?

Мин дә аны җырлар идем,
Ничек белеп алырга?!

Рөстәм Мингалим.

Инша языйк.

Автор болыт җырының эчтәлеген күз алдына китерә. Болыт эчендә күкрәү дөньяны тетрәтә, яшен яктысынерактагы кешеләр дә күрәләр. Шулай булгач, болыт җырында күкрәү дә, яшен яктысы да булырга тиеш. Лирик геройның әнә шундый күкрәүле, ерактан күренә торган яшендәй яшисе килә.

Шигырь, димәк, авторның үз теләге турында да, безгә күкрәп, янып яшәргә киңәш итүе турында да була ала.

Сулар җырының эчтәлеген дә, шуңа охшатып, үзегез ишетергә теләгәнчә языгыз.

Су җыры турында язганда, аның яңгыр, ерганак, инеш, елга, диңгез була алуын; бозга, карга, парга әйләнә алуын да истә тотыгыз. Суның ярлары, камышлары, дулкыны, төнбоеклары, балыклары бар. Су агымын үзгәртә-үзгәртә ага, аңа кичләрен ай күләгәсе төшә, дулкыннарында, вак-вак кояшчыкларга чәчелеп, кояш уйнарга ярата. Сез шуларның һәркайсын кеше язмышы, теләге, хисе, мәхәббәте белән бәйли аласыз. Ашыкмыйча, уйлап языгыз.

КАР БӨРТЕГЕ, КУН КУЛГА.

Кар бөртеге,
Кун кулга,
Азрак ял ит
Син шунда.

Бер карасам,
Гел боз син,
Бер карасам,
Йолдыз син,

Искитәрлек
Матур син,
Ничек җирдә
Ятарсың?

Ашыкмачы,
Очынма!
...Кар бөртеге
Учыма

Төште дә,
Бөтерелеп,
Мактанудан
Бетте эреп!

Шәүкәт Галиев.

?! Кар бөртеге — әсәрнең төп персонажы. Ләкин шигырь кар бөртеге турында түгел. Исбат итегез.

ТӘБӘ ПЕШЕРМӘКЧЕ.

Бер кыз тәбә пешермәкче булган. Йомыркаларының берсен чүлмәк кырыена бәреп вата башлаган... Йомыркага берни булмаган, калын чүлмәк икегә ярылган.

?! Вакыйганы рәсем итеп ясагыз.

БӨРКЕТ, ЕЛАН ҺӘМ АГАЧ.

Күптән булган хәл. Буп-буш яланда ялгыз Агач үскән.

Аның тамырларында галәмәт зур Елан оя корган. Ә Агач башындагы ботаклар арасына куркыныч Бөркет оялаган. Болар, бергәләп, тыныч кына яши биргәннәр.

Агач башында мәгънәсез уй туганчыга кадәр шулай яшәгәннәр.

— Аста Елан яшәмәгән булсамы? Яшәмәсә, тамырларымны суза-суза, аждаһалар патшалыгына кадәр үсәр идем. Өстемдә Бөркет ояламаган булсамы? Ояламаган булса, минем ботакларым күккә җитәрлек итеп үсмәс идемени?

Шулай уйлый торгач, Агач хәйләкәр план уйлап тапкан.

Бөркет көн дә таңда уяна да ауга оча. Елан исә ауга көн уртасында гына шуышып чыга.

Беркөнне, Бөркет очып китүгә, Агач, башын бөгеп, Еланга болай дигән:

— Хөрмәтле Елан! Ничәмә-ничә ел туганнар кебек тату яшәдек. Мин әйткәнгә ышанмасагыз, иртәгә таң атканда Бөркетне күзәтегез. Алдамыйм. Очымда кунаклаган Бөркет болай дип сөйли: «Еланның башын чукып тишмәсәм, исемем Бөркет булмасын. Шундый матур агачта үзе генә рәхәт чикмәсен»,— ди. Ихластыр, шулай ди, хөрмәтле Елан.

Бу сүзләрне ишеткәч, Елан хәтта калтырый башлаган.

Төш җиткәч, Елан ауга киткән, ә Бөркет аудан оясына әйләнеп кайткан. Агач, ашыга-ашыга, аңа хәтәр хәбәрен сөйләгән:

— Хөрмәтле Бөркет! Без ничә еллар буена бертуганнар кебек тату яшәдек. Шуңа күрә мин сезне бик яратам. Яратканга күрә, бик җитди хәбәр сөйләми булдыра алмыйм. Менә тыңлагыз: «Шул Бөркетне кабып йотмасаммы? Кабып йотам да матур агач астында берүзем рәхәтләнеп яшим»,— дип сөйләнә. Шуның өчен Елан көн дә иртән синнән күзен алмый. Мин әйткәннәргә ышанмасагыз, иртән үз күзегез белән күргәч ышанырсыз.

Агач сүзләрен ишеткәч, Бөркет Еланны ерткалап ташларлык дәрәҗәгә җитеп нәфрәтләнгән.

Төнлә Елан да, Бөркет тә ятып йоклаганнар. Ә таң аткач, Елан Агач очына караган да:

— Бөркет, чыннан да, минем башны чукып тишмәкче буламы? — дип сораган.

Ул арада Бөркет тә Агач сүзләрен исенә төшергән. Бу Елан чынлап торып мине йотмакчы буламы дип, аска күз төшергән. Алар бер-берсенең күзенә

туп-туры караганнар. Агач сүзләренең хак булуына хәзер икесе дә тәмам ышанганнар.

— Бер койрыклы буш куык, әле син мине йотарга йөрисеңмени? — дип кычкырганын Бөркет сизми дә калган.

— Ә син, бөкре бака, чыннан да, минем башны чукырга дип сүз биргәнсең икән! — дип кычкырган Елан.

Шулай сүз көрәштерә торгач, Бөркет, оясыннан очып, җиргә төшкән, Елан үз оясыннан шуышып чыккан. Сугыш башланган. Бөркет, уктай атылып, югарыга очкан да, таш булып, Елан өстенә ташланган. Елан Бөркеткә астан торып ыргылган. Буп-буш яланда

болар сугышыннан күтәрелгән тузан эчендә кешеләр хәтта юлларын югалтып адашканнар.

Сугыша торгач, Бөркет Елан башын, чукып, иләк ясаган, Елан Бөркетнең муенын сындырган. Икесе дә үлгәннәр.

Бу хәлне күргәч, Агачның шатлыгы кәүсәсенә сыймаган.

— Булды бу! Хәзер минем тамырларым аждаһа патшалыгына кадәр сузылачак, ә ботакларыма күккә үсеп җитәргә берәү дә комачаулый алмас! — дигән.

?! Әкиятләрдә явызлар, башта җиңсәләр дә, соңыннан җәза алалар. Бу әкият тә шулай тәмамлана. Агач нинди җәза алырга мөмкин, уйлап табыгыз. Мәсәлән, Агач корый, ава, утынга киселә ала. Шуларның кайсы Елан һәм Бөркет белән бәйле? Уйны дәвам итегез.

Күнекмәләр.

ТИРӘН КҮЛ.

1

Буран иде бу төнне,
Иван бабай тун киде,
Бүрек киде, итек киде:
— Әйдә, улым, киттек,—
диде.
Алдылар алар балта,
Алдылар тимер көрәк;
Дөнья булгач дөнья инде,
Бөтенесе дә кирәк.

Күренми бер кеше дә,
Алар яшерен генә
Чыктылар арт урамга,
Юл тоттылар урманга.

Иван бабай тун кигән,
Туны җылы, якалы;
Иван бабай — карт кеше,
Көрәк чаклы сакалы.

Күренми бер кеше дә,
Алар яшерен генә
Чыктылар арт урамга,
Юл тоттылар урманга.

Иван бабай тун кигән,
Туны җылы, якалы;
Иван бабай — карт кеше,
Көрәк чаклы сакалы.

Улы менә кечкенә,
Аңа унбер яшь кенә;
Кечкенә ул, сакалсыз,
Бишмәте дә якасыз.

Ямаулы зур бияләе,
Бусы — әтисенеке,
Төпләгән киез итеге,
Бусы — әбисенеке.

Башына шлем кигән ул,
Шлем аңа килешә,
Тик азырак зурырак:
Борынына шуып төшә.

Нинди иде мәктәпләре,
Нинди укый иде ул,
Болар бар да элек иде,
Хәзер ул укымый шул.

Бар иде яңа бүреге,
Яңа киез итеге,
Бөтен яңа киемнәрен
Бер немец талап китте.

Яндырдылар мәктәпне,
Укытучы апаны
Хур итеп бетерделәр
Һәм асып үтерделәр.

Алып киттеләр каядыр
Яшь балалы әнисен;
Өйдә калды бабасы да
Авыру билле әбисе.

Алып китәләр көн дә
Бабасын да, үзен дә,
Бүре тавы артына
Тимер юл тазартырга.

Карап яталар алар,
Читкә күз ташламыйлар.
Эшләмәсәң — аталар,
Эшләсәң — ашатмыйлар.

Эшләгән эшең, көчең
Булгачтын немец өчен,
Иң кыены, авыры —
Эшкә һич күңел бармый.

2

Иван бабай тун кигән,
Туны җылы, якалы;
Иван бабай — карт кеше,
Күрәк чаклы сакалы.

Улы аның кечкенә,
Аңа унбер яшь кенә;
Кечкенә ул, сакалсыз,
Бишмәте дә якасыз.

Тотканнар алар балта,
Тотканнар тимер көрәк;
Дөнья булгач дөнья инде,
Бөтенесе дә кирәк.

Килделәр. Менә урман,
Котырып уйный буран,
Уйный буран, сызгыра,
Бит алмасын кыздыра.

Колак салып еракка,
Карадылар як-якка:
Ни күренсен буранда,
Шаулап торган урманда?

Урманның сере шунда:
Бер күл бар уртасында,
Бөтен картлар, әбиләр
Аны бик тирән, диләр.

Кышын күлне боз каплый,
Боз өстеннән юл үтә,
Һәм фашистлар бу юлдан
Сугышка корал илтә.

Җәзаларга халыкны,
Калган актык байлыкны
Тартып алырга кулдан
Киләләр шушы юлдан...

Алды бабай балтасын,
Төшерде тун якасын:
— Йә улым, башлыйк,—
диде,—
Актарып ташлыйк,— диде.

Эштә кул җитез булды,
Күлдә юл булган бозның
Иң кирәкле җиреннән
Байтагын җимерделәр.

Күл булгач, шунсы җайлы,
Бозлар өчен уңайлы:
Агып китми берсе дә,
Торалар су өстендә.

Шик төшәрлек төшләргә
Карт — хәйләкәр —
кар сипте,

Көрәк белән суккалап,
Элеккечә юл итте.

Авыр булды бабайга,
Ә кечкенә малайга? —
Аяк-кулы чыланды,
Эндәшмәде, чыдады.

Малай башын күтәрсә,
Юл буеннан бернәрсә
Килә шаулап, үкереп,
Бака кебек сикереп.

Әче бер үч, калтырану
Купты безнең малайда,
Тешләре шыкылдаганны
Сизде хәтта бабай да.

— Танк килә түгелме?
Бусы менә күңелле!
Күл төбен күреп чыксын,
Юк, чыкмасын,
тончыксын!

— Әйдә, улым, сызыйк
без,
Юкса күрер козгын күз...
Чыгалар юлдан читкә,
Чумалар тирән көрткә.

Килә танк, ә малай?
Малай бераз шомлана.
Килә танк, ә бабай?
Күзләре очкынлана;

Калтырый ак сакалы,
Кыса ул балта сабын.
Көтәләр алар икәү:
«Ни булып бетәр икән?!»

Килә танк үкереп,
Бик тәкәббер сикереп.
Исә җил, карны каулый,
Ярларда урман шаулый.

Буласы эш — ул булды,
Менә танк ыргылды,
Янтайды ялган бозлар,
Чәчрәде бозлы сулар.

Җитәр таптап йөрергә!
Чумды танк гомергә;
Аның кара тәресе
Ташка барып бәрелсен!

Гөбер-гөбер килеп, танк
Күлнең төбенә китте,
Тончыкты гөберле бака.
Бабай улына төртте:

— Улым, күрдеңме?
— Күрдем.
— Нишләделәр?
— Баттылар...

Таң беленер-беленмәстә
Иван бабай белән Ваня
Өйләренә кайттылар.

Фатих Кәрим.

?! **1.** Шигырьдәге вакыйганы беркадәр кыскартып сөйләгез.

2. Хәзер әсәрнең эчтәлеген эзлик. Моның өчен авторның безгә сүзсез генә әйткән киңәшен табыйк. Теорияне искә төшерәбез: автор киңәшенең бер чарасы — кабатлау дигән идек. Шигырьдә кабатлану бар. Шул юлларны табыгыз һәм эчтәлеген үз сүзләрегез белән әйтегез.

3. Эчтәлекне таптыгыз. Инде ул эчтәлекне ни өчен кабатлавымны белегез, дип тә өсти автор. Бергәләп уйлыйк. Автор безгә нәрсәне таптыра?

Шигырьнең авторы белән танышыйк.

Фатих Кәрим нибары утыз алты ел гына яшәп кала. Бу елларның бер өлеше белем алуга китсә, җиде елы хәрби хезмәттә үтә. Аның иркенләп утырып әсәр язарга вакыты да калмаган диярлек. Шуңа күрә әсәрләре күбрәк эш вакытында, яу кырында туалар. Күңелендә туган әсәрләрен ул эш арасында, сугыш тынып торган арада гына кәгазьгә төшерә алган. Шагыйрьнең дустына язган бер хатында мондый юллар бар:

«Мин бу юлы да фронтта бирешмәдем, кулда корал белән ут эчендә йөргәндә татар совет язучысы исеменә тап төшермәдем, зур тырышлык белән үз иҗатым өстендә эшләдем... «Разведчик язмалары» дигән күләмле проза өстендә эшлим... Төнге йокы сәгатьләрендә сукыр лампа яктысында тезембә такта куеп язам. Шундый язасы килә...»

Кызганычка каршы, шагыйрь, сугыш тәмамлануга нибары өч ай калганда, Кёнигсберг шәһәренә һөҗүм вакытында һәлак була.

Фронтта язган «Сибәли дә сибәли» шигырендә әдип разведкада һәлак булган иптәшләрен күму турында болай яза:

Кайгыдан каралып торган
Япь-яшь нарат төбенә
Япь-яшь иптәшне күмгәнне
Күрә бары төн генә.

Япь-яшь иптәшне күмәбез,
Беркем берни сөйләми,
Күзгә төндә яңгыр гына
Сибәли дә сибәли.

Бик аз яшәгән Фатих Кәрим. Ләкин шул арада да күп санлы әсәрләр язарга өлгергән. Аларның күбесе балалар өчен язылган. Аның хәтта «Хәзер сезнең белән» дигән иң беренче шигыре дә балалар өчен бит. Әдип иң күләмле әсәрләрендә дә балаларны төп персонажлары арасына керткән.

Ә күпме гүзәл әсәрләр язган булыр иде!

БАБАЙ САНДЫГЫ.

(Вл. Лифшицка ияреп.)

КАТНАШАЛАР:

Васил белән Камил.

Васил керә. Кулындагы сандыкны урындыкка куя.

Васил. Бу кадәр киребеткән нәрсә булса булыр икән. Ачылмый гына бит. Әйтмәгән сүз калмады. Исе дә китми. Тагын әйтеп карыйм әле. *(Сандыкка.)* Сандык, хәзер үк ачыл! Ачылмый. Ачыл дигәч, ачыл! Кыланып утырма, сандык! Юк. Бер генә минутка булса да ачыл дим мин сиңа! Тыңламый. Нишләтергә инде бу юньсезне?

Камил керә.

Камил. Ни булды? Нигә шулкадәр кычкырасың?

Васил. Кычкырмыйм. Кирәкле сүзне сайлыйм.

Камил. Нинди сүз?

Васил. Нинди булсын, кирәкле сүз!

Камил. Нигә кирәк ул сиңа?

Васил. «Нигә дә нигә!» Сандыкны ачарга. Менә нигә. Шул сүзне әйтмәсәң ачылмый.

Камил. Нигә ачылмый?

Васил. «Нигә дә нигә!» Сандык сихерләнгән. Менә нигә. Аны авылдан бабай җибәргән. Кичә әйттем бит. Сандык җибәргән, дидем.

Камил. Берни дә әйтмәдең.

Васил. Минем бабай Кавказда яши. Аның зур алма бакчасы бар. Андагы җиләк-җимешне күрсәң!.. Менә шул бабай җиләк-җимеш тутырып сандык һәм хат җибәргән. Хатында болай дигән. Тыңла. *(Хатын алып укый.)*

Җибәрәм сиңа, онык,
Менә дигән бер сандык.
Эченә салдым
Әфлисуннар
Алмалар һәм мандариннар.

Аңа эленгән йозак,
Ә син аны ачып бак.
Кирәкле сүз уйлап тап.
Ишетсә, шул сүзеңне
Танып алыр үзеңне:
Сандык шундук ачылыр,
Күр дә тор, шатландырыр.

Камил. Әллә кайчан шулай диләр аны. Әнә шул бердәнбер сүзне таба алмыйм дисең инде, алайса?

Васил. Таба алмыйм. Әйткән сүзләрем меңнән артты инде.

Камил. Ачылмыймы?

Васил. Ачылырга уйлап та карамый.

Камил. Тагын әйтеп кара.

Васил. Ярый. Тагын әйтеп карыйм... *(Сандыкка.)* Ачыл дим мин сиңа! Хәзер үк ачыл! Ачыласыңмы, юкмы? Ачыл диләр сиңа! Югыйсә тетмәңне тетәм бит, юньсез!.. *(Сандыкка йодрыгы белән китереп бәрә. Кулын авырттыра.)* Әллә-әллә! Әле син шулаймы, юньсез агач!

Камил. Мин сандыкны ача торган сүзне беләм кебек.

Васил. Белгәч, нигә авызыңа су капкандай утырасың? Әйт!

Камил. Колагыңа гына әйтәм. *(Пышылдап нидер әйтә.)*

Васил. Булмас. Ышанмыйм. Мин аңа миллион сүз әйтеп карадым. Шулар арасына ул сүз керми калмагандыр, кергәндер.

К а м и л. Миллионны әйткәнсең. Ә менә иң кирәклесен исеңә төшермәгәнсең. Йә, әйтеп кара!

В а с и л. Әйтеп карыйммы? Ничектер ят сүз ул миңа. Мин аны берәүгә дә әйткәнем юк. Ярый, алайса. Әйтеп карыйм... *(Сандыкка, ягымлы итеп.)* Сандыккаем, ачыл әле, зинһар.

Сандык капкачы ачыла.

Ачылды!.. Ачылды!.. Кара әле — алмалар! *(Бер алма алып ашый башлый. Берсен иптәшенә бирә.)* Тәмлеме?

К а м и л. Бик тәмле. Рәхмәт... Ә мандариннар, әфлисуннар кайда?

В а с и л *(сандыгына карый).* Монда алмалар гына. Ә бабай сандыкта әфлисун белән мандарин да бар дип язган иде... Хатында шулай дигән дә... *(Хатын алып укый.)*

Эченә салдым
Әфлисуннар
Алмалар һәм мандариннар.

Акка кара белән язган бит.

К а м и л *(хатны алып укый).* Син хатны укып бетермәгәнсең бит. Анда тагын менә нәрсә әйтелгән:

Әфлисуннар юк, чөнки
Нидер әйтергә оныттың...

(Балаларга карап.) Балалар, нинди сүз әйтергә оныттыы Камил?

Б а л а л а р. Рәхмәт!

В а с и л. Рәхмәт!.. Рәхмәт, бабакай!.. *(Сандыкка күз ташлый.)* Кара әле, әфлисуннар да, мандариннар да барлыкка килде. Менә нинди бабай сандыгы!..

К а м и л. Ә ул, кеше кебек, үзе белән әдәпле сөйләшүне ярата. Аңладыңмы?

В а с и л. Аңладым. Рәхмәт!

К а м и л. Зур үс.

Әсәренең эчтәлеген автор безгә кыска гына, ләкин аңлаешлы итеп әйтә алыр иде. Мәсәлән, болай: «Хөрмәтле укучыларым, әдәпле булыгыз, «Рәхмәт», «Үтенеп сорыйм», «Рәхим итеп...» сүзләрен һәрвакыт тел очыгызда гына тотыгыз»,— дияр иде. Ләкин автор безне үгетләмәгән. Үгетен бик матур вакыйга эченә яшереп куйган.

Хәзер автор бездән: «Сез кемгә охшагансыз, Василгәме, Камилгәме? Шуңа җавап эзләгез әле, ди. Ләкин җавап бирүегезне көтми. Җавапны үзегезгә үзегез бирсәгез яхшы булыр иде», — ди.

Әсәр авторы сезнең ничек җавап бирүегезне белә. Шуңа күрә шыпырт кына: «Җавабыгыз өчен рәхмәт. Арагызда йөзенә кызыллык йөгергән укучы булса шатланыгыз. Мондый чакта йөзгә кызыллык килү — хатаны төзәтү билгесе ул»,— ди.

ТАШСУАР ПАТША.

Моннан күп мең еллар элек Ташсуар исемле бер патша яшәгән иде. Ташсуар белән тиңләшердәй пәһлеван якын-тирә илләрнең берсендә дә булмады.

Башка түрәләр сыман, Ташсуар патша кул кушырып, тәхет сагалап утырмас, түшәмгә тәкереп ятмас иде. Ул җиң сызганып, җир казый, печән чаба торган иде, ауга йөрер, җырлар-биер иде. Ул шундый таза иде, атка атланса, атның биле сыгылып җиргә тия. Ул шулкадәр батыр — үкереп килгән юлбарысны бер ук белән атып егар иде. Үгезләрне, мөгезләреннән тотып, каерып җиргә сала торган иде Ташсуар патша. Үзе ис-акылларны китәрерлек зиһенле, зирәк башлы, үткер сүзле иде.

Ташсуарның батырлыгын күреп, ир-атлар угылларын аңа охшатып тәрбияләргә тырышалар, аналар кызларын аңа тиң кәләш итеп тәрбияләргә хыялланалар иде. Ләкин Ташсуарга кәләш булырлык тиң гүзәл дә, Сабантуйларында аның белән алышырлык пәһлеван да табылмады.

Ташсуарның тәвәккәллеген, батырлыгын, куәтен сизеп, бер ил дә аңа яу белән килергә базмады. Бар да Ташсуар белән туганлашу уенда иделәр.

Биек тау итәгендә матур елга ага, елга аръягыннан киң җәйләү[1], болын башлана. Шул елганың җәйләү белән кушылган төшенә Ташсуар таш-кирпечләрдән шәһәр салып куйды. Бу шәһәргә Ташкала дип исем куштылар.

Илдән илгә йөреп, Ташкаланың матурлыгын мактап сөйләр, җырлар өчен, шагыйрьләр, чичәннәр, акыннар төрлесе-төрле якка чыгып таралдылар.

---

[1] Җәйләү — җирдә өсте тигез булган зур яссы калкулык.

Ташсуар шәһәре Ташкалага төрле җирләрдән илчеләр, кәрванчылар, атлылар, кораблар, җәяүлеләр агыла башлады. Шәһәр котларга дип мал төяп килгән илчеләр, сәүдәгәрләр үзара танышып, малтуар алышып, сату итәргә керештеләр. Ташкалада бөек ярминкә бәйрәме башланып китте. Базарларда итчеләр, киезчеләр, күнчеләр, хәлвәчеләр, сәйләнчеләр, җәүһәрчеләр, вак-төяк сатучылар мыж килеп торырлар иде.

Алыш-бирештән файда күргәч, сәүдәгәрләр Ташсуар казнасына зур-зур бүләкләр калдырып китә торган булдылар. Ташкала тагын да баеды, матурланды. Сиксән чакрымнан күренеп торган сиксән манарасы гына бар иде.

Мәйданнарында кәмит күрсәтү, аю-елан биетү дисеңме; ул әтәч сугыштыру, ул сорнайчылар, сазчылар, курайчылар, кубызчылар, шәрәбан-барабан кагучылар дисеңме, һәммәсе үз һөнәрен күрсәтә, булдыра алганча җырлап-уйнап, кеше күңелен ачып тамак туйдыра.

Чәйханәләргә дәрвишләр, мосафирлар, сәяхәтчеләр, ил гизүчеләр кереп тулды.

Халык җырлар иде, биер иде, күңел ачар иде.

Ләкин Ташсуар патша гына шатланмый. Шөһрәте дә җитәрлек югыйсә. Байлыгы да бар. Шулай да Ташсуар бер җанына урын табалмый аптырады. Чөнки аның сөйгән яры юк иде. Илчеләр белән яучылар җибәреп эзләтеп тә карады, алай да булмагач, Ташсуар кәләш эзләргә үзе чыгып китте...

Тапкыр кыз — гүзәл кәләш.

...Ташсуар патша кыз багу[1] мәҗлесе уздырырга булды.

Өндәүчеләр кыз багу мәҗлесе булачагын кычкырып йөрделәр.

Ит чабучы кызына:

— Син, ит бүкәне, күп ашама! Ташсуар нәзек билләрне ярата! — диде.

Бәлзәм-су сатучы үзенең кызына:

— Син, ябык ябалак, бигрәк ябыксың, күбрәк аша! Түрә юаннарны ярата! —диде.

Менә кыз багу мәҗлесе билгеләнгән көн килеп җитте. Чибәрләр бер-бер артлы кереп кенә торалар. Патша аларга бер-бер артлы сораулар бирә торды, табышмаклар әйтте. Ләкин, тырышып-тырышып ябыккан булуына карамастан, итче кызы да, никадәр юанайган булса да, бәлзәмче кызы да Ташсуарга ошамады.

— Нинди генә кыз кирәк соң сиңа, Ташсуар патша? — диделәр яучылар.— Инде боларыннан да артыклары юк!

Ташсуар әйтте:

— Минем өчен кызның матурлыгы шарт түгел! Миңа кызның мәгънәле булуы, зиһенле булуы кыйммәт! — диде.

Инде өмет өзелде, башка кыз табылмас дигәндә генә, бөркәнчек ябынган бер кызны мәҗлескә алып

---

[1] Кыз багу — кыз сайлау.

керделәр. Кыз башта патшага тез йөгенде[1], аннан — вәзирләргә, аннан тамашачыларга бил тиңентен иелеп хөрмәтен күрсәтте. Хәтта пәрәнҗә аша да бу кызның зифа буйлы, матур икәнен сиземләргә мөмкин иде.

Вәзир патша колагына әйтте:

— Аh, солтаным, менә ул кыз! — диде. Кызга карап, патша иң әүвәл бер сорау бирде:

— Кем син? Нигә үзең генә, атаң-анаң кайда?

— Мин — ятимә кыз бала. Исемем — Гөлзифа. Атам — игенче, анам киләпче[2] иде — вафат булдылар! — диде кыз.

— Игенче кызы Гөлзифа! — диде Ташсуар.— Әйтеп бирче, кояш батканда аяз булып, төн ягыннан салкын җил иссә, ни булыр?

Гөлзифа әйтте:

— Кояш батканда аяз булып, төн ягыннан салкын җил иссә, кырау булыр!— диде.

Вәзирләр вә патша да кызның җавабын бик хуп күрделәр.

Икенче сорау:

— Кояш батканда кояш артыннан болытлар ияреп барса, ни булыр?

Кыз әйтте:

— Кояш батканда кояш артыннан болытлар ияреп барса, каты давыл булу галәмәте, падишаһымсолтаным!

---

[1] Тез йөгенде — тез чүгеп сәлам бирде.
[2] Киләпче — җеп ураучы.

Вәзирләр әйтте:

— Алтын кыздан алтын сүз! Фәрештәдәй ягымлы, диделәр. Гөлзифа әйтте:

— Мин алтын түгел, солтаным! Фәрештә дә түгелмен, гүзәлләрнең гүзәле дә түгелмен! Мин җир кызы, һөнәрем — палас сугу!

Патша әйтте:

— Җир кызы Гөлзифа, сандык әзерләдеңме, кавыннар үстердеңме, паласлар тукыдыңмы?

Кыз әйтте:

— Сандыгым әзер тора, кавыннарым өлгерде, паласларым сугылды...

— Бик хуп! Бик күркәм! — диде Ташсуар.— Хәзер табышмаклар әйтешик.

— Баш өсте, падишаһ!— диде Гөлзифа.

Беренче табышмак:

— Җизнәй атын менеп булмай,
Җиз камчысын тотып булмай.

Кыз уйлады да әйтте:

— Аюга атланып булмас,
Еланны тотып булмас,— диде.

Диван вәзирләре[1] дә, патша да, тыңлап торучылар да җавапны бик хупладылар.

Икенче табышмак:

— Ике йөз егерме бармагы,
Егерме ике аякта тормагы;
Унбер башы, унбер тәне, ун җаны,
Ни гаҗәп: унбер барып, ун кайтты!

---

[1] Диван вәзирләре — патша киңәшчеләре.

Гөлзифа озак уйлады бу юлы. Уйлаганнан соң әйтте:

— Ун адәм берәүсен гүргә иңдереп кайтты. Вәзирләр, тамашачылар шаулаша башладылар.

— Ничек ул? Нишләп алай? — дип гаҗәпләнделәр. Гөлзифа болай дип аңлатты:

— Унбер кешегә ике йөз егерме бармак. Егерме ике аяк, унбер тән, унбер баш. Ун җан, димәк, берсенең җаны юк, ул — табутта. Унбер барды, ун кайтты. Берсе кабердә калды.

Барча халык ошбу зирәк җавапны ишетеп шаккатты. Шуннан соң Ташсуар Гөлзифага башваткычлар әйтте. Беренче башваткыч:

— Дөньяда өч кеше хайван белән сөйләшә, кемнәр алар? Гөлзифа җавабында болай әйтте:

— Авыл агае аты белән киңәшә. Аучы эте белән гәпләшә. Ялгыз карчык песие белән сөйләшә.

Ошбу җавап та матур саналды. Икенче башваткыч:

— Дөньяда хәерчедән дә хәерче кем?

— Адәм затларыннан — синең вәзирләрең, хайван затларыннан — кәҗә! — диде кыз.

Вәзирләр аптыраштылар:

— Ничек, ни өчен, аңлатып бир!

— Кәҗәнең сакал кырдырырга акчасы юк. Шуңа күрә гомере буе сакал асып йөри. Вәзирләрнең сакаллары кәҗәнекеннән дә озынрак!

Тамашачылар да, патша, хәтта вәзирләр дә, бу кызык җавапны ишеткәч, рәхәтләнеп көлештеләр.

Һәр җавап та Ташсуарны таң калдырды. Тамашачылар гөрләтеп кул чапты, «афәрин» кычкырдылар.

Вәзирләрнең сакаллары бертуктаусыз селкенә башлады: диван вәзирләре кызның зирәклеге турысында сөйләшә-киңәшә иделәр.

Шуннан патша урыныннан торып әйтте:

— Һай, Моңтасир!
Кыз бар җирдә кубыз бар,
Кубыз бар җирдә кымыз бар,
Кымыз бар җирдә кызык бар,
Кураең уйнап җибәр! —

дип, Ташсуар курайчы Моңтасирны уенга чакырды.

Сарайның иң оста курайчысы Моңтасир уйнарга дип кураен иреннәренә китергәндә, Гөлзифа йөзендәге чадрасын салып ташлады.

Курайчының күтәрелгән кулы катып калды. Вәзирләрнең сакаллары селкенүдән туктады. Тамаша кылучыларның «афәрин» дип кычкырырга җәелгән авызлары ачык килеш калды. Ташсуар патша мәрмәр сын рәвешле тораташ булды. Игенче кызы Гөлзифаның зирәклегенә хәйран калган Ташсуар кызның сихри гүзәллеген күреп телсез булды. Ул буйсын, ул гүзәл чырай, ул нәфис бармаклар, ул матур тавыш, ул чибәр күзләр турында сөйләсәң сөйләп, язсаң язып бетергесез иде. Менә берзаманны Ташсуар исен-акылын җыеп болай диде:

— Бу гүзәл кыз Гөлзифа илемнең патшабикәсе булыр!

Җаны теләгән елан ите ашаган, ди, Ташсуар үз теләгәнен алды да дөньяда тиңе булмаган бәйрәм ясады. Бәйрәмгә барча илчеләр, сәүдәгәрләр

чакырылды, хәтта базар халкын, ярлы-ябагайны да ныклап сыйладылар. Туйларында мин дә булдым: йөз самавыр чәй эчтем, мең чүлмәк кымыз түктем, бик күп хикмәтләр күрдем. Кырык көн уен, кырык көн туен уздырдылар.

Туйлар узды, туннар тузды дигәндәй, яши башладылар болар. Туйдан соң озак та узмады, гаҗәп сәер хәлләргә тап булды Ташкала. Кинәттән генә Ташсуар патша ашаудан өзелде, ябыга, кибә-корый башлады. Табиблар да, сихерчеләр дә моның сәбәбен аңлата алмадылар.

Көннәрнең берендә Ташкалага килүче, Ташкаладан китеп баручы бай кәрваннар юкка чыкты.

Ташсуар аптырады: вәзирләр, сакалларын күпме генә селкетсәләр дә, бу сернең очына чыга алмадылар. Шул хәсрәттән патша, бөтенләй өзлегеп, урынга ятты. Сөекле иренең өметсезлеген күреп, патшабикә дә бик уфтанды, кара кайгыга сабышты: аһ итте, ваһ итте, төрле шифалы үләннәр эчертеп карады. Барыбер файдасы тимәде, Ташсуар патша көннән-көн хәлсезләнә барды.

Кәрваннар һаман эзсез югала торды. Тора-бара илчеләр, Ташсуарга ачуланып, Ташкаланы каһәрләп кайтып киттеләр. Базарлар, урамнар бушап калды.

Телсез курайчы.

Моңтасир атлы телсез егет Ташсуарның гөлбакчасында каравылчы иде. Шул егет, сөйләшә белмәсә дә, искиткеч оста уенчы иде. Моңтасир кичләрен гөлбакчада салмак кына курай тарта торган иде.

Шулай кичләрнең берендә бакча буйлап йөрергә чыга бу. Курай уйнап, патшабикә тәрәзәсе каршыннан узган чагында, кинәт тәрәзә капкачлары ачылып китә, тәрәзәдә патшабикә күренә. Һич көтмәгәндә гүзәл хатын тәрәзәдән чыга да курайчыга таба килә башлый. Үзе килә, үзе боргалана-сыргалана биергә тотына. Биегән саен, ул еланга охшый бара, егет, сихерләнгәндәй, һаман уйный. Патшабикә еланга әверелеп бетә. Елан курай көенә сыгылып-сыгылып бии, ә үзе Гөлзифа тавышы белән егеткә дәшә:

— Зинһар, уйнама!.. Тукта!.. Тукта!.. Мин арыдым инде! Зинһар, кызган мине! — ди.

Курайчы туктый. Юха елан шундук патшабикә кыяфәтенә кайта да тиз генә сарайга йөгереп кереп китә. Сарайга керү белән, патшабикә җир ярып акыра башлый. Хезмәтчеләр, вәзирләр корт чаккандай сикерешеп торалар.

— Коткарыгыз! Коткарыгыз... Телсезне тотып алыгыз! Тәрәзәм каршында ул төне буе сыбызгы сызгырта, йокы бирми!—ди юха елан.

Телсез курайчыны тотып алалар.

— Ташсуар! — ди патшабикә иренә.— Мин синең кайгыңны кайгыртып, төн йоклый алмый азап чигәм. Синең телсез мәхлугың бакчада төне буе гыж-гыж көпшә өрә.

Патшабикә шулкадәр ышандырып елый, ялына, Ташсуар чын күңелдән хатынын кызгана һәм телсез курайчы Моңтасирның бер кулын чабып өзәргә әмер бирә. Мескен телсез аңлатырга тели, бакчада күргәннәрен әйтергә тырыша, ләкин җәлладлар

аны тыңлап тормыйлар, нәрсә әйтергә азаплануын төшенергә дә теләмиләр — курайчының уң кулын кисеп ташлыйлар.

Әмма ләкин курайчы сул кулы белән уйнарга тотына. Патшабикә тагын тәрәзәдән чыга, курай тавышына чыдый алмыйча, еланга әверелеп, тагын Моңтасир алдында бии, үзе бии, үзе патшабикә тавышы белән егеткә ялвара:

— Тукта, зинһар, тукта, егет! Мин синең колың булырга риза!—ди.

Еланны биетә-биетә әлсерәтеп бетергәч, курайчы егет туктый. Юха елан, хәлдән таеп, чәчәкләр түтәленә егыла һәм шундук патшабикәгә әйләнә.

— Коткарыгыз!—дип кычкыра патшабикә.— Телсез мине мәсхәрә итте!

Сакчылар килеп чыга. Телсез Моңтасир сыңар кулы белән нидер сөйләргә, аңлатырга тотына. Сакчылар аның кураен каерып алып, чәрдәкләп ташлыйлар.

— Бу телсез дивананың соңгы кулын да кисеп ташлагыз! — дип әмер бирә патшабикә.

Телсез курайчы Моңтасир ике кулсыз кала. Шул көнне төнлә белән Ташкаладагы бөтен курайчылар юкка чыга. Юха аларның барысын да астыртып үтерә.

— Алар — дошманнар!— ди патшабикә.— Алар авыру патшага йокы бирмиләр. Шуңа күрә без аларны юк итәбез!

Халык берни эшли алмый. Юха елан эчтән генә куана: илдә бер курайчы да калмады, хәзер мине

берәү дә үз кураена биетә алмас. Ә Моңтасир телсез, кулсыз мәхлук, берни кыла алмас дип тынычлап йокларга ята.

Ләкин йокыга китәргә дә өлгермәде патшабикә, курай тавышы ишетеп, сискәнеп торып утырды. Гөлбакчада кемдер өздереп курай уйный. Курай тавышы аны сихерли башлый. Юха елан ирексездән тәрәзә янына килә, курай тавышы аны тәрәзәдән бакчага төшәргә мәҗбүр итә. Курайга буйсынып, патшабикә тавыш килгән якка юнәлә. Килеп җитсә, ни күзләре белән күрсен, сукмак уртасында ике кулсыз, телсез курайчы Моңтасир басып тора, үзе тамак төбе белән өздереп курай тавышы чыгара икән.

— Аһ, курайчы, курайчы!—ди юха елан.— Мин җиңелдем! Бөтенләй җиңелдем, җибәр мине... Үз илемә, Үркалага кайтып китәм. Җибәр, зинһар, патшагыз да терелер, сиңа да куллар үсеп чыгар!

Моңтасир уйнавыннан туктамыйча, сарайга керде, елан бии-бии аңа иярде. Моңтасир юха еланны Ташсуар бүлмәсенә китереп җиткерде. Вәзирләр, сакчылар җыелды. Алар, исләре-акыллары китеп, елан биюен карап тордылар. Ташсуар телсезгә туктарга ишарә ясады. Курай тавышы тыну белән, юха елан патшабикәгә әйләнде.

Моны күреп, һәммәсе дә бөтен серне аңладылар.

— Юханы утка ташларга! — дип әмер бирде Ташсуар. Сакчылар патшабикәне тотарга дип килүгә, гүзәл хатын яткан җирендә юк булды. Ул, канатлы еланга әверелеп, тәрәзәдән чыгып очты. Барча халык юханы куа китте. Ләкин ул, һавага күтәрелеп,

Ташкала янындагы биек тау башына менеп кунды. Яхшылап баксалар, ни күрделәр: тау башы еланнар белән мыж килеп тора. Алар шулкадәр күп үрчегән, хәтта үр башына сыеша алмый, тау итәгенә сарылганнар. Шулчак иң биек түбәдә Аждаһа пәйда булды.

— Ташсуар халкы! Бу — мин! Юхалар патшасы Аждаһа! Кәрваннарны йотучы мин! Бүгенге көннән Ташсуар патшалыгы юк! Бүгенге көннән дөньяны минем юхаларым басып узачак! Бездә сихер дә, тылсым да, хәйлә дә, көч тә, куәт тә — бар да бар! Безгә каршы чыгу — үлем!

Коточкыч сызгыру, ысылдау яңгырады. Таудан меңләгән елан гаскәре төшә башлады. Көтелмәгән бу хәлдән халык та, гаскәр башлыклары да, зәгыйфь Ташсуар да каушап калды. Бу кадәр елан гаскәренә ничек итеп каршы тормак кирәк!

— Бетүебез шушы икән! — диде вәзир патшага.

— Нишләргә?! — дип кычкырды гаскәр башлыгы.— Елан гаскәре каланы камап алды! Капкаларны ачаргамы, әллә чыгып качаргамы?

Ташсуар боерды:

— Язмыш килә! Шәһәрне җимертмичә генә сакларга кирәк! Ачыгыз капкаларны! — диде.

Капкалар ачылды. Дошман гаскәре калага керәм дигәндә генә, бөтен дөньяны яңгыратып, курай тавышы ишетелде. Моны телсез, кулсыз Моңтасир тамак төбе белән өздереп уйный иде. Барча еланнар бердәй катып калды, бераздан соң еланнар биергә тотындылар. Әй биилар, әй биилар, сикерәләр, бор-

галаналар, сыргалананалар. Бер сәгать, ике сәгать биеделәр. Юха елан, тагын телгә килеп:

— Тукта, егет, тукта! Мин синең колың! — дип еларга ябышты.

Аңа кушылып, меңләгән юхалар, буар еланнар сызгыра-сызгыра еларга тотындылар. Шулчак Ташкала капкасыннан сугышчылар атылып чыктылар да бик күп еланнарның башларын чабып өзделәр. Курайчы арыгач, кояш баегач кына кырыш тукталды.

Соңгы сугышта елан гаскәре бик каты җиңелде, исән калган еланнар кире тау башына менеп качтылар.

Шуннан соң җиһанда тынлык урнашты. Сугыш беткәч, иминлек еллары башланды: Ташсуар сәламәтләнде, яралы сугышчылар сихәтләнде, күңелләр көрәйде, тагын мул тормыш килде илгә. Аждаһа белән юха, койрыкларын күрсәтергә дә куркып, Елантау башында яраларын ялап яталар. Инде яралары да төзәлде, ләкин барыбер Ташкалага төшәргә шүрлиләр. Төшәрләр иде дә, курайчы Моңтасир бар. Телсез, кулсыз курайчы сакта тора. Капка төбенә чатыр корып, шунда йоклый, шунда ашый, шунда яши. Үр өстендә елан гаскәре күрендеме, аны уяталар. Шуңа күрә юлбасарлар, Ташкалага төшмичә, шәһәр читендәге, ил чигендәге халыкны талап йөдәтә башладылар.

Беркөнне, курайчы Моңтасир чатыры янына килеп, вәзир болай диде:

— Бар, курайчы пәһлеван! Бар, агайне, үр-өскә менеп көйлә. Синең белән гаскәр барыр. Кырып бетерергә кирәк үр-өс еланнарын.

Чатыр эченнән җавап килмәде. Бер дәште вәзир, ике... Шуннан, шиккә калып, сакчыдан сорады:

— Курайчы бер-бер җиргә киттеме әллә?— диде.

— Юк, әфәндем,— диде сакчы.— Ул беркая да чыкмады. Аның янына пешекче кызы аш китереп киткән иде. Моңтасир пәһлеван ашап туйгач черем итә торгандыр.

Күңеле белән нидер сизенеп, вәзир, кынысыннан хәнҗәрен чыгарып, чатыр эченә иңде. Озак та үтмәде, чатыр эченнән үзәк өзгеч тавыш ишетелде. Шулчак чатырдан күзе-башы акайган вәзир атылып чыкты, чыкты да, акылдан язган тиле кебек, акыра-бакыра, атына атланырга да онытып, сарайга таба йөгерде.

— Курайчы үлгән! Курайчыбызны елан чаккан! Курайчыбыз һәлак булган! — дип кычкырды вәзир.

Бу тавыш бөтен шәһәр-ил өстен каплады. Ташсуар тиз генә гаскәр туплады, ярдәм сорап күрше илләргә чапкыннар җибәрде. Курайчы үчен алырга карар кылып, Ташсуар аксакалларны җыйды, киңәш итте.

— Бабайлар, әйтегез! Тау башы — еланнар оясы! Нинди чара белән котылырга алардан? Хәзер бездә көч җитәрлек, озакламый күршеләр килеп өлгерер! — диде Ташсуар.

Аксакаллар әйтте:

— Үрне салам, печән, чыбык-чабык белән урап, ут төртергә кирәк! Юхалар төтенне яратмый! — диделәр.

Шулай эшләделәр дә. Берзаманны үргә ут капты. Оча алмый торган еланнар ялкын-төтенгә чыдый алмыйча, тончыгып, янып үлделәр. Аждаһа белән

юха елан һавада югалдылар. Үр өстендә салам көле белән елан башы сөякләре генә аунап калды.

Телсез курайчы Моңтасирны әллә нинди сихерләр, тылсымнар белән терелтергә азапландылар — булмады. Курайчыны хөрмәтләп җирләделәр. Аның кабере өстендә курай көпшәләре үсеп чыкты. Ул көпшәләр гаять матур курай тавышы чыгарып шаулый башладылар.

Ташсуарның икенче тапкыр өйләнүе.

Аждаһа белән юханы тау башыннан куып җибәргәч, Ташсуар тагын эшкә тотынды. Сугышта җимерелгән кала-авылларны төзәттерде, күршеләр белән сәүдә эшләрен яңартты.

Ташкала тагын элеккеге шөһрәтенә менеп җитте, хәтта аннан да узып китте.

— Инде бар як та түгәрәкләнде, хәзер башлыкүзле булсаң да ярый! — диделәр Ташсуар патшага.

Патша дәшмәде. Өйләнәм дисә — курка: «Бу юлы тагын алдансам, бу кәләшем урынына гөберле бака чыкса, нишләрмен? — дип шүрли.— Ни булса шул булыр, тәвәккәл таш ярган, дип, иртәгә кыз багу мәҗлесе уздырыргамы икән әллә?» — дип уйлый. Аннан соң ул, бер карарга килеп:

— Җыегыз мәҗлес! — дип боерды.

Кызлы кешеләрнең тагын йокысыз төннәре башланды.

Мәҗлес җыелды. Ләкин кызларның бер генәсе дә Ташсуарның күңеленә хуш килмәде. Инде мәҗлес тәмам булды дип торганда гына җыр тавышы

ишетелде. Барысы да, гаҗәпләнеп, җыр тыңлау белән мәшгуль булдылар. Шулкадәр матур җыр иде бу, патша түзмәде, әйтте:

— Кем ул шулай җырлый?—диде.

— Бу, Ташсуар патша, гөлбакчаңны каравыллаган телсез курайчының апасы Гөлчәчәк түтәлләргә су сибә!— диделәр вәзирләр.

Ташсуар, гөлбакчага чыгып, кызны эзләп тапты. Кыз, патшаны күргәч, оялып кына йөзен яшерде дә тез йөгенде.

— Тагын җырла, зинһар!— диде патша.

Кыз патшадан тел яшерә иде, шуңа күрә дәшмәде. Инде нишләргә белмәгәч, Ташсуар үзе җырлап җибәрде. Ташсуар-егет җырлый да җырлый, кыз онытылып тыңлый да тыңлый; соңра үзе дә аңа кушылып җыр башлады.

Чәчәкләр үстерүче кыз белән патша кара-каршы озак җырлашып утырдылар. Ташсуар Гөлчәчәккә гашыйк булды. Гөлчәчәк тә Ташсуарны күптәннән ярата икән.

— Дөнья әйләнеп тапмадым... Кәләшем үз бакчамда икән ләбаса!—диде Ташсуар.

Шулай итеп, алар өйләнештеләр. Ул туйга чакырылган кунак-төшем! Язсаң язып, сөйләсәң сөйләп бетергесез! Ул ашамлык, ул нигъмәт, чәйләр-мәйләр, каты-котыны санасаң — санап бетергесез! Гел галәмәт! Туйларында мин дә булдым... Йөз самавыр чәй эчтем, мең чүлмәк ширбәт түктем, бик күп хикмәтләр күрдем...

Рабит Батулла.

?! **1.** Әкияттә ике зур вакыйга бар. Беренчесе — тау башы еланнарын җиңү вакыйгасы. Дошманны кем җиңә? Еланнар күп тә, аларда сихер көче дә бар. Аларны көч җиңә алмый — көчсез, телсез бакча каравылчысы курай уйнап җиңә. Дошманнарны егетнең моңлы көе җиңә. Шуңа күрә бу өлешкә «Моң көче» «Матурлык көче» дип исем бирик.

Әкияттәге беренче вакыйгага бәйләнеше булган икенче вакыйганы табыгыз.

2. Өлешләр һәм алар арасындагы бәйләнештә авторның безгә әйтәсе сүзе ята. Автор безгә нәрсә әйтергә тели?

Ятлау өчен.

ТУГАН АВЫЛ.

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән...

Истән чыкмый монда минем күргәннәрем,
Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем;
Абый белән бергәләшеп, кара җирне
Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем.

Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,
Билгесездер: кая ташлар бу тәкъдирем[1];
Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.

Габдулла Тукай.

[1] Тәкъдирем — киләчәгем, язмышым.

АЙ КЕБЕК, БЕЗ ОЗАК ЯШӘМӘБЕЗ.

(Өзек.)

Ах, җир,
Ах, җир!
Синең матурлыгың
Шундый тигез итеп таралган:
Һәр дуңгызың, һәрбер песи кызың
Чәчәк кебек матур яралган...
Һәр әтәчкә бүркем салып үтәм,
Совет саулык бирсен аңарга;
Һәрбер эткә, үзе тели икән,
Рөхсәт итәм борным яларга...
Һәрбер сыер мине, бозавы итеп,
Ап-ак сөте белән имезгән;
Һәрбер сарык, тунын салып биреп,
Кышкы суыкларда кигезгән...
Ә ай ялгыз,
Айда бернәрсә юк,
Әтәч тә юк анда, песи дә;
Катык та юк анда, ипи дә юк
Безнең ише ярлы кешегә...

Һади Такташ.

Эчтәлек

КОШ-КОРТЛАРНЫ СӨЙЛӘШТЕРҮ, ПРЕДМЕТЛАРНЫ ҖАНЛАНДЫРУ.

Йөри торган агач. *(Миф.)* 4
Бай әтәч, Ярлы әтәч. *(Миф.)* 6
Чишмә. *Әхмәт Исхак* 7
Ак итек. *Фәннур Сафин* 8
Сыерчык. *Гасыйм Лотфи* 9
Кошлар кайткач. *Галимҗан Латыйп* 9
Чылбырдагы эт. *Габдулла Тукай* 10
Ай сукмагы. *Габделхәй Сабитов* 12
Көмеш тояк. *Павел Бажов* 38
Кышкы төн. *Флёра Тарханова* 48
Ипекәй. *Әмирхан Еники* 49
Борын. *Идрис Туктар* 51

АРТТЫРУ АЛЫМЫН ӨЙРӘНИК.

Надан юлбашчы. *(Миф.)* 53
Соңгы пилмән. *(Кытай халык әкияте.)* 56
Бер агай. *(Татар халык әкияте.)* 57
Каракош һәм чүл. *(Кытай халык әкияте.)* 62
Төз атылган ядрә. *Эрих Распе* 65
Курчак батыр. *Бари Рәхмәт* 68
Мишка пешергән ботка. *Николай Носов* 71
Джельсомино ялганчылар илендә. *Джанни Родари* 73

ХӘРӘКӘТ ОХШАШЛЫГЫ.

Кузгалу, күчү, гамәл, вакыйга. 82
Туганнар мәхәббәте. *(Мәзәк.)* 84
Ике бәти. *Җәүдәт Дәрзаман* 85
Тукрансакал. *Бертуган Якоб һәм Вильгельм Гриммнар* . . . 86
Шакир белән Гали. *Муса Җәлил* 93
Тимеркендек. *(Татар халык әкияте.)* 94
Чук һәм Гек. *Аркадий Гайдар* 100
Хикәянең авторы белән танышыйк. 122
Иҗади эш.
Күзгә кичтә. *Зиннур Мансуров* 124
Ничек белеп алырга? *Рөстәм Мингалим* 125
Кар бөртеге, кун кулга. *Шәүкәт Галиев* 126
Тәбә пешермәкче. *(Мәзәк.)* 127
Бөркет, Елан һәм Агач. *(Монгол халык әкияте.)* 127
Күнекмәләр.
Тирән күл. *Фатих Кәрим* 130
Шигырьнең авторы белән танышыйк. 134
Бабай сандыгы. *(Вл. Лифшицка ияреп.)* 135
Ташсуар патша. *Рабит Батулла* 139
Ятлау өчен.
Туган авыл. *Габдулла Тукай* 156
Ай кебек, без озак яшәмәбез. *Һади Такташ* 157

Учебное издание

Яхин Альберт Гатуфович (Гатинович)

ЛИТЕРАТУРА

Учебник для 4 класса начальной
общеобразовательной школы с татарским языком обучения

В двух частях

Часть вторая

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Яхин Альберт Гатуф улы

ӘДӘБИЯТ

Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең
4 нче сыйныфы өчен дәреслек

Ике кисәктә

Икенче кисәк

Мөхәррире *З. М. Гыйниятова*
Бизәлеш мөхәррире *М. Д. Вәҗиева*
Компьютерда биткә салучысы *Г. Р. Галимҗанова*
Корректорлары *Г. Г. Мөхәммәтҗанова, Т. Н. Сәгъдуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 14.02.2011.
Форматы 70х90 $^1/_{16}$. Шартлы басма табагы 11,7 + форз. 0,29.
Тиражы 3700 д. Заказ Р-612.

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 519-45-22.
http: //tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:
Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.
Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

9 785298 020473